МИРАС

ЧЫН

ФӘННИ-ПОПУЛЯР,
ӘДӘБИ-НӘФИС ЖУРНАЛ

№2 / февраль 2013

ТАРИХИ, ӘДӘБИ, МӘДӘНИ МИРАС, ТӘНКЫЙДИ ФИКЕР, ЗАМАН ӘДӘБИЯТЫ, ЯҢАЧА КАРАШ

Башкалабызның Каюм Насыйри урамындагы 10 нчы йорт
Бу йортта 1858-1889 елларда татар халкының күренекле мәгърифәтчесе, дин белгече, тарихчы галим Шиһабетдин Мәрҗани яшәгән.
Йортны төзекләндерү эшен Урман хуҗалыгы министрлыгы башкарды.

12 +

Журнал «ТАТМЕДИА» ААЖ тарафыннан гамәлгә куелды.

2012 елның май аеннан чыга.

Индекс 54132

Баш мөхәррир —
Илфак Мирза улы ИБРАҺИМОВ

Баш мөхәррир урынбасары — җаваплы сәркатип —
Рамил Ханнанов

Редакция советы:
Марсель Әхмәтҗанов
Разил Вәлиев
Резеда Ганиева
Рәдиф Җамалетдинов
Фәнзилә Җәүһәрова
Ринат Закиров
Дания Заһидуллина
Илдус Заһидуллин
Данил Ибраһимов
Зиннур Мансуров
Ким Миңнуллин
Данил Мостафин
Рөстәм Мөхәммәдиев
Рафыйк Мөхәммәтшин
Гөлчәчәк Нәҗипова
Индус Таһиров
Рамил Ханнанов
Рафаил Хәкимов
Әнвәр Хуҗиәхмәтов

Иҗат төркеме:
Илдус Заһидуллин
Диләрә Нәүрүзова
Дания Фәйзуллина
Ленар Гобәйдуллин
Ренат Миңнегалиев
Алия Мөбарәкшина

Редакция һәм нәшрият адресы:
420066, Казан шәһәре,
Декабристлар урамы, 2 нче йорт
Телефон: (843) 222-09-83 (17-90)
Электрон почта:
yanamiras@mail.ru

Заказ № С-257
Тираж — 2000 данә.
Формат 70 x 108 1/16
Журнал айга бер тапкыр чыга.
Басарга кул куелды: 30.01.2013

МИРАС
ЧЫН
ФӘННИ-ПОПУЛЯР, ӘДӘБИ-НӘФИС ЖУРНАЛ
№2 (14) / февраль 2013

Эчтәлек

ТАРИХ

5 **XIX гасыр ахыры — XX йөз башы татар-төрек багланышлары.** *Исмәгыйль Төркуглы*
20 **Ташлар сере.** («Түгәрәк өстәл»)
34 **Бертуган Хөсәеневләр каберләренә куелган ташъязма истәлекләр.** *Ирек Һадиев*
38 **Керәшен Сәрдәсе авылы тарихыннан (XV-XIX гасырлар).** *Николай Петров-TEKIN*
46 **Габдрахман Рафиков гаиләсе һәм татар зыялылары.** *Ләлә Мортазина*
56 **Җыр калдырыйк.** *Фәнис Яруллин*

СӘНГАТЬ

59 **Үги кыздан — Мәйсәрәгә.** *Луара Шакирҗан*
65 **Альтернатив... яки кинәсез кино.** *Әхтәм Зарипов*

ӘДӘБИЯТ

72 **Телебез сафлыгы сагында.** *Гөлназ Хөснетдинова*
73 **Татарстанда «Фәнни истыйляхлар» ясау. Мәскәүнең яңа һөҗүме.** *Гаяз Исхакый*
76 **Балалар күңеленә ачкыч тапкан әдип.** *Сәүия Хәкимова*
83 **Балкыш, яки Хәйретдин Мөҗәйнең сугыш язмаларыннан юллар.** *Зиннур Мансуров*
92 **Батырша.** *Фәүзия Бәйрәмова*
99 **Тукай энциклопедиясенә.** *Резеда Ганиева*

БӘЙРӘМНӘРЕБЕЗ

102 **Мәүлид бәйрәме һәм аның тарихы.** *Ренат Миңнегалиев*
107 **Мишәрстанда Мәүлид.** *«Аксакал»*

ДӨНЬЯДА СҮЗЕМ КАЛЫР

112 **Иле барның теле бар.** *Гүзәл Нәбиуллина, Лилия Гыйләҗева*
116 **Яңа китаплар.** *Дания Заһидуллина*
118 **Тарих сәхифәләреннән**
119 **«Универсиада!» дип тибә йөрәкләр.** *Атлас Гафиятов*

Журнал 2012 елның 17 апрелендә Федераль элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсендә ПИ №ФС77-49398 нче таныклык белән теркәлде.

Бәясе ирекле

Мәкалә авторларының фикере редакция хезмәткәрләренең фикере белән туры килмәскә дә мөмкин.

Редакциягә килгән язмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый. Материаллар бары тик электрон вариантта гына кабул ителә.

Журналга кергән язмаларны редакция рөхсәтеннән башка күчереп бастыру тыела.

Бу санда авторларның, Ф.Мәрсетдинов, Л.Гобәйдуллин, Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры архивларыннан фоторәсемнәр файдаланылды.

Тышлыкның 1 нче битендә — «Оҗмах һәм дөнья». Шамаил. *Татарский шамаиль: слово и образ (Москва: Издательский дом Марджани, 2009) китабыннан;*
4 нче битендә — Кош сыны һәм тагылмалар белән чигә алкасы. *Алтын. Озынлыгы — 11,6 см. XI-XII гасырлар*

«ТАТМЕДИА» Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият
комплексында басылды.
Адресы: 420066, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2 нче йорт

«ИСТИННОЕ НАСЛЕДИЕ»
Ежемесячный научно-популярный, литературно-художественный журнал (на татарском языке)

Хөрмәтле укучыларыбыз!
Безнең журналга сез
54132 ИНДЕКСЫ
буенча һәр элемтә бүлегендә
язып аласыз.

ТАРИХ

Хаклыкны нинди генә авыр таш белән бастырып куйма, аны кубарып ташлардай көчлеләр, гайрәтлеләр табылыр.

Фәнис Яруллин

Габдерәшит Ибраһим һәм Әхмәт Мөнир Ибраһим. Истанбул, 1912 ел

XIX ГАСЫР АХЫРЫ – XX ЙӨЗ БАШЫ ТӨРЕК-ТАТАР БАГЛАНЫШЛАРЫ*

ИСМӘГЫЙЛЬ ТӨРКУГЛЫ,
Мәрмәрә университетының Тюркология институты докторы

ИСТАНБУЛНЫҢ ПРЕМЬЕР-МИНИСТРЛЫК АРХИВЫНДА XIX ГАСЫР АХЫРЫ – XX ЙӨЗ БАШЫ ТӨРЕК-ТАТАР БӘЙЛӘНЕШЛӘРЕ ТУРЫНДА ШАКТЫЙ ГЫНА ДОКУМЕНТЛАР БАР. АЛДАГЫРАК ЧОРЛАРГА КАРАГАН ДОКУМЕНТЛАР БИК АЗ САНДА САКЛАНГАН. БЕЗНЕҢ МӘКАЛӘБЕЗДӘ СҮЗ РОССИЯДӘ ЯШӘГӘН ТАТАРЛАРНЫҢ АВЫР ВАКЫТЛАРДА ГОСМАНЛЫ ДӘҮЛӘТЕНӘ СЫЕНУЛАРЫ, ИКЕ ХАЛЫК АРАСЫНДАГЫ БАГЛАНЫШЛАР ТУРЫНДА БАРА.

*Дәвамы. Башы журналның 1 нче санында

ГОСМАНЛЫ ДӘҮЛӘТЕ ҺӘМ ТӨРКИЯ ҖӨМҺҮРИЯТЕНӘ ХЕЗМӘТ ИТКӘН ТАТАРЛАР

Госманлы дәүләтенең төрле төбәкләренә урнаштырылган татар мөһаҗирләре арасында дәүләт хезмәтенә керүчеләр саны шактый. Габделхәмит II нең сараенда 30 еллап шәхси сакчысы булып хезмәт иткән, капитан чинына ия булган Мөфтәхетдин бине Габделгани Уфа губернасының Бәләбәй өязе Мәсәй авылыннан. Ул, Уфа янындагы Стәрлебаш мәдрәсәсендә укыганнан соң, Истанбулга килгән. Истанбулда Мөфтәхетдинне падишаһ белән таныштырганнар. Падишаһ Габделхәмит II Мөфтәхетдиннең исемен Мостафа дип үзгәртә һәм сарайның гвардиясенә урнаштыра. Хаҗга баручы бөтен Россия мөселманнарына зур ярдәм күрсәтүче Мостафа әфәнде 1910 елда гүр иясе була. Аның 3 улы кала [1].

Йолдыз сараенда хезмәт иткән тагын бер татар — Мәһмәт Кәрим (Мөхәммәткәрим) әфәнде. Без аның турында улы Хәсән Фәһминең автобиографиясе аша хәбәрдар булдык. Кызганыч, анда бу шәхес хакында тәфсилле мәгълүмат бирелмәгән.

Мәһмәт Кани паша [2] — Госманлы дәүләте чорында дәүләт бюрократлары арасында иң югары дәрәҗәгә ирешкән татар. Бу шәхес турында Габдерәшит Ибраһим «Бәянелхак» газетасының 1911 елда басылган «Төркиядәге татарлар» исемле мәкаләсендә аз гына мәгълүмат биреп узган [3]. Габдерәшит Ибраһим Мәһмәт Кани пашаның әтисе Петербург ахуннарыннан булуын язса да, аның турында җентекле мәгълүмат бирмәгән.

Мәһмәт Кани пашаның «Сиҗил-и Османи»дәге [4] кыска биографиясендә татар булуы турында иң тәфсилле мәгълүмат бирүче Мәһмәт Зәки Пакъалын [5] исә аның анапалы Мостафа агайның улы булуы, ә әнисенең рус милләтеннән булганлыгы турында яза [6].

Мәһмәт Кани паша 1805 елда Россиянең Анапа яки Пенза шәһәрендә туган. Аның Россиядәге тормышы турында мәгълүмат аз. Ул туган илендә берникадәр белем алганнан соң, мөгаен, югары белем алыр өчен, Истанбулга килгән һәм берникадәр француз мәктәбендә укыган. Аннан соң Каһирәдә хәрби белем алган. Мисырда укуын тәмамлагач, янәдән Истанбулга кайтып, «Баб-ы Али»дә [7] рус теленнән тәрҗемәче булып эшли башлый. 1851 елның 12 октябрендә Трикалага төбәк җитәкчесе итеп билгеләнә. Кани пашаның Трикаладагы җитәкчелек вазифасын үтәү гыйсъянчыларның баш күтәрү чорына туры килә. Аның монда башкарган иң әһәмиятле эшләренең берсе Трикаланың Бүлбүлҗә утравына урнашкан бандитларны табу һәм юкка чыгару була. Шулай ук Кани пашаның соңрак җирле идарә башлыгы булып эшләгән елларда бандитлык хәрәкәтләре кайнаган Айдын, Босния, Салоники кебек төбәкләрдә гыйсъянчыларны җиңүдә, тынычлык урнаштыруда зур уңышларга ирешкәнлеге мәгълүм. Аның Трикаладагы уңышлары алдагы карьерасында әһәмиятле роль уйный.

Кани пашаның Трикала җирле идарә башлыгы булу чоры бер ел чамасы дәвам итә. 1852 елның 11 октябрендә аның урынына Җаник төбәге җитәкчесе Васиф паша билгеләнгәч, Кани паша Истанбулга кайта. Трикала төбәге җирле идарә башлыгы булган чорда, гаиләсен үз янына алдыру өчен Мисырга барып кайту теләген белдерә. Шуннан чыгып, без аны Мисырда булган вакытта өйләнгән, дип фараз кыла алабыз [8]. Кызганыч ки, хатыны һәм хатынының ата-анасы, туганнары турында бернинди мәгълүмат юк. Кани пашаның оныгы Мәһмәт Ваһид эшчәнлеген өйрәнеп, докторлык диссертациясе язган Сәчкин Наип углы бәян иткәннәргә таянып, әлеге гаиләнең Мисырда байтак мөлкәтләре һәм бер

вакыфы булганлыгын, ягъни Кани пашаның бай Мисыр кешесе кызына өйләнгәнен чамаларга була. Шул ук көннәрдә штаб начальнигы (офицер) булган бертуган энесе Госман Нуринең дә гаиләсен китерү өчен Мисырга барып кайту үтенече хөкүмәт тарафыннан кабул ителә. Ләкин ул Мисырдан кайткан чакта, холера йоктырып, 1865 елда вафат була. Госман Нури пашаның Истанбулга килүенә һәм шәһәргә холера чире алып кайтуына сәбәпче булган Әхмәт пашага шелтә белдерелә [9].

Трикаладан Истанбулга кайткан Кани паша 1853 елының 13 маенда Финанс казначей躍ствосына комиссия рәисе итеп куела. Анда ул дәүләтнең финанс системасы өлкәсендә тәҗрибә туплый, бер үк вакытта яңа гына оешкан «Ширкәт-и Хәйрия» дип исемләнгән пароходчылык ширкәтендә дә эшли. Кырым сугышы чорында (1853-1856 еллар) Хәрби чыгымнар комиссиясе һәм Финанс идарәсе бухгалтерия бүлегендә хезмәт итә. Ә аннары Кипр утравында җирле идарә башлыгы, 1857-1859 елларда Босния, Салоники һәм Скопье губернаторы вазифаларын башкарган Кани паша 1859 елда товар таможнясы мөдире итеп билгеләнә һәм Госманлы дәүләтенең таможня эшләрен тәртипкә салуда гаять әһәмиятле эшләр башкара [10]. Соңрак финанс министры (1864 ел, март — 1865 ел, апрель), төзекләндерү эшләре министры (1873 ел, июль-октябрь), финанс министры (1878 ел, гыйнвар-август — 1879 ел, февраль-май) кәнәфиләрен били, шул ук елларда «Мәҗлес-и Аян»да [11] дәрәҗәле вазифа башкара. Аның французчадан хәрби мәсьәләләр буенча байтак тәрҗемә ителгән мәкаләләре бар. Мәһмәт Кани паша 1885 елда Истанбулда гүр иясе була.

Мәһмәд Кани пашаның Госманлы дәүләте файдасына куйган хезмәтләре өчен I, II, III дәрәҗә «Мәҗиди», «Госман» дип аталган батырлык һәм югары дәрәҗәдәге Хезмәт орденнарына лаек

Мәһмәд Кани паша

була. Шулай ук ул Франция, Россия, Австрия, Италия, Пруссия, Швеция, Норвегия дәүләтләренең дә төрле дәрәҗәдәге орден һәм медальләре белән бүләкләнә. Чыганакларда Кани пашаның рус, гарәп, итальян һәм француз телләрендә иркен аралашуы турында мәгълүматлар теркәлгән. Шулай ук ул гадел, гыйффәтле, акыллы, зирәк һәм сакчыл, исәп-хисап өлкәсендә оста шәхес буларак, таможня хезмәтен тәртипкә салган. Падишаһның шәхси хәзинәсе эшләрен алып баруы да аның ышанычлы һәм гадел дәүләт эшлеклесе икәнлеген раслый. Кани пашаның Европадан бурычка акча алганда Габделгазиз солтанга: «Әҗәтне күбрәк ал да Истанбулдан Батумига тимер юлы салдыр, акчаны сарай диварлары өчен тотма», — дигәне, ләкин падишаһның аның сүзләренә колак салмаганлыгы риваять ителә [12]. Чыганакларда Кани пашаның бик саран булуы искәртелә. Үзенә генерал дәрәҗәсе бирелүе ту-

Гобәйдулла Буби (уртада утырган) һәм Фатих Кәрими (аның уң ягында) Госманлы дәүләте уку йортларында белем алучы милләттәшләре арасында. Истанбул, 1896 ел

рындагы хәбәренең сөенчесе өчен акча яки алтын урынына бакчада үскән гөл өзеп биргәнлеге, улы Рифатның патша сараеннан ярәшкән кызы, ягъни булачак килене өчен кыйммәтле бүләк җибәрмәве сәбәпле, яшьләрнең кавыша алмыйча аерылулары да телгә алына.

Кани пашаның хатыны Хафизә ханымнан (?-1874) Мәрьям Шәрифә (?-1878), Гөлсем (?-1887), Фатыйма Шадия (?-13 октябрь, 1889), Әхмәт Рифат (1844-10 май, 1891), Гали Мухи (?-1893) исемле биш баласы була. Беренче хатыны Хафизә ханымның вафатыннан соң, 1874 елда никахланган Зөһрә ханымнан Мөнирә, Исмәгыйль Хаккы һәм Мәһмәт Ихсан исемле өч баласы туа. Кызы Мөнирә ханым һәм улы Исмәгыйль Хаккы турында мәгълүматлар юк. Тугыз яшендә этисез калган Мәһмәд Ихсан бәй, укуын тәмамлагач, 18 яшендә Эчке эшләр министрлыгы канцеляриясендә хезмәткәр булып эшли башлый. Соңрак Мадрид илчелегенә сәркатип итеп билгеләнә, ул дәвердә «Тәкаүд сандыгы» дип исемләнгән пенсия фондыннан алына торган хезмәт хакы түләнми башлагач, Министрлар Кабинетының чит илләр белән хезмәттәшлек идарәсенә күчерүләрен сорый, ә аннары садрәгъзәм [13] бүлегенә күчерелә. Бу шәхеснең тормышы турында мәгълүмат шуның белән өзелә.

Мәһмәт Кани пашаның Әхмәт Рифат исемле улы 1844 елда Истанбул каласында туа. Укуын бетергәч, «Баб-ы Али» тәрҗемә офисында эшли. Ә 1864 елда Петербургтагы Төркия консуллыгына күчерелә. 1864 елда Әдилә Солтанның кызы Хәйрия туташ белән ярәшә һәм фәриклек [14] званиесе бирелеп, Югары гаскәри мәҗлес әгъзасы булып сайлана. Белем алуын дәвам итәр өчен, Төркиянең Париждагы илчелегенә эшкә җибәрелә [15]. Әмма алты айдан соң ярәшкән кызы белән арасы бозылу сәбәпле, фәриклек чины кире алына. Әхмәт Рифат ике елдан соң илчелектәге эшен ташлый һәм Парижда яшәвен дәвам итә. Габделгазиз солтанның Парижга сәфәре

сәбәпле һәм Франция эчке эшләр министрының рәсми карары нигезендә, Әхмәт Рифат «Яшь төрекләр»нең алдынгы активистлары белән бергә Лондонга, аннан Мисырга китәргә мәҗбүр була. Мисырны инглизләр басып алгач, аны бу илдән куалар, ул яңадан Истанбулга кайта. Конья һәм Бурса шәһәрләрендә Режи идарәсендә [16] эшли. Аны хәтта бервакыт Багдатка Режи агенты итеп җибәрергә уйласалар да, соңрак бу карар тормышка ашмый кала [17]. Әхмәт Рифат авырый башлагач, Истанбулга кайта һәм Мәрмәр диңгезендәге Хәйбәлиада дигән утраугa ял итәргә китә, ләкин бер атнадан соң вафат була. Ул Истанбулдагы Топкапы районында әтисе җирләнгән Мәркәз әфәнде зиратына күмелә.

Әхмәт Рифатның үлеменнән соң кайбер әсәрләре 1891 елда «Барика-и Әдәб» («Әхлак яшене») дигән хезмәттә Бурсада басыла. Ул төрекләрнең алдынгы язучылары Али Суави һәм Нәмык Кәмал белән дус булган. Аның кайбер мәкаләләре Лондонда Али Суави тарафыннан чыгарыла торган «Лә мөхбир» һәм «Яңа госманлылар җәмгыяте»нең «Хөррият» газеталарында дөнья күрә. Әхмәт Рифат әфәнде француз хокук белгече P.Pradier-Fodéréнең «Гомуми хокук» исемле әсәрен төрекчәгә тәрҗемә итеп, 1868 елда Парижда, 1873 елда Истанбулда бастыра [18].

Әхмәт Рифат әфәнденең улы Мәһмәт Ваһид 1873 елның 2 гыйнварында Истанбулда туган. Ул 1897 елда «Кулэли» хәрби лицеен тәмамлагач, кавалерия офицерлыгы сыйныфында укый һәм аны уңышлы тәмамлый. Гаскәри хезмәтен калдырганнан соң, Госманлы дәүләтенең Гомуми бурычлар идарәсендә эшләп ала. Соңрак тарих белән кызыксына башлап, Сынлы сәнгать мәктәбендә [19] укыта. Тарих фәне үсешенә төрекчәгә әсәрләр тәрҗемә итеп, мөһим өлеш кертә. 1931 елда каты депрессия кичерә һәм үзүзенә кул салып һәлак була.

Мәһмәт әфәнде 1900 елда мәшһүр рәссам һәм музей эшлеклесе Госман Хәмди бәйнең кызы Ләйлә туташ белән гаилә корып, Нимәт һәм Хәмди исемле ике бала үстерәләр. Германия һәм Франциядә музыка сәнгате буенча белем алган Нимәт ханым Төркиянең тәүге опера җырчысы була. Ул 1930 елда Америкага күченеп китә һәм 2003 елда шунда бакыйлыкка күчә. Улы Хәмди Керман исә төрле хосусый ширкәтләрдә эшләп, 1985 елда гүр иясе була [20].

Алда язылганнардан аңлашылганча, мөһаҗир Мәһмәт Кани Истанбулда тырышлыгы аркасында дәүләт хезмәтенең иң югары баскычларына күтәрелгән. Аның тормыш юлы Госманлы дәүләтенең җитәкчелегенә матур мисал булып тора. Ә бит беренче буын мөһаҗирләр арасында министр дәрәҗәсенә җиткән кешеләрне очрату мөмкин түгел. Госманлы дәүләте тырыш, уңышка омтылган кешеләргә карьера үсеше өчен бюрократлыкның бөтен ишекләрен ачкан. Мәһмәт Кани паша кебек югары дәрәҗәдәге дәүләт эшлеклеләре арасында мөһаҗирләрнең саны шактый күп булуы билгеле.

XIX гасыр ахыры — XX йөз башларында Казан, Уфа, Самара, Оренбург кебек татарлар күпләп яшәгән төбәкләрдән Госманлы дәүләтенең Истанбул, Бәйрут, Салоники, Мәккә, Мәдинә калаларына белем эстәү максаты белән йөзләрчә шәкерт агылган. Ул чор татар матбугатыннан андый татар яшьләренең тагын да күбрәк булганлыгы аңлашыла. 1910 елда бер сәяхәте вакытында Казанда тукталган Җәләл Нури Иләри, Госманлы мәктәп һәм мәдрәсәләрендә уку шартлары яхшыра төшкән очракта, Россиядән елына ике мең шәкертне кабул итәргә мөмкин булганлыгын әйтә [21]. Габдерәшит Ибраһим исә 1906 елда Истанбулдагы һәр уку йортында 5-10 татар шәкерте укыганлыгын, хәтта Мәрҗан лицеенда татар студентлары өчен аерым сый-

ныф оештырылганлыгын белдерә [22]. Бәйруттагы Американ көллиятендә 1913 елда 12 татар шәкерте укый [23]. Истанбулдагы Мәрҗан, Вефа лицейлары, Солтани мәктәбе һәм Солоники гимназияләре татар студентлары арасында иң мәшһүр уку йортлары була. Бу шәкертләр арасында танылганнары — татар милләтенең булачак зыялылары Гобәйдулла Буби, Фатих Кәрими, Харис Фәйзи, Шәриф Камал, Мәхмүт Алмаев, Габдрахман Кәрим, Габдрахман Сәгъди һәм Габдерәшит Ибраһимов. Болар өстенә Истанбул, Багдат, Мәккә, Мәдинә кебек шәһәрләрдә укыган күпсанлы татар студентлары булуын да искәртеп узу кирәк. Әмма аларның төгәл санын әйтү кыен. Идел-Урал төбәгендә җәдитчелек хәрәкәтен әйдәп баручылар булып Госманлы дәүләтендә белем алган студентлар торган. Истанбулга укырга килгән Муса Акъегетзадә, Хәлим Сабит Шибай, Хәмит Зөбәер Кошай һәм Әхмәт Таҗетдин кебек шәкертләр, ватаннарына кире кайтмыйча яки кайта алмыйча Төркиядә калып, төрек мәгарифе һәм мәдәниятенә зур хезмәт куйганнар [24].

Студентлардан тыш төрле сәбәпләр белән, бигрәк тә хаҗга бару өчен Истанбулга килеп, госманлы зыялылары белән аралашып фикер туплаучылар да аз түгел. Габденнасыйр Курсави, Шиһабетдин Мәрҗани, Галиәсгар Камал, Дәрдмәнд, Муса Бигиев, Зыя Камали, Габдулла Баттал Таймас, Гаяз Исхакый, Габдулла Буби кебек гыйлем әһелләре төрле елларда Истанбулда яшәп алганнар. Төркиянең мәгарифе һәм мәдәни тормышына өлеш керткән татар зыялыларын биш төркемгә бүлергә була:

1. 1890 еллардан башлап Госманлы империясенә мөһаҗир булып килүчеләр: Йосыф Акчура, Габдерәшит Ибраһим.

2. Госманлы империясе чорында укырга дип килеп, ватаннарына кире кайтмый калучылар: Муса Акъегетзадә, Хәлим Сабит Шибай, Хәмит Зөбәер Кошай.

3. 1917 ел революциясеннән соң Россиядән качып, Төркиягә сыенучылар: Габдулла Баттал Таймас, Әкъдәс Нигъмәт Курат, Сәгадәт Чагатай, Әхмәт Тимер, Закир Кадыйри Уган.

4. Европа илләрендә яшәгәндә, Төркия җөмһүрияте оештыручы Ататөрекнең чакыруы буенча Төркиягә килүчеләр: Садри Максуди Арсал, Рәшит Рәхмәти Арат.

5. Икенче Бөтендөнья сугышыннан соң Япония һәм Кытайдан Төркиягә мөһаҗир булып килүчеләр: Надир Дәүләт, Мәхмүт Таһир.

Төрек мәгарифе һәм мәдәниятенә мөһим хезмәт керткән татар зыялыларының күп өлешен хәзерге Татарстаннан яки татарлар күпләп яшәгән Россиянең башка төбәкләреннән чыгучылар тәшкил итә. Ватаннарына хас үзенчәлекләрне торган урыннарындагы мохиттә дә чагылдырганга күрә, аларның нәсел-тамырларын өйрәнүе җиңел. Ә башка илләрдән чыкканнарның саны аз һәм аларның нәсел-тамырларын билгеләү дә шактый кыен.

Төркиянең мәгарифе һәм мәдәни тормышына өлеш кертүчеләрнең башында Муса Акъегетзадә (1865-1923) тора. Казанда «Хисаметдин менла» дип аталган беренче дөньяви татар повесте (1886) авторы буларак танылган Муса 1865 елның 3 декабрендә Пенза губернасы Чембар шәһәрендә дөньяга килгән. Башлангыч белемне бабасының авылында, Мачали мәдрәсәсендә ала башлый. Бирегә берничә ел укыгач, туган шәһәре Чембарга кайтып, 4 сыйныфлы рус мәктәбен тәмамлый. Аннан соң ата-анасы аны 1878 елда Пенза шәһәре гимназиясенә укырга җибәрә. Муса 1884 елда гимназияне уңышлы тәмамлап, 1888 елда югары белем алу нияте белән Истанбулга килә. Падишаһның әмере белән Мөлкия

мәктәбенең [25] югары белем бирә торган бүлегенә укырга керә. 1891 елда аны бик яхшы билгеләренә тәмамлый. 1892 елның 29 гыйнварында падишаһның боерыгы белән Хәрбия мәктәбенә [26] рус теле һәм икътисад укытучысы итеп билгеләнә. Акъегетзадә укытучы булып эшләгән чорда Ататөрек [27] тә шул ук уку йортында студент була. Муса Акъегетзадәнең, Ататөрекнең укытучысы булуы турында төгәл мәгълүмат булмаса да, Хәрбия нәшриятында басылган «Гыйльме сәрвәт яхут гыйльме икътисад» («Байлык фәне яки икътисад фәне») дигән әсәре Ататөрек студент булган елларда дәреслек буларак кулланылганлыгы төгәл билгеле.

Муса Акъегетзадәгә 1892 елның 13 февралендә өстәмә вазифа итеп Галата таможня идарәсендә тикшерү хезмәте (инспекторы) эше бирелә. 1893 елның 13 апрелендә бу өстәмә эш Сиркәҗи таможня мәркәзенә күчерелә. Муса Акъегетзадә II Мәшрүтият чорына [28] чаклы бу хезмәтендә кала, ә 1909 елның 16 гыйнварында Ван губернаторлыгының Адиҗеваз төбәгенә, 1910 елның 25 июлендә Хиҗаз төбәгендәге Мәмүрәт-үл Хәмид бистәсенә губернаторлыкның җирле идарә җитәкчесе итеп билгеләнә. 1910 елның 23 ноябрендә бу эшеннән азат ителә. Хезмәт хакы түләнсә дә, биш ай эшсез тора. 1911 елның 2 маенда Измир губернасының 4 нче округына, 1912 елның 14 маенда шул ук губернаның 6 нчы округына, 1912 елның 29 июлендә Халәп губернасына җибәрелә, 1913 елның 14 февралендә Хумус өязенең Таһрир-и Мусаккафат [29] комиссиясенә әгъза булып сайлана, 1914 елның 23 ноябрендә Чапакчур [30] өязенә губернаторлыкның җирле идарә җитәкчесе итеп куела. 1916 елның 23 сентябрендә, вазифасын үтәгәндә каты авырып китеп, янәдән Истанбулга кайтырга мәҗбүр була. Муса Акъегетзадә 1916 елның 3 декабрендә Эчке эшләр министрлыгына эшсезлек акчасы бирелүен сорап гариза яза. Ә 1923 елның 6 сентябрендә Истанбулның Чәнгәлкөй мәхәлләсендә вафат була.

Муса Акъегетзадә

Муса Акъегетзадәнең хезмәтләре: 1. Хисаметдин менла. — Казан, 1886; 2. Аурупа мәдәниятенә бер караш. — Истанбул, 1314/1889. 3. Икътисад яки байлык фәне: ирекле сәүдә һәм саклау ысулы. — Истанбул, 1316/1900. Авторның бу әсәрләреннән тыш «Мәтин» («Чынлык») һәм «Өч гәҗит» исемле газеталарда бастырылган күпсанлы мәкаләләре бар.

Муса Акъегетзадәдән тыш эшчәнлеге белән игътибарны үзенә җәлеп итүче татар — 1885 елдан башлап төрле сәбәпләр белән Истанбулга бик күп тапкыр килгән Габдерәшит Ибраһим (1857-1944). Ул Истанбулда чыгарган журналлары, оештырган конференцияләре, бастырган мәкаләләре белән татар халкын, татар мәдәниятен Төркиядә таныту эшендә үзеннән чиксез зур өлеш кертә. Бигрәк тә аның Себер төбәгендә яшәүче татарларны һәм I Бөтендөнья сугышы вакытында алманнарга әсир төшкән татар солдатларының Төркиягә күче-

нүен оештыруы игътибарга лаек. Габдерәшит Ибраһимов 1910 елда Ерак Көнчыгышка сәяхәтен тәмамлагач, Төркиягә килә. Төрек иле өчен гаять авыр еллар – Триполи, Балкан, Беренче Бөтендөнья сугышлары дәверендә Габдерәшит Ибраһим бөтен мөселман дөньясының төрекләр яклы булуына барлык көчен куя. Триполи сугышында катнашып, алгы сызыкта да, фронт чигендә дә яу оештыруга зур өлеш кертә. Балкан сугышлары чорында җир шарының төрле почмакларындагы мөселман халыкларына һәм Россиядә калган туганнарына, таныш-белешләренә хатлар язып, аларны зиярәт итеп, мөселман халыкларын бу сугышта төрекләрне якларга чакыра. Г.Ибраһимның тырышлыгы нәтиҗәсендә Россиядәге төрки халыклар һәм дөньяның төрле төбәкләреннән бик күп яшьләр Госманлы дәүләте сафында сугышыр өчен Төркиягә килә. Россиядә яшәүче мөселман төрки кызлары әлеге сугышта шәфкать туташы сыйфатында катнаша. Г.Ибраһимның тырышлыгы белән Һиндстан, Әфганстан, Япония, Малайзия, Кытай һәм тагын бик күп илләрдә Балкан сугышлары өчен иганә акчасы җыю оештырыла. Ул I Бөтендөнья сугышы чорында төрек хөкүмәте һәм Германия дәүләте ярдәме белән немецларга әсирлеккә төшкән татар һәм башкорт гаскәриләреннән «Азия батальоны» оештыртып, аларны Гыйрак фронтында инглизләргә каршы сугышырга җибәрттерә.

Г.Ибраһимның Ерак көнчыгыш сәяхәте турында хатирәләре Казанда «Дәвр-и Аләм» («Галәм дәвере») (1909), Истанбулда «Исламият дөньясы», Япониядә «Интишар-ы Исламият» («Ислам диненең таралышы)» (1912) дигән исемнәр белән басыла. 1910 елда Г.Ибраһим Истанбулда Әхмәт Таҗеддин белән бергә «Теаруф-и Мөслимин» («Мөселманнарны тану») дип аталган бер журнал нәшер итеп, Россия мөселманнарының хәле, ислам дөньясының проблемалары һәм мәгарифе турында мәкаләләр бастыра. Журналның утыз ике саны дөнья күрә. Бу казан татарларының Россиядән читтә чыгарылган беренче журналы буларак билгеле. 1912 елда Госман Җуди белән бергә «Ислам дөньясы» исемле тагын бер журнал нәшер итә. Анда Г.Ибраһимның Россия мөселманнарының торышы һәм ислам галәме турында мәкаләләре бар.

I Бөтендөнья сугышы вакытында Германия армиясе Россия белән сугышканда, шактый хәрбиләрне әсир төшерә. Алар арасында татарлар һәм башкортлар да байтак була. Әсирләр Берлинга якын Цоссен дип аталган лагерьга урнаштырыла. Германия белән Госманлы дәүләте бер сафта сугышканлыктан немецлар бу мөселман әсирләренә башкаларга караганда яхшырак мөгамәлә күрсәтә. Герман хөкүмәте белән Госманлы дәүләте арасындагы сөйләшүләрдә мөселман әсирләрен сугышта файдаланырга карар бирелә. Әнвәр паша Г.Ибраһим белән күрешкәч, аңа әлеге әсирләрне Госманлы дәүләте сафларында сугышыр өчен өндәргә куша. Г.Ибраһим бу вазифаны теләп кабул итә һәм Германиягә юл тота. Ул мөселман әсирләр урнашкан Цоссен лагерена барып, аларга Хәлифәнең дошманнарына каршы сугыш игълан итүен, бу җәһәттән мөселман халыкларның берберләренә ярдәмләшүләре кирәклеген аңлата. Әлеге сугышта Госманлы дәүләте җиңгән очракта, Россиядә яшәүче төрки милләтләрнең азатлыкка ирешә алачакларын белдерә. Г.Ибраһим татар әсирләрен Госманлы дәүләте армиясе сафларында хезмәт итәргә, инглиз һәм хәтта русларга каршы сугышырга өнди. Ул берүк вакытта Галимҗан Идриси белән бергә әсирләр өчен чыгарган «Әл-Җиһад» дип аталган газетада мәкаләләр дә бастыра.

Г.Ибраһим Берлинда булган чагын-

Мөселман хәрби токтыннарының Госманлы империясенә китү күренеше
Фоторәсем түбәндәге китаптан алынды: Исповеди в зеркале: Межконфессиональные отношения в центре Евразии (на примере Волго-Уральского региона — XVIII-XXI вв. / сост. и отв. ред. Стефан А.Дюдуаньюн, Ксавье Ле Торривеллек, Ольга Н.Сенюткина. — Н.Новгород, 2012. — С.478.

да үзенең Стокгольмдагы «Россиядәге чит милләтләр җәмгыяте»нә Россия мөселманнарының вәкиле итеп сайланганын ишетеп ала һәм май башларында Берлиннан Стокгольмга юлга чыга. Бу җәмгыять 1916 елның 18 маенда Стокгольмнан Америка дәүләте президенты Уилсонга телеграмма сугып, Россиядә рус булмаган милләтләргә юкка чыгу куркынычы янаганлыгын белдерә. Телеграмманы Габдерәшит Ибраһим, Йосыф Акчура, Али Хөсәензадә, Әхмәт Ага углы имзалый.

Г.Ибраһимга 1918 елда Хәрби министрлыкның куркынычсызлык идарәсе тарафыннан Швейцариядә Россия мөселманнары белән бәйле бер бюро оештыру вазифасы тәкъдим ителә. Аның белән Швейцариягә юлга чыгарга тиеш делегатлар исемлегенә Садретдин Хан, Нуретдин Ходайархан, Хөсәензадә Гали Бәй, Госман Токумбәт, Гатаулла Баһаэддин, Хәлим Сабит исемле шәхесләр дә кертелә. Санап узган бу кешеләрнең барысы да Россия мөселманнары вәкилләре була, аларның күбесе Европага тәүге тапкыр сәяхәт итә. Төрек хөкүмәте исеменнән Фуад Көпрүлү дә делегациягә алына. Әмма Германия белән Венгриядә барлыкка килгән чуалышлар нәтиҗәсендә бу делегация Венгриядән Киевка юнәлергә мәҗбүр була. Г.Ибраһимнан кала делегация әгъзаларының кайберләре туган илләренә, кайсыберләре Төркиягә кире кайтып китә. Ә Г.Ибраһим Истанбулдан килгән боерык буенча Киевта кала, анда ул яңа ачылачак илчелекнең оештыру эшләрен хәл итәргә, шул ук вакытта Киевта булган төрек ватандашларының, Украинадагы чуалышлардан зарар күрмичә, исән-имин Төркиягә барып җитүен кайгыртырга тиеш була.

Г.Ибраһим, Мәскәүдән кайтканнан соң, Истанбулда калган гаиләсе белән Конья губернасының Җиһанбәй районы Бөгрүдәлик авылына барып урнаша. Ул анда 1925-1933 еллар арасында сөрген хәлендә яшәде дияргә була. Без аның Мисыр һәм Һиҗазга берничә тапкыр сәяхәт кылганлыгын ачыкладык, ләкин алар хаҗ вакытына туры килгән

кыска вакытлы сәфәрләр була. Аеруча, Г.Ибраһим кебек бер зыялының авылда яши алуы да мөмкин түгел. Ул 1929-1933 еллар арасында гомеренең күп өлешен Конья (Бөгрүдәлик авылы), Истанбул, Каһирә һәм Һиҗазда уздыра. Г.Ибраһимның бик еш чит илләргә сәяхәт кылуын һәм актив эшчәнлеген өнәп бетермәгән төрек дәүләте аның өстеннән тикшерү эшләре алып бара башлый. Ул бу хәлгә бик борчыла, гаиләсен Төркиядә калдырып, 1933 елда Япониягә китеп бара һәм 1944 елда шунда вафат була. 1933 елда Берлинда Муса Бигиев тарафыннан бастырылган «Тарихның онытылган сәхифәләре» исемле әсәр Г.Ибраһимның хатирәләренә нигезләнгән. Анда 1921-1922 елларда Идел-Урал төбәгендәге ачлык белән бәйле күп мәгълүматлар китерелгән.

Бүген Төркиядә «төрекчелек» һәм «милләтчелек» диюгә беренче булып искә төшә торган шәхес, шөбһәсез, Йосыф Акчура (1876-1935). Мәшһүр Акчуриннар нәселеннән булган Йосыф Акчура Истанбул һәм Парижда белем алганнан соң, 1904-1908 елларда Казан, Мәскәү, Петербург кебек шәһәрләрдә яши. 1905 елгы инкыйлабтан соң Россия мөселманнарының сәяси эшләрен җитәкли һәм II Мәшрүтият (1908) игълан ителгәннән соң, Истанбулга килеп, «Төрек җәмгыяте»н оештыручыларның берсе, бүген дә нәшер ителә торган «Төрек йорты» журналының баш мөхәррире була. Й.Акчура Төркиянең бәйсезлек сугышында катнаша, җөмһүрият оешканнан соң, Карс шәһәреннән делегат булып сайланып, Төркия Бөек Милләт Мәҗлесендә (парламенты) хезмәт итә. Шулай ук Й.Акчура Төрек тарихы институтының рәисе була, Әнкарадагы Хокук мәктәбе һәм Истанбул университетының хәзерге чор сәяси тарих кафедрасында профессор буларак лекцияләр укый, икътисад һәм сәясәт белән бәйле күпсанлы хезмәтләр яза.

Йосыф Акчура

Йосыф Акчураның хезмәтләре:
1) Госманлы дәүләтенең оешуы һәм бу вакыйга белән бәйле чыганаклар. — Әнкара: Башвәкаләт Мөдевванат нәшрияты, 1933. — 14 б.; 2) Госманлы Дәүләтенең таралу дәвере: XVIII һәм XIX гасырларда. — Әнкара: Төрек тарих институты, 1985. — 174 б.; 3) Өч төрле сәясәт. — Әнкара: Төрек тарих институты, 1987. — 55 б.; 4) Төрек тарихының төп юнәлешләре: кереш бүлеге. — Әнкара: Мәгариф вәкаләте, 1931. — 87 б.; 5) Төрекчелекнең тарихы. — Истанбул: Кайнак матбагалары, 1998. — 184 б.; 6) Төрекчелек һәм чит илләрдәге төрекләр, 1345/1935, Истанбул: Токәр матбагалары, 1990. — 360 б.; 7) Яңа төрек дәүләтенең алдынгылары, 1928 ел. / Нәҗат Сәфәрче углы тәрҗемәсе. — Әнкара: Мәдәният министрлыгы, 1981. — 212 б.; 8) Заманыбыз — Ауропаның сәясәт тарихы: 4 нче уку елы. — Әнкара: Әнкара хокук факультеты, 1933. — 223 б.; 9) Заманыбыз — Ауропа сәясәт тарихы: 5 нче уку елы. — Әнкара: Әнкара хокук мәктәбе, 1930. — 255 б.; 10) Заманыбыз — Ауропаның сәясәт тарихы: 6 нчы уку елы. — Әнкара: Әнкара хокук факультеты, 1931. — 292 б.; 11) Схоластик укыту һәм Төркиядә схоластик ысул. / Хәсән Үндәр тәрҗемәсе. — Әнкара: Эпос матбагалары, 2002. — 127 б.

Белем алу өчен Төркиягә килеп, кире ватанына кайтмый калган Хәлим Сабит Шибай — «Берлек һәм Алгарыш» [31] чорында язган дәреслек китаплары һәм «Төрек йорты» жур-

налында басылган «Алтайларга таба» исемле мәкаләләр җыентыгы белән игътибар үзәгендә булган бер шәхес. Ул 1883 елда Сембер губернасы Кечкенә Тарханлы авылында дөньяга килә. 1890 елда Самараның яңа ысулда укытыла торган мәктәбендә башлангыч һәм урта белем ала. 1897 елда Сембердәге Олы Тархан авылында «Хәлимия» мәдрәсәсендә һәм рус гимназиясендә укый башлый. Соңрак Оренбургтагы «Хөсәения» мәдрәсәсенең мөдәррисе була. Башка казанлы иптәшләре кебек ул да белем эстәү өчен 1901 елда Истанбулга юл тота. Хәлим Сабит биредә «Мәрҗан» лицеена укырга керә. Шул ук вакытта Фатих мәчетендә ул чорның танылган галимнәренең берсе булган дагыстанлы Гәбделфәттаһ әфәнденең дәресләренә дә йөри. 1906 елның февраль аенда Мәрҗан лицеен тәмамлагач, дарелфөнүннең (Истанбул университеты) илаһият (теология) факультетына укырга керә. Аны 1910 елның июлендә тәмамлый. Төркестандагы төрки халыкларның тормыш итү рәвеше буенча тикшеренүләр алып бару өчен, озын сәяхәткә чыга. 1911 елның 2 октябрендә Казанга якын Зөябаш авылыннан Мәһмәт Рәхим (Мөхәммәтрәхим) Габдерразаковның кызы Зәлихә туташ белән гаилә кора. Ошбу сәяхәт турындагы язмалары, «Алтайларга таба» исемле мәкаләләр җыентыгы булып, «Төрек йорты» журналында дөнья күрә. Төркиягә әйләнеп кайткач, төрле мәдрәсәләрдә укыта, 1914-1919 елларда Истанбул университетында ислам һәм пәйгамбәрләр тарихы буенча лекцияләр укый. 1919-1939 елларда сәүдәгәрлек эше белән шөгыльләнә, күбрәк Европа илләрендә яши. 1939-1944 еллар арасында «Ислам энциклопедиясе» институтында һәм Дин эшләре министрлыгында эшли. Сабит Шибай 1946 елның 27 декабрендә Әнкарада гүр иясе була.

Аның «Сәбилүррешад», «Иҗтимагыять мәҗмугасы», «Яңа мәҗмуга», «Сыйрател-мөстәкыйм», «Билги мәҗмугасы», «Ислам мәҗмугасы», «Кырым мәҗмугасы», «Хикмәт», «Төрек йорты» кебек журналларда, «Вакыт» һәм «Җөмһүрият» газеталарында күпсанлы мәкаләләре белән бергә кайбер әсәрләре дә басыла.

Хәлим Сабит I Бөтендөнья сугышы вакытында немецларга әсир төшкән мөселманнар өчен Берлинда чыгып килә торган «Әл-җиһад» исемле газетаның татарча кушымтасында татар солдатлары өчен «Җиһад», «Һиҗрәт», «Бер милләт», « Һиҗрәт юллары» кебек 23 мәкалә язып бастыра [32]. Аның аеруча мәктәп укучылары өчен язган «Гыйлем өйрәтү дөньясы» (Истанбул, 1328/1332. — I-V т.), «Галимнәр һәм фән өйрәнүче шәкерт әфәнделәргә дәрес программасы мөнәсәбәте белән» (Истанбул, 1329) исемле китапчыклары берничә тапкыр басылып, авторның махсус премия белән бүләкләнүенә сәбәп була.

Габдерәшит Ибраһимның улы Әхмәт Мөнир Ибраһим (Искәр) да — әтисе кебек үк булмаса да, актив тормыш алып барган, төрек мәгарифе һәм мәдәниятенә хезмәт иткән бер татар. Ул, Россиядә, Истанбул һәм Япониядә белем алганнан соң, берникадәр Россия белән Япониядә эшләп ала. I Бөтендөнья сугышыннан соң Төркиядә урнашып, Әнкара мөгаллимәләре мәктәбендә, «Сүмәрбанк» һәм авыл хуҗалыгын механизацияләү өлкәсендә эшли. Әнкарада вафат була. Әтисе Япониядә булган елларда Казанда «Бәянелхак» газетасында эшли, әтисенең Япония һәм Ерак Көнчыгыштагы сәяхәте язмаларын «Дәвр-и галәм» (Казан, 2009) иseме белән бастырып чыгара. Япония шәкерте Әхмәт Мөнирнең Истанбулда чыккан «Сәбилүррешад» журналында байтак мәкаләсе басылганлыгы да билгеле.

Япониядә югары белем алган беренче татар студенты Әхмәт Мөнирнең басылган мәкаләләренең кайберләре:

Габдулла Баттал Таймас хатыны һәм малае белән

Бераз статистика // Сәбилүррешад. — 1330, 12 том, №307. — Б.365-366; Тышкы сәүдә — милләтләрнең сәгадәткә ирешү василәсе // Сәбилүррешад. — 1330 (6), 12 том, №302. — Б.290-291.; Япониядәге университет студентыннан Госманлы университеты студентына хат // Сәбилүррешад. — 1328 (2), 2-9 том, №52-234. — Б.450-451.; Токиода башлангыч белем // Сәбилүррешад. — 1329 (7), 10 том, №255. — Б.345-346.; Азия бөтен күркәмлеге белән уяна // Сәбилүррешад — 1330 (5), 12 том, №296. — Б.184.; 6 илгә бер илчелек: Токиода Чили илчелеге // Сәбилүррешад — 1330 (6), 12 том, №301. — Б.273-274.; Кытайның әзерлеге // Сәбилүррешад. — 1329 (11), 10 том, №240. — Б.102-103; Токиода халыкара бер ассамблея // Сәбилүррешад. — 1329 (10), 11 том, №270. — Б.155-156.; Япониядә дин мәсьәләсе // Сәбилүррешад. — 1328 (3) 1-8 том, №3. — Б.108-109.; Дин белән сәясәт бер-береннән аерылырга тиешме? // Сәбилүррешад. — 1330 (4), 12 том, №294. — Б.145-147.; Япония Микадосу Мутсуһито // Сәбилүррешад. — 1328 (9), 2-9 том, №31-213. — Б.96-98.; Хәлифәлек мәркәзендә // Сәбилүррешад. — 1328 (7), 1-8 том, №20-202. — Б.389-390.; Япониядә диңгезчелек сәүдәсе // Сәбилүррешад. — 1328 (7), 1-8 том, №22-204. — Б.426-427; Азиядә яңалык дәвере, 1330 (4), 12 том, №295. — Б.164-167; Токиода гомуми күргәзмә // Сәбилүррешад. — 1329 (5), 12 том, №300. — Б.255-257.; Дарелфөнүннең корылышына 30 ел тулу тантанасы // Сәбилүррешад. — 1329 (11), 11 том, №274. — Б.219-220.

Габдерәшит Ибраһимның кызы Фәүзия Ибраһим да Төркиядә «Хатын-кыз язмалары» дип исемләнгән беренче хатын-кыз журналларының берсен чыгара һәм Истанбулда кыз балалар өчен интернат мәктәп ача. Ул кулыннан килгәнчә төрек мәгариф һәм мәдәниятенә хезмәт итәргә тырышкан зыялы бер татар була. Мисырда яшәгән чорда әтисенең дусты Муса Бигиев авырып киткәч, бер шәфкать туташы кебек, баш очыннан аерылмый аңа хезмәт итә. Үзе чыгарган «Асар-ы Нисван», «Ислам мәҗмугасы» кебек журналларда басылган күпсанлы мәкаләләреннән кала «Кер юу һәм аны саклау» (Казан, 1911), «Органик химияне куллану» (Гомәр Сами белән бергә) (Истанбул, 1923), «Башлангыч мәктәпләрдә хисап фәнен укыту ысуллары» (Гомәр Сами белән) (Истанбул, 1916) кебек китаплар да нәшер итә.

Япониядә беренчеләрдән булып югары белем алган татар студентларының берсе — Хәсән Фәһми. Аның ата-анасының Истанбулга кайчан күченеп килүләре билгеле түгел, ләкин әтисе Мәһмәт Кәрим (Мөхәммәткәрим) әфәнде Йолдыз сараенда сержант булып хезмәт иткән.

Хәсән Фәһми 1886 елда Казанда дөньяга килә, башлангыч белемне дә шунда ала. Әти-әнисе белән Истан-

булга күченеп килгәч, белем алуын башта «Мәрҗан» лицеенда, соңрак «Солтания» гимназиясендә дәвам итә. 1910 елның 12 августында уку йортын «бик яхшы» билгеләренә тәмамлый. Озак та үтми, шул ук елның 14 августында, Әдернә губернасына башлангыч мәктәпләр инспекторы буларак билгеләнә. Шулай итеп, дәүләт эшенә керешә. Бу эшеннән ул 1911 елның 20 сентябрендә үз теләге белән чыга. Дәүләт аны Тәүфикъ һәм Әдһәм исемле иптәшләре белән бергә Японияга югары белем алырга җибәрә. Ул анда биш ел укыганнан соң, 1916 елның февраль аенда Истанбулга әйләнеп кайта. Хәсән Фәһми 1916 елның 21 мартында Әдернә губернасында башлангыч мәктәпләр инспекторы булып эшли башлый. 1917 елның 23 маенда укытучылар әзерли торган Әдернә кызлар мәктәбенә мөдир итеп билгеләнә. Ә 1918 елның 1 мартында кабаттан башлангыч мәктәпләр инспекторы итеп куела, ләкин бу эшен кабул итәргә теләмичә, чиновниклык эшеннән китә. Шул ук елны Әдернәдә вафат була.

Хәсән Фәһми, Япониядән кайткач, Госманлы хөкүмәтенә Япониянең сәяси хәле, Госманлы дәүләтенең Япония белән сәяси элемтәләр кору мөмкинлеге кебек мәсьәләләр буенча бер проект әзерли. Ул Госманлы хөкүмәтенә язган бер язуда үзеннән алдарак Япониядә булган Габдерәшит Ибраһим һәм аның улы Әхмәт Мөнирнең андагы эшчәнлекләре турында шикаять бирә. Хәсән Фәһминең бу язулары беркайда да басылмаган. Алар Госманлы архивында саклана.

Татар әдәбиятында беренче романы буларак кабул ителгән «Мәгыйшәт»нең (Казан, 1898) авторы, 1917 елның февраль инкыйлабы нәтиҗәсендә барлыкка килгән «Эчке Россия һәм Себер мөселманнары» милләт мәҗлесенең беренче рәисе Садри Максуди Арсал (1879-1957) тормышының 34 елын Россиядә, 11 елын Франциядә һәм

Садри Максуди

соңгы 32 елын Төркиядә үткәрә. Ул Мостафа Кәмал Ататөрекнең чакыруы буенча 1925 елда Франциядән Төркиягә күченеп килә. Садри Максуди төрки халыклар тарихы, теле, социологиясе, юриспруденциясе һәм хокук тарихы буенча бик күп әсәрләр яза, Истанбул университетының хокук факультетында лекцияләр укый. 1950 елда демократлар партиясеннән депутат булып сайланып, Төркиянең Бөек Милләт Мәҗлесендә хезмәт итә, хәтта президентлыкка кандидат та була. 1911 елдан соң аның исеме язучы Гаяз Исхакый белән бергә искә алына башлый.

Садри Максудиның хезмәтләре:

Хокукның гомуми нигезләре: хокукның позитив фәлсәфәсе. — Әнкара: Әнкара университетының хокук факультеты нәшрияты, 1937. — №1. — 214 б.; Хокук фәлсәфәсе тарихы: әхлак, хокук һәм дәүләтнең нигезе. — Истанбул: Хокук факультеты студентлар җәмгыяте, 1945. — Б.316.; Милләт тойгысының социологик нигезләре: милләт тойгысының социологик, психологик һәм тарихи нигезләре буенча тикшеренүләр. — Истанбул: Челтүт типографиясе, 1955. — Б.224; Төрек теле өчен. — Әнкара: Төрек учаклары фән-сәнгать вакыфы, 1930. — Б.517; Төрек тарихы һәм хокук: исламияттән алдагы чор. — Истанбул: Истанбул

университеты, 1947, №1. — Б.416; Гомуми хокук тарихы. 3 басма. — Истанбул: Истанбул университеты, 1948. — Б.532; Борынгы төркиләрдә Сой-Оймак оешмасының сакланган нигезләре белән борынгы грекларның Генос-Фратрия оешмасында һәм борынгы римлеләрнең Генсцурия оешмаларындагы нигезләрнең охшашлыгы турында. IV. Төрек тарих конгрессы чыгышлары. — Әнкара: Төрек тарих институты, 1952. — Б.64-109.

Хәзерге Башкортстанда дөньяга килеп, 1909 елда җизнәсе Ризаэтдин Фәхретдиннең инициативасы белән Төркиягә җибәрелгән фәннәр докторы Хәмит Зөбәер Кошай (1897-1984), большевиклар инкыйлабы сәбәпле, туган иленә кайта алмыйча, калган гомерен Төркиядә уздырырга мәҗбүр була. Ул Төркиядә заманча музейлар төзү һәм археологик тикшеренүләр алып баручыларның беренчеләреннән санала. Әнкара этнография музеен оештырып, аның беренче җитәкчесе була. Бүгенге Анадулыдагы мәдәниятләр музеена нигез сала. Хәмит Зөбәер Анатолиядә күпсанлы археологик казу эшләрендә катнашып, бу тикшеренүләр турында саллы хезмәтләр яза. Шулай ук ул Анадулы этнографиясе, фольклоры һәм төрек мәдәнияте буенча мәкаләләр авторы.

Хәмит Зөбәер Кошайның кайбер хезмәтләре:
Этнография музее белешмәсе. — Әнкара: Милли мәгариф министрлыгының Иске әсәрләр һәм музейлар идарәсе нәшрияты, 1963. — Б.20; Төрек фольклор тикшеренүләрендә чагыштырмалар һәм тарихи методка йөз тоту. I Халыкара төрек фольклор конгрессы чыгышлары. — Әнкара: Мәдәният министрылыгының Милли фольклор тикшеренү үзәге. I том, 1976. — Б.257; Алаҗаһөйүк һәм Гүллүҗәк казылмаларының нәтиҗәләре. IV Төрек тарихы конгрессы. — Әнкара: Төрек тарихы оешмасы, 1952. — Б.362-364. Борынгы төркиләрнең ана ватаны һәм ризык исемнәре. Төрек кухнясы симпозиумы чыгышлары. — Әнкара: Мәдәният һәм туризм министрлыгы, 1982. — Б.257; Төркия халкы телендәге ризык исемнәре. — Әнкара: Төрек тел корылышы, 1962. — Б.393; Кара кыргызларда йорт хайваннары белән бәйле сүзләр. Фуад Көпрүлүнең 60 яшьлек юбилее уңаеннан. — Әнкара: Әнкара университетының Тел, тарих һәм география факультеты, 1953.

Татарларның мәшһүр журналисты һәм язучысы Габдулла Баттал Таймас (1883-1969) та — 1925 елда Төркиягә сыенучыларның берсе. Ул 1927 елда Матбугат баш идарәсенә эшкә алына. Бер үк вакытта тарих һәм тел буенча гыйльми эшчәнлек алып бара. Төрле журналларда, шул исәптән «Төрек мәдәнияте», «Төрек йорты»нда байтак мәкаләсе басыла.

Габдулла Баттал Таймас хезмәтләре:
Ибнү-л-Мүһенна лөгать. — Әнкара: Мәгариф вәкиллеге, 1934. — III т. — Б.105.; Мин бер яктылык эзлим: кызыл дөнья. — Истанбул: «Таң» газетасы, 1962. — Б.209; Казан төрекчәсендә мәкаль һәм әйтемнәр. 2 нче басма. — Әнкара: Төрек тел оешмасы, 1988. — Б.151; Казан төрекләре. 2 нче басма. — Әнкара: Төрек мәдәниятен өйрәнү институты, 1966. — Б.239; Казанлы төрек мәшһүрләреннән — Галимҗан Баруди. — Истанбул: Сыралар нәшрияты, 1958. — Б.77.; Казанлы төрек мәшһүрләреннән — Муса Яруллаһ Биги. — Истанбул: Сыралар нәшрияты, 1958. — Б.61; Казанлы төрек мәшһүрләреннән — Ризаэтдин Фәхретдин. — Истанбул: нәшрият йорты, 1958. — Б.60; Казанлы төрек мәшһүрләреннән — ике Максудилар: Садри Арсал, Әхмәт Һади. — Истанбул: Сыралар нәшрияты, 1959. — Б.71; Рус инкыйлабы хатирәләре. — Истанбул: «Туран» мәдәният вакыфы, 2000. — Б.241.

Закир Кадыйри Уган (1878-1954) 1922 елда Төркиягә килеп сыена. Авторлык хокуклары һәм тәрҗемә мәркәзендә эшли, гарәп телен яхшы белгәнлектән, Ибн Хәлдун һәм башка күп кенә гарәп тарихчыларының әсәрләрен төрекчәгә тәрҗемә итүче һәм «Төрек йорты» журналына да мәкаләләр язган зат буларак билгеле.

Закир Кадыйри Уган хезмәтләре:
Милләтләр һәм хөкемдарлар тарихы. — 1 сан. 1 бүлек. — Әнкара: Милли мәгариф министрлыгы, 1965,. — Т.VIII — Б.443.; Милләтләр һәм хөкемдарлар тарихы. — №1. — 2 бүлек. — Әнкара: Милли мәгариф министрлыгы, 1965, — Б.449-822; Милләтләр һәм хөкемдарлар тарихы. 1 сан. 3 бүлек. — Әнкара: Милли мәгариф министрлыгы, 1965. — Б.823-1264; Милләтләр һәм хөкемдарлар тарихы. 2 сан. 1 бүлек. — Әнкара: Милли мәгариф министрлыгы, 1966. — Б.444; Милләтләр һәм хөкемдарлар тарихы. 2 сан. 2 бүлек. — Әнкара: Милли мәгариф министрлы-

гы, 1966. — Б.445-902; Әбү Зәйд Вәлийүддин Абдеррахман бине Мөхәммәт Ибн Хәлдун. Мөкатдимә. — Т.1 / тәрҗемә: Закир Кадыйри Уган. — Әнкара: Мәраиф вәкиллеге, 1954. — Т.XXIV — Б.715; Әбү-л-Аббас Әхмәт бине Яхья бине Җабир Белазүри. Фүтуһүл-бүлдан. — Т.1 / тәрҗемә: Закир Кадыйри Уган. — Әнкара: Мәгариф вәкиллеге, 1955. — Б.309; Әбү-л-Аббас Әхмәт бине Яхья бине Җабир Белазүри. Фүтуһүл-бүлдан. — Т.2. / тәрҗемә: Закир Кадыйри Уган. — Әнкара: Мәгариф вәкиллеге, 1956. — Б.411.

Искәрмәләр:

1. Габдерәшит Ибраһим. Мостафа әфәнденең вафаты // Бәянелхак. — 1911. — №893.
2. Паша — генерал.
3. Габдерәшит Ибраһим. Төркиядәге татарлар // Бәянелхак. — 1911. — №795.
4. Госманлы империясенең оешканнан алып XX гасыр башына кадәрге чорда мәшһүр булган 17 мең ир-ат һәм хатын-кыз турында мәгълүмат бирелгән автобиографик белешмәсе.
5. Госманлы тарихы буенча энциклопедик һәм автобиографик хезмәтләр авторы.
6. Мәһмәт Кани пашаның кыскача тормыш юлы турында Мәһмәд Сүррәянең «Сиҗилл-и Османи» (IV, İstanbul, 1308, Б.74-75) хезмәтендә, ә Финанс министры булган чорындагы хезмәтләре Мәһмәт Зәки Пакъалынның «Финанс министрлары тәртипләре» исемле әсәрендә киң мәгълүмат бирелә (II том, Б.66-96).
7. Госманлы дәүләте чорында Министрлар Кабинеты, Эчке эшләр министрлыгы һәм Югары хокук эшләре буенча Дәүләт шурасы урнашкан урын.
8. ОАТР, A. MKT.MHM., 47/68.
9. Мәһмәт Сүррәя. Сибилл-и Османи. — Истанбул, 1308. — Б.306-307.
10. Кани пашаның бу чордагы хезмәтләре белән бәйле язышулар: ОАТР, A. DVN., 113/61, A. DVN., 135/75, A. MKT.MHM., 165/96, A. MKT.MHM., 213/13, A. MKT.MHM., 469/21.
11. Парламенттан өстен оешма.
12. Кани пашаның улы Рифат бәй дә Госманлы дәүләтенең чит илләрдән бурычка акча алуына каршы чыгучыларның берсе була. «Хөррият» газетасында бастырган бер мәкаләсендә «Баб-ы Али» нең яңадан әҗәткә кермәячәгенә вәгъдә бирүенә карамастан, 125 миллион франклык яңа бурыч алырга планлаштыруы хәбәренә протестын белдерә. Кара: Хөррият. — 1285 (һиҗри). — №21.
13. Падишаһ исеменнән дәүләт эшләрен йөртүче иң югары дәрәҗәле зат.
14. Югары гаскәри чин.
15. ОАТР, A. MKT.MHM., 335/6.
16. Габделхәмит II падишаһлыгы дәверендә Госманлы дәүләтенең тәмәке монополиясен җитәкләүче оешмасы.
17. ОАТР, Y.A.HUS. 180/76.
18. Ибнүләмин Мәхмүт Кәмал Инал. Соңгы гасырның төрки шагыйрьләре. — Истанбул, 1988. — Б.1475-1478.
19. Хәзерге Мимар Синан сәнгать университеты.
20. Мәһмәд Вахит һәм гаиләсе турында киң мәгълүматны карагыз: Сәчкин Г.Наип углының «Нәфис сәнгать мәктәбендә сәнгать тарихына мөнәсәбәт һәм Вахит бәй» исемле (Хаҗәттәпә университетының Гуманитар фәннәр институты) докторлык диссертациясе. — Әнкара, 2008; Кахрамана Бостанҗы. Мәһмәд Вахит бәй һәм нәфис сәнгать буенча терминология трактаты. — Истанбул, 2003. — Б.1-11; Әдһәм Әлдәм. Осман Хәмди бәй сүзлеге. — Әнкара, 2010. — Б.407-408; Б.447.
21. Җәләл Нури. Төньяк хатирәләре. — Истанбул, 1330 (һиҗри). — Б.118.
22. Харис Фәйзи. Садретдин бәйгә мөрәҗәгать // Әлфәт. — 1906. — №17.
23. Йосыф Акчура. Сүриядән // Вакыт. — 1913. — №1183.
24. Бу турыда киңрәк мәгълүмат өчен карагыз: Надир Дәүләт. Төркиягә хезмәт иткән татар-башкортлар // Төркия җөмһүрияте дәүләтенең оешуы һәм үсешенә хезмәт керткән төрки дөнья зыялылары симпозиумы чыгышлары. — Кайсери: Әрҗиес университетының Төрек дөньясы тикшеренү институты мәркәзе, 1996. — Б.161-173.
25. Дәүләт хезмәте өчен кадрлар әзерләү мәктәбе.
26. Югары хәрби академия.
27. Ататөрек Хәрбия мәктәбенә 1898 елның 13 апрелендә укырга кереп, аны 1902 елның 10 февралендә тәмамлый.
28. Госманлы дәүләте конституциясенең, 29 ел кулланылмый торганнан соң, 1908 елның 24 июлендә яңадан игълан ителеп, 1922 елның 5 ноябрендә Госманлы дәүләтенең ликвидацияләнүе белән гамәлдән чыккан дәвере.
29. Вакыфларга бәйле оешмаларның теркәлү бүлеге.
30. Элек Диярбакырга караган торак пункт.
31. 1889 елда оешып, 1908-1918 еллар арасында дәүләт хакимиятен кыска-кыска вакытларга үз кулына алган, төрекчелек идеологиясен алга сөргән бер партия.
32. Ваһдәт Кәләшелмаз. Бөтендөнья сугышында әсир гаскәрләр арасында панисламизм пропагандасын ясау омтылышы // Кәбикәч. — 2000. — №10.

Төрекчәдән ***Рушания Алтай*** *тәрҗемәсе*

Дәвамы алдагы санда

ТАШЛАР СЕРЕ

(«ТҮГӘРӘК ӨСТӘЛ»)

БЕЗ «ЧЫН МИРАС» ЖУРНАЛЫ РЕДАКЦИЯСЕНӘ ТАРИХ ФӘНЕНЕҢ БЕР ЮНӘЛЕШЕ БУЛГАН ЭПИГРАФИКА ТАРМАГЫ БЕЛГЕЧЛӘРЕН ЧАКЫРДЫК. ЭПИГРАФИКА – КАТЫ ӨСЛЕККӘ ЯЗЫЛГАН (ТАШ, КЕРАМИКА, ТИМЕР һ.Б.) ЯЗУЛАРНЫ ӨЙРӘНӘ ТОРГАН ФӘН. ШУЛАР АРАСЫНДА ИҢ КҮП САКЛАНГАН ҺӘМ БҮГЕН ДӘ КҮПЛӘП ЯЗЫЛА ТОРГАННАРЫ – КАБЕР ТАШЛАРЫ.

Ф.Мәрсетдинов фотосы

ТР Кукмара районы Мәчкәрә авылы зиратында кабер ташы уку. Сулдан уңга: галим Раиф Мәрданов, авыл имамы Мөнир Йосыпов, Кукмара районы мәгариф бүлеге мөдире Роберт Мансуров, галим Ирек Һадиев. 2012 ел

Катнашалар:

Марсель ӘХМӘТҖАНОВ — филология фәннәре докторы, Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының өлкән фәнни хезмәткәре;

Җәмил МӨХӘММӘТШИН — тарих фәннәре кандидаты, Болгар дәүләт тарих-архитектура музей-тыюлыгының фәнни хезмәткәре;

Ирек ҺАДИЕВ — ТР Милли китапханәсенең директор урынбасары;

Раиф МӘРДАНОВ — филология фәннәре кандидаты, ТР Милли китапханәсе кулъязмалар һәм сирәк китаплар бүлегенең өлкән фәнни хезмәткәре;

Илдус ЗАҺИДУЛЛИН — тарих фәннәре докторы, ТР Фәннәр академиясе Ш.Мәрҗани исемендәге Тарих институтының урта гасырлар тарихы бүлеге мөдире, «Чын мирас» журналының бүлек мөхәррире.



Илдус Заһидуллин.

Хөрмәтле кунаклар, коллегалар! Сез барыгыз да — олуг галимнәр, озак еллар максатчан һәм нәтиҗәле эшләп, төрле төбәкләрдә экспедицияләрдә булып, яңа ачышларыгыз, табышларыгыз белән фәнни җәмәгатьчелекне һәм халыкны шатландырып киләсез. Россия Федерациясенең һәр төбәгендә төрле гасырларга караган мөселман зиратлары бар, аларда эпитафик һәйкәлләр саклана. Татарстаннан читтә, әйтик, Башкортстанда, Мәскәү, Санкт-Петербург кебек фәнни үзәкләрдә татар эпиграфикасы белгечләре эшлиләрме, аларның хезмәтләре белән сез танышмы?

Марсель Әхмәтҗанов. Уфада кабер ташларын профессиональ дәрәҗәдә өйрәнүче галим юк. Мин Башкортстаннан Венер Усмановның хезмәтләрен күзәтеп барам. Дөрес, ул хезмәтләрендә текстларны рәссам буларак матур эшләгән, ләкин еш кына төгәл укылыш килеп чыкмаган. Ул, нигездә, ташларны укып түгел, ә күчереп яза. Шул сәбәпле кайбер сүзләр, нокталар, хәрефләр, иҗекләр төшеп кала. Гарәби язулы ташларны өйрәнер өчен, гарәп телен, догалардан өзекләрне укый белү өстенә иске татар телен дә камил белергә кирәк. Шулай ук кабер ташларында тарихи әһәмияткә ия борынгы исемнәр бар, бу исемнәрне уку да катлаулы хезмәт.

Узган ел Марий-Эл Республикасының Бәрәңге районында XVII гасыр ахыры — XVIII йөз башларында яшәгән мәгърифәтче, галим Рәфыйк Курсави нәселенең 300 еллыгына багышлап «Нәсел тамырлары» дип исемләнгән икетомлы китап чыкты. Бу хезмәтне басмага шушы нәселдән булган Рәйханә Гаязова әзерләде.

Ирек Һадиев.

Башка төбәкләрдә татар эпиграфикасын өйрәнүчеләр һәм аларның гыйльми эшләре булса, матбугатта яки махсус фәнни җыентыкларда мәкаләләр күренер иде. Әмма аларның ни Мәскәүдә, ни Санкт-Петербургта, ни Уфада, ни Әстерханда, ни Оренбургта, ни Самарада басылып чыгуы турында мәгълүматыбыз юк. Элек тә эпиграфист галимнәр бармак белән генә санарлык булган, хәзер дә алар күп түгел.

Илдус Заһидуллин. Узган 2012 ел Татарстан Республикасының тарихи-мәдәни мирасы елы дип игълан ителгән иде. Моның ташъязмаларны өйрәнүгә, саклауга йогынтысы булдымы?

Ирек Һадиев. 2012 елны Татарстан Республикасының тарихи-мәдәни мирасы елы дип игълан итү бик уңай күренеш, кирәкле гамәл булды дип саныйм. Ләкин эпиграфика, борынгы ташбилгеләрне өйрәнү һәм саклау җәһәтеннән чыгып караганда, бу мәсьәләне кузгатып җибәрүгә аның әллә ни зур тәэсире булмады. Төп игътибар архитектура истәлекләренә юнәлтелде. Шулай да кайбер адымнар ясалуга сәбәп булды. Безне Татарстан Дәүләт Советының Мәдәният, фән, мәгариф һәм милли мәсьәләләр комитетының махсус утырышына да чакырдылар. Анда зиратлар, зиратлардагы тарихи истәлекләрне саклау мәсьәләсе кузгатылды. Әмма тарихи мирасны саклауга турыдан-туры җаваплы булган дәүләт оешмалары тарафыннан нәкъ менә эпиграфик истәлекләрне өйрәнү юнәлешендә төгәл гамәлләр башкарылмады. Яңа гына кабул ителгән «Мирас» программасы нигезендә, Дәүләт Советы югарылыгында киләчәктә, бәлки, бу мәсьәлә җайга салыныр дигән өмет бар.

Илдус Заһидуллин. Соңгы елларда сезнең тарафтан кайсы төбәкләрнең эпиграфик истәлекләре җентекләп өйрәнелде?

Марсель Әхмәтҗанов. Марий-Эл Республикасының Бәрәңге районында 2011 елда Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты оештырган комплекслы экспедициягә кушылып, күп авыл зиратларын өйрәнеп чыктым. Төбәктә дистәләгән каберлек бар. Минем өчен, беренче чиратта, танылган фамилияләр, ташбилгенең эпиграфик тексты, поэтик өлге-теләкләре булган ташлар кызыклы иде. Пенза, Мордовия, Рязань өлкәләрендәге кабер ташлары турында басылмаган 60 битлек кулъязмам ята. Бу төбәкләрдә Худяковлар (күбрәк Кудяков формасында) фамилиясе бик еш очрый. Димәк, атаклы тарихчы М.Худяков үзенең нәсел-тамырлары белән татар булган дип уйларга нигез бар. Ул юкка гына татар тарихы белән кызыксынмаган, ә үз туган тамырларын өйрәнгән икән. Пенза, Тамбов өлкәләрендәге татар зиратларында бик борынгы ташлар бардыр дип уйламыйм, шулай да тарихи фамилияләр язылган ташларны теркәргә кирәк.

Мин шулай ук Башкортстан Республикасы, Курган, Свердловск, Чиләбе өлкәләре шәһәрләренә барып, мөселман зиратларын өйрәндем. Кызганыч, бу төбәкләрдә дә Казан каласындагы кебек үк борынгы каберлекләрне бетерәләр. XIX гасыр — XX йөз башында куелган ташлар бик аз сакланган. Әлеге төбәкләрдәге дөрбәләр дә кызыклы. Татар зиратларындагы дөрбәләр турында фәнни хезмәт язу белән мәшгульмен, ул китап тиздән дөнья күрер дип уйлыйм. Шулай ук таш кисеп ясаучыларның һәм язучыларның исемнәрен барлау да мөһим. Бу шәхесләр исемлегенең бер өлешен «Татар энциклопедиясе»нә бирдем. Киләчәктә татар ташбилгеләре иҗат итүчеләр турында аерым бер китап язу сорала. Таш кисеп эшләү — тарихи яктан бик кызыклы күренеш. Патша хөкүмәте татарга таш кисеп эшләүне тыйганнан соң да, бу һөнәр яңадан үсеш алган. Ташка язучы осталар әлеге төр сәнгатьтә гаять гүзәл әйберләр тудырганнар. Төрле төбәкләрдәге кабер ташларын системалы өйрәнеп, осталарга бирелгән заказның ареалын белергә була. Әйтик, Буа шәһәрендә Гарифҗан Бу-

ави *(Мөхәммәдгариф Хәсән хаҗи улы Вәлиди. — Ред.)* дигән оста яшәгән. Минемчә, ул танылган мәгърифәтче Җамал Вәлидинең кардәше булырга тиеш. Гарифҗан Буавиның таш ясау эшчәнлеге 1912 елдан башлана. Аның үз стиле бар, шигырьләре һәм ташының формасы аерылып тора. Ул эшләгән ташларның биеклеге — 40-45 см, ә киңлеге — 15 см. Гарифҗан Буави ташларның күбесендә үз исемен язып калдырган. *(Кара: Гарифҗан Буави (тууына 130 ел) // Гасырлар авазы — Эхо веков. — 2009. —№2 — Ред.)* Миңа күптән түгел Чүпрәле районы Яңа Задур авылыннан фотоматериаллар китерделәр. Карасам, нәкъ Буа төбәгендәге кебек ташлар! Боларны Задур авылыннан Вәлиэддин Задури исемле оста эшләгән. Вәлиэддин Задури ташлары XIX гасыр ахырында куела башлый. Бу фактлардан төрле төбәкләрдә таш ясаучы осталарның үзенә күрә бер мәктәбе булганлыгы турында фикер әйтергә мөмкин.

Касыйм каласы татар зиратындагы ядкәрләр дә шактый җимерелгән. Мондагы ташлар, дөрбәләр турында «Татар археологиясе» журналында саллы гына мәкаләм басылып чыкты *(Кара: Татарская археология. — 2006, №1-2 (16-17). — Ред.)*

Җәмил Мөхәммәтшин.

Ульяновск өлкәсенең көньяк-көнбатышында, Пенза өлкәсенең көньяк-көнчыгышында яшәүче татарларның эпиграфик һәйкәлләрен өйрәнү максатыннан оештырылган экспедиция барышында, ике өлкәнең 22 авылында булып, 70кә якын һәйкәлне өйрәнеп чыктык. Алар арасында тамгалы ташлар, комташына уеп язылган һәйкәлләр дә бар. Сирәк кенә чын сәнгать әсәре булырдай, зәвык белән эшләнгән матур гарәби язулы гранит ташлар да очрап куя. Әлегә кадәр бу як татарлары арасында кабер ташы кую традициясе булмаган дигән фикер яши иде. Димәк, безнең экспедиция зур табыш белән кайтты, дияргә була. Безгә очраган гарәп язулы иң борынгы таш 1805 елгысы дип уйлыйм (Муратовка авылы).

Каберләрнең өске өлеше турында бер-ике сүз әйтеп китик. Ул якларда каберне таш белән әйләндереп алып, 80-100 см биеклектә җир өяләр. Мәетнең баш очына биегрәк итеп гади таш куела. Бу төр каберләр зиратларда күп сакланган. Ләкин кабер иясенең кем икәнен белеп булмый. Бер-ике буыннан соң онытылмасын өчен, башта тамгалы таш, аннары Коръән кәлимәсе язылган таш, ә соңыннан инде исемнәр һәм мәрхүмнең үлгән еллары күрсәтелә башлый.

Татарстанның Әлмәт ягында ташларны утыртып куймыйлар, кладкага өяләр. Бәлки аларның алдында язулы такта да куелгандыр. Мәсәлән, Ульяновск өлкәсенең Иске Кулатка районы Зимничә авылында да шундый бер такта сакланган. Зурлыгы 6х50х43 см булган комташыннан эшләнгән бу такта таш өеме өстенә куелган. Таш иясе Ибраһим бине Салих (1837-1900) Зимничә авылында икенче мәхәллә имамы була.

Инде кабер ташларына килсәк, аларның бер төркеме начар сыйфатлы таштан эшләнгән. Турыпочмак яисә өчпочмак формасында, язулары каллиграфик язу түгел. Бик начар сыйфатлы текст 2-3 юлдан тора. Икенче төркем ташлар Казан җирлеге ташларыннан аерылмый: зурлыгы, язу стиле, тексты, орнамент-бизәкләре шундый ук.

Беренче төркем җирле традицияләр нигезендә үссә, икенчесе Казан, Каргалы традицияләрен дәвам итә. Зимничәнең Хәбибулла атлы ишаны һәм аның улы Габделваһаб Чистай, Казан мәдрәсәләрендә белем ала. Ә Гали

авылында ташларны Сафиулла Каргалый яза. Сирәк кенә кабер өстенә тегермән ташы куюю традициясе дә булган. Мисалга Татар Сайманы, Иске Атлаш авыллары зиратларын китерергә мөмкин.

Марсель Әхмәтҗанов. Мәскәүдәге зиратларны өйрәнү әлегә актуаль булып кала. Мин 1980 елларда Габдрахман Таһирҗанов архивы белән танышу максатыннан Ленинградта булган чакта, Волково зиратын өйрәнеп, кабер ташларындагы язмаларны күчереп алдым. Бу мәгълүматлар Петербургтагы милләттәшләребезнең кайсы төбәклэрдән килеп урнашуын хәбәр итә. Язмалардан күренгәнчә, бирегә татарлар XIX гасырда хәзерге Татарстан җирлегеннән түгел, ә Касыйм, Пенза, Түбән Новгород, Рязань тирәләреннән күчеп утырган. Кабер ташларында борынгы татар фамилияләре дә сакланган. Фольклорчылар, тел һәм музыка белгечләре, Санкт-Петербургтагы «Якташлык» җәмгыяте белән элемтәгә кереп, шушы фамилияләр нигезендә җирле татар мәдәниятен өйрәнә ала. Кабер ташларындагы даталар мәрхүмнәрнең уртача гомер озынлыкларын күрсәтә. Боларның күбесе 77-80 яшьләрдә бакый дөньяга күчкән. Күрүебезчә, эпитафик язмалар шул чордагы демографик вазгыятьне өйрәнү өчен дә кызыклы тарихи чыганак булып тора. Әйтергә кирәк, мәрхүмнәрнең исем-фамилияләрен язуда зур хаталар да җибәргәннәр. Якын киләчәктә ул хаталарны төзәтеп, сүзлекчә төзеп чыгарырга ниятлим.

Илдус Заһидуллин. Эпиграфик экспедицияләр ни рәвешле оештырыла? Аларны кем финанслый? Кем заказ бирә? Оештыру эшләре ничек бара?

Раиф Мәрданов. Энтузиазм белән бара. Мәсәлән, безнең эшләрне нигезле рәвештә финанслау булмады. Ирек Һадиев — Кукмара районыннан, ә мин

— Әгерже төбәгеннән. Үз алдыбызга туган якларыбызның эпиграфик истәлекләрен барлыйк әле, дигән максат куйдык та 1998 елдан башлап Кукмара, Әгерже районнары татар зиратларын тулаем өйрәнеп чыктык. Гарәпчә язылган, фәнни яктан әһәмиятле булган кабер ташларын теркәдек, фоторәсемгә төшердек, текстларын укыдык һәм язып алдык.

Туган төбәкләребездән кала, Саба, Балтач, Алабуга, Менделеевск, Киров өлкәсенең һәм Удмуртия Республикасының берничә районындагы татар кабер ташларын өйрәндек. Тупланган материалларны тәртипкә салып, компьютерда бастырып куйдык. Узган Тарихи-мәдәни мирас елында шушы әзер хезмәтләрне нәшер итеп була иде. Әмма безгә бергәләп эшлик, дип мөрәҗәгать итүче булмады. Ә бит мондый китаплар җирле халык өчен бик тә кирәк. Кабер ташларында ата-бабаларның исемнәрен барлау, шәҗәрәләр төзү өчен шактый зур мәгълүмат теркәлгән. Алабуга районында татар авыллары күп түгел, ләкин бу төбәк без тикшергән районнардан эпиграфик истәлекләргә иң бае, җәмгысе — 400дән артык таш. Алабуга районындагы Морт авылының бер зиратында гына да (авылда ике зират) 130 ташъязма теркәдек. Аларның ниндиләре генә юк! Авылның мөәзине Мөхәммәдзакир Шакир улы таш уючы булган. Бу төбәктәге ташларның күбесе аның тарафыннан язылган. Мөхәммәдзакир мөәзин ташлары башка районнардагы зиратларда да очрый. Аның ташлары зәвыклы һәм нәфис, затлы бизәлгән, текстлары эчтәлекле һәм бай мәгълүматка ия, матур каллиграфияле булулары белән үзенчәлекле.

Марсель Әхмәтҗанов. Бу шәхеснең үзенә багышлап бер монография язарлык!

Раиф Мәрданов. Чыннан да, ташъязмалар — бик әһәмиятле тарихи чыганак. Һәр районның татар зиратларында милләтебез тарихында, әдәбиятында һәм мәдәниятендә исемнәре танылган, каберләре билгесез шәхесләрнең ташларын очратабыз. Бик еш кына алар ватылган яки авып яткан була. Булдыра алсак, үзебез күтәреп куябыз. Булдыра алмасак, башка кешеләрне ярдәмгә чакырырга туры килә.

Әйткәнемчә, мондый экспедиция-сәфәрләр төп эшебезнең планына кермәгән. Мөмкин булганда, барып эшлик әле дип тырышабыз. Фәнни, дәүләт оешмаларының планында бу эшне гамәлгә ашыруга акча каралу-каралмавын белмибез.

Илдус Заһидуллин. Бу юнәлештә Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтында эшләр ничек тора?

Марсель Әхмәтҗанов. ТӘҺСИдә дә шундый ук хәл. Институтта эпиграфиканы максатчан өйрәнү 1940 елларда Һарун Йосыпов тарафыннан башланган һәм 1970 еллар азагында Фәрит Хәкимҗанов белән тәмамланган. Мин экспедицияләргә чыкканда, археографик максаттан, кулъязмалар җыйнау өчен чыга идем. Шул вакытта топонимиканы да, риваятьләрне дә, эпиграфиканы да өйрәнеп бардым.Соңгы өч елда Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты җитәкчелеге комплекслы экспедицияләр составында максатчан эпиграфик командировкалар оештыра башлады. Шуның нәтиҗәсе буларак, Татарстан Республикасының Актаныш, Кукмара, Чүпрәле районнары, Удмуртия Республикасының кайбер районнары тикшерелде. Әмма бар җирне дә бер-ике кеше тарафыннан гына йөреп бетерү мөмкин түгел. Безгә бу эшкә яшь егетләрне күбрәк җәлеп итәсе иде. Кызганыч, соңгы елларда аспирантура күбрәк кызлар килә, ә алар зиратларга керергә куркалар.

Ирек Һадиев. Татарлар яшәгән төбәкләрдә белгечләрнең әллә ничә төркеме кабер ташларын гомер буе өйрәнгәндә дә, бер-берсенә конкурент булырлык түгел.

Фото Л.Гобәйдуллин архивыннан

Красноярск крае Олы Морта районы Казанка авылы зиратындагы бура чардуган.
2008 елда төшерелгән

Илдус Заһидуллин. Кабер ташларының якынча хисабы билгелеме?

Раиф Мәрданов. Якынча исәп белән Татарстанда гына да гарәби язулы, 1930 елларга кадәрге ташлар 10 меңнән артык. Менә аларның барысы да өйрәнелергә тиеш бит…

Илдус Заһидуллин. Эпиграфик истәлекләрне өйрәнергә заказ бирүчеләр бармы?

Ирек Һадиев. «Шундый таш бар, шуны килеп карагыз әле», — дип әйтүчеләр бик аз. Мәсәлән, Балтачка Җәлил хәзрәт Фазлыев чакырып алгач, Бөрбаш зираты ташларын укыдык. Мәчкәрәдә Үтәмешевләргә багышланган конференция алдыннан: «Кайтыгыз әле, оныклары да кайта, менә бу таш кемнеке, монысы кемнеке, әйтеп бирегез әле», — дип чакырганнары булды. Болар бик сирәк очраклар гына.

Җәмил Мөхәммәтшин. Мин Ютазы, Азнакай, Сарман, Чүпрәле төбәкләрендәге кабер ташларын район хакимиятләре тәкъдиме белән өйрәндем. Ульяновск өлкәсе Иске Кулаткадагы тарихи истәлекләр турында да хезмәтем чыгачак, дөрес, анда 10-15 кенә таш урын алачак, әмма алар зур әһәмияткә ия. Бу да заказлы басма булачак. Мондый очракта мин ничек телим, шулай итеп эшли алмыйм инде. Мәсьәләнең шул ягы да бар.

Марсель Әхмәтҗанов. Апас районы җитәкчеләре белән килешү нигезендә китап язылды, кабер ташлары да өйрәнелде. Әмма китапның кульязмасы биш ел басылганын көтеп, архивта ятты. Соңгы көннәрдә генә басылып

чыгачагы турында хәбәр килде. Менә шундый хәлләр дә булырга мөмкин.

Илдус Заһидуллин. Без әле һаман да гарәп имлясындагы ташлар турында сөйләшәбез. 1929-1939 елларда латин графикасы гамәлгә куела. Бу күренеш кабер ташларында чагылыш тапканмы?

Марсель Әхмәтҗанов. Ул заманнарда таш кисеп ясаучы осталарны тыйганнар, әгәр дә кабер ташы ясаганны белсәләр, төрмәгә утыртканнар. Таш кисү осталары 1950 еллардан соң гына яңадан күренә башлый. Бу елларга кадәрге ташлар бик сирәк очрый.

Илдус Заһидуллин. Үзенә күрә дингә каршы көрәшнең бер элементы булгандыр инде...

Раиф Мәрданов. Алабуга районы Морт авылындагы кабер ташы язучы оста турында сөйләдем бит. Аның бер ягына гарәп, ә бер ягына латин хәрефләре белән язган ташларын күргәнебез бар.

Илдус Заһидуллин. Татар эпиграфика сәнгатенә Госманлы дәүләте һәм Урта Азиянең йогынтысы булганмы? Гомумән, татарлар ул җирлекләрдәге традицияләрне кабул иткәнме? Әллә безнең ташларыбыз үзенчәлекле истәлекме?

Марсель Әхмәтҗанов. Үзенчәлекле ядкәрләр. Бiредә Урта Азия белән дә, Төркия белән дә бернинди охшашлык юк. Константинопольне алган вакытта куелган ташлар бик примитив, кечкенә, язулары да гади, ә безнең инде ул вакытта 110-120 см биеклектә, 50-60 см киңлектә матур итеп язылган ташлар булган.

Илдус Заһидуллин. Ә XIX гасыр мисалында карасак?

Марсель Әхмәтҗанов. Каргалы белән Оренбург татар зираты ташларына берникадәр тәэсир бар. Чөнки аларның зыялылары Кырымга, Төркиягә йөз тоткан. Шулай ук төрек теленең әдәби телгә йогынтысы көчле булган. Моның өчен Риза Фәхреддин телен искә алу да җитә. Ә Урта Идел буе эпитафикасында мондый тәэсир күзәтелми. Гомумән алганда, зур йогынты бер төбәктә дә юк.

Әлегә Әстерхан өлкәсе ташъязма истәлекләре җентекләп тикшерелмәгән. Аларда «сондык таш»лар («сандык таш»лар, ягъни кабер өстендә гори-

Фотолар М.Әхмәтҗанов архивыннан

«Свердловскидагы татар зиратының киләчәге аяныч». Таштан ясалган дөрбә эчендәге кабер ташы

Дөрбә янәшәсендә генә агач төбенә охшатып эшләнгән кабер ташы. 2009 елда төшерелгән

зонталь яткан ташлар) бар. Шулай ук Әлмәттәге бер авылда да «сондык таш»лар очрады. Бу күренеш мине бик гаҗәпләндерде. Андый ташлар төрек солтаннары, Бакчасарайдагы Кырым ханнарының каберлекләрен хәтерләтә. Миңа калса, бу — Алтын Урда тәэсире. Чөнки Төркиядә урта гасырлардан килгән мондый традиция юк.

Илдус Заһидуллин. Рус патшаларының каберләрендә дә шундый ташлар бар…

Марсель Әхмәтҗанов. Бу да Алтын Урда тәэсире. Без бу күренешне үзебезнең традицияләргә бәйләп аңлатабыз. Касыйм шәһәрендәге чиркәү янында 1730 елларга нисбәтле бер ак таш «гражданский стиль»дә татарлар тәэсире белән русча язылган. Рус шәһәрләрендә кабер ташларын күпләп кую 1860 еллардан соң гына башлана.

Җәмил Мөхәммәтшин. Мин дә Урта Азия һәм Төркия тәэсирен күрмим. Безнең кабер ташлары бик үзенчәлекле. Төркиянең тәэсире XIX гасыр татар кабер ташларындагы ярымайларда һәм туграларда чагыла. Ә татар эпиграфикасының Казахстан җирлегенә тәэсире ачыктан-ачык билгеле. Казахстанда яссы ташлар татар йогынтысында куела башлаган.

Марсель Әхмәтҗанов. Казахстан — Мангышлак дигән Нугай Урдасы формалашкан җир. Ул тирәдәге кабер ташлары белән Каргалы зиратындагылар арасында кайбер охшашлыклар күзгә ташлана. Бу мөнәсәбәтләрне махсус өйрәнү шарт. Казах үзе таш куймаган. Дөрбә корган да шуның стенасына ыруын, мәрхүмнең исемен язган. Ә катлаулы структуралы текстлар юк. Мин 1981 елда Ташкентта тел һәм әдәбият галиме Җәвад Алмазның архивын өйрәндем. Җәвад Алмазны казах галимнәре Мангышлак ягындагы Нугай Урдасыннан калган зиратларны өйрәнү өчен җәлеп иткәннәр һәм ул анда барып эшләгән. Җәвад Алмаз архивында бу ташларның йөзләрчә фотолары бар һәм чыганаклар беркайда да басылмаган. Безнең төбәктә дә ташларның яңаруы Нугай Урдасыннан килмәдеме икән? Шул исәптән бу гомумтөрки эпитафия традицияләре белән дә турыдан-туры бәйле. Нугай Урдасы ташларында язулар аз, ә бизәк-орнаментлар күп. Шулай ук Кавказда яшәүче нугай татарларының кабер ташларында да язу аз, орнамент күп. Ул бизәкләрдә казахныкы белән дә охшашлык бар. Димәк, казахларга да Нугай Урдасы эпиграфик сәнгатенең үрнәкләре үтеп кергән, дип әйтергә була.

Илдус Заһидуллин. Татар зиратларында дөрбәләрнең саны билгелеме?

Марсель Әхмәтҗанов. Бер иллеләп дөрбә Троицк, Каргалы, Уфа, Касыйм, Пенза төбәкләрендә сакланган.

Илдус Заһидуллин. Татар эпиграфик культурасының чуваш, мари, удмурт кебек күрше милләтләргә йогынтысы нинди? Чувашларда кабер ташлары бармы?

Җәмил Мөхәммәтшин. Бер чуваш авылы зиратында тәре өстенә тәре тезеләп киткән, әмма бер җирдә бик матур язылган мөселман кабер ташы тора. Чувашлар арасында мөселманнар да булган. Миңа шундый 20ләп мөселман чувашының кабер ташы мәгълүм.

Марсель Әхмәтҗанов. Мәҗүси чувашларда да ташлар бар. Анда кеше исеме язылган. Таш уртасында өчпочмак сыман тишек бар.

Илдус Заһидуллин. Галимнәр мариларда, бигрәк тә мәҗүсиләр зиратларында, кабер ташлары табалар. Алар арасында татар хәрефләре белән дә, рус хәрефләре белән дә язылганнары бар. Бу да, мөгаен, татарлар йогынтысыдыр.

Сез — зиратларда күп йөргән, аларны җентекләп тикшергән галимнәр.

Фото Ж.Мөхәммәтшин архивыннан

Галим Җәмил Мөхәммәтшин Ульяновск өлкәсе Иске Кулатка районы Татар Шомалак авылы зиратындагы кабер ташын өйрәнә. 2011 ел

Хәзерге татар эпиграфика фәнендә нинди проблемалар бар?

Марсель Әхмәтҗанов. Кислоталы яңгырлар таштагы язуларга зыян сала. XVI гасыр ташлары 1970 елларда әйбәт кенә торалар иде, хәзер аларның язуын укырлык түгел. Ташның сыйфаты төрле төбәктә төрлечә. Әйтик, Касыйм, Пенза якларында алар бик уалучан, безнең Идел буенда шактый каты, Троицк төбәгендәге Ахун авылында кабер ташлары граниттан эшләнгән. Гранит ташларны укырга шактый авыр. Алар сай гына язылганнар, кояш төшсә, ялтырыйлар, ә фоторәсеме аша уку турында сүз дә була алмый. Аның каравы гранит чыдам, ватылмый, табигать тәэсиренә дә бирешми.

Ирек Һадиев. Чынлап та, соңгы 30 ел эчендә начар экологик халәт йогынтысында тарихи кабер ташлары бик нык зарарланды. Безгә эпиграфиканы өйрәнүне ашыктырырга кирәк...

Марсель Әхмәтҗанов. Троицкида 200-300 ташны өйрәндем. Кесәдәге мең сум акча белән 4-5 көн эчендә мин нәрсә өйрәнә алам? Бу чыганакларны өйрәнүне ашыктырырга кирәк. Свердловскидагы татар зиратының киләчәге аяныч, чөнки бу зират янында зур төзелеш бара. Зират капкасыннан килеп керүгә, мәрхүмнәрнең заманында бу төбәккә Зөя ягы, Акъегет авылларыннан күчеп килгәнен күрәсең.

timyash.ru

Лениногорск районы Тимәш авылында шагыйрь Габдерәхим Утыз Имәни кабере өстендәге дөрбә. 2010 елда төшерелгән

Димәк, зират исән вакытта Свердловск шәһәре татарларының кайсы төбәкләрдән килеп утыруын ачыклап була. Зиратны саклап калмасак, вакытында кабер ташларын өйрәнмәсәк, тарихи тамырларга балта чабабыз дигән сүз.

Ирек Һадиев. Әле узган ел Оренбург шәһәренең татар-мөселман зираты белән өстән-өстән генә булса да танышырга туры килде. Анда дала ягы булгач, зиратта бездәге шикелле куе урман кебек шаулап агачлар үсеп утырмый. Монда кабер ташлары ачык күренеп, гаҗәеп бер манзара хасил итеп тора. Аларның исәбен-санын болай гына әйтү мөмкин түгел. Дөрес, Оренбургта, элек-электән татар эзе нык булу сәбәпле, бу зиратка көчле зарар ясалмагандыр. Ул коймалап алынган, шактый тәртипле, шулай булса да, ташлар берәм-берәм югалып бара... Кайсылары сынган-ватылган, җиргә баткан, язулары җуелган... Бу зираттагы ташларга да мәрхүмнәрнең Оренбургка кайсы төбәктән килгән булуы язып куелган. Әлеге мәгълүматлар төбәкләр, халыклар бәйләнешен өйрәнү өчен дә бик кызыклы. Шулай ук, татарлар белән казахларның кабер ташларын чагыштырып, кызыклы нәтиҗәләр ясарга мөмкин. Бу зират — үзе бер фәнни дөнья. Төп проблема — кабер ташларының югалып баруы, сакланышларының начар булуы һәм аларны өйрәнүче белгечләр юклыгы.

Марсель Әхмәтҗанов. Бездә бит, шәһәрләрдә, татар зират культурасы бар. Оренбург шәһәрендәге зират — шуның бер мисалы. Бу калада тагын да борынгырак, күренекле кешеләребез җирләнгән зиратны узган гасырның 30-40 нчы елларында җимереп ташлаганнар. Анда мәшһүр галим-имамнарның кабер ташлары була.

Татар зират культурасы турында сөйләгәндә, янә бер кызыклы күренеш — борынгыдан килгән бура культурасын да онытырга ярамый. Буралар беткәч, такталардан ясалган чардуганнар барлыкка килә, ә аннан соң рәшәткәле чардуганнар куела. Соңгы елларда арматурадан эшләнгән чыбык чардуганнар кую гадәти хәл. Аларның кайберләре зиратта шулкадәр коточкыч булып тора ки, кабергә якын да килеп булмый. Күгәреп беткән тимерләре белән дә чиркандыралар. Шул ук вакытта сәнгати дәрәҗәдә камил, матур итеп эшләнгән чардуган-

нар да еш очрый. Аларда төсләрнең, орнаментларның уйнавы, арматураларны бөгеп, матурлап, зәвыклап ясалган детальләр өйрәнүгә лаек. Татар чардуганнарын да өйрәнергә кирәк, чөнки мондый гүзәл, нәфис, югары сәнгать башка бер милләттә дә юк. Аларның типларын, төрләрен күрсәтеп, альбомнар чыгару актуаль. Безнең хәзерге кустарлар, акча артыннан куып, зәвыксыз әйберләр коялар. Мәрмәр кисәгенә матур итеп язган булалар да берәр елдан ул язу яңгыр белән юкка чыга, укырлыгы калмый. Ә бит ташлар бер-ике ел өчен генә куелмый, алар йөзләрчә ел торырга тиеш. Бүген безгә Болгар, Алтын Урда чоры эпиграфикасы кызык булган кебек, киләчәк буын өчен хәзерге заман эпиграфикасы, зират культурасы кызыклы булачак. Шуңа күрә эпиграфика остаханәләрен яңарту кирәк. Алар борынгы традицияләрне үстерергә, дәвам итәргә, бездә таш кисеп ясау сәнгате булганлыгын күрсәтергә тиеш. Борынгы гореф-гадәтләрне өзмәскә кирәк.

Кызганыч, соңгы елларда кабер ташларына портрет кую җанны әрнетә. Бу рәсем ташларга ямьсез кыяфәт биреп тора, ә зиратта кичкә калганда, күңелгә әллә нинди вәсвәсәләр килә. Ташка портрет кую татар халкына хас традиция түгел.

Безнең тарихчыларыбызга кабер ташларын, эпиграфик чыганакларны файдалану өлкәсендә бик күп эшләргә кирәк. Ташларны, зиратларны, дөрбәләрне комплекслы өйрәнү дә актуаль.

Безгә эпиграфист галимнәребезне дә онытырга ярамый. Һарун Йосыпов [1], Фәрит Хәкимҗановларның [2] эшләрен еш искә алып торырга кирәк. Гали Рәхим [3] турында матур гына китап дөнья күрде, ләкин аны эпиграфика остасы, ташларны тарихи чыганак буларак кулланучы белгеч итеп аерым хезмәттә күрсәтү кирәк. Каюм Насыйри [4], Риза Фәхреддин [5] кебек мәгърифәтчеләребезне яд итеп тору шарт. Алар бит бөек хезмәтләр башкарган.

Илдус Заһидуллин. Зиратларны һәм кабер ташларын саклап калу һәм өйрәнү өчен, нәрсәләр эшләргә кирәк? Авыл җирләрендә аларны саклау, өйрәнү буенча җәмәгатьчелекне, дин әһелләрен, авыл картларын һәм муниципаль органнар белән һәрбер авыл зиратының «паспорт»ын — планы, ташларның урнашу схемасы, исемлеге, әһәмиятле кабер ташларының тасвирламалары һәм фотосурәтләре булган кыскача тарихи белешмә ролен үтәүче документ эшләргә вакыт җитмәдеме икән?

Җәмил Мөхәммәтшин. Иң төп мәсьәлә — бик сыйфатлы фото тупланмалар эшләргә һәм ташларның каталогларын төзергә кирәк. Әгәр дә моны эшләсәк, яшьләр шуларга карап өйрәнә алыр иде. Раиф Мәрданов, Ирек Һадиев [6], Марсель Әхмәтҗанов [7] хезмәтләре минем өстәлемдә тора. Мин һәрвакыт аларга мөрәҗәгать итәм.

Ирек Һадиев. Кызганыч, китапларда зур, төсле фотолар бирү мөмкинлеге

чикләнгән. Кечкенә генә аклы-каралы фотодан тексттагы язуны, таш өслегендәге бизәк-орнаментларны анык күреп булмый.

Илдус Заһидуллин. Кабер ташлары буенча даими чыга торган җыентык гамәлгә куелса, яхшы булыр, анда һәр белгеч фоторәсемнәр, ташларның укылышы, үлчәмнәре, алар турында мәкаләләр белән катнаша алыр иде.

Марсель Әхмәтҗанов. Татар эпиграфикасының халәте, торышы турында бер конференция оештырырга да кирәк. Безнең китаплар нибары 200-300 данә тираж белән чыга. Әле анысын да мин үз кесәмнән акча чыгарып бастырам. Әлбәттә, бу китаплар халыкка барып җитми.

Илдус Заһидуллин. Ташларны саклау дигәннән, бәлки, җимерелә торган ташларны авыл музейларына, мәчет яннарына күчерергә кирәктер?

Марсель Әхмәтҗанов. Ябык бинага куйсаң да ярар иде.

Раиф Мәрданов. Кабер ташларын саклауга җитди әһәмият бирелергә тиеш. Экспедицияләрдә йөргәндә, зираттан читтә, аерым бер урыннарда да борынгы кабер ташлары очрый. Андыйларны урынында килеш сакларга кирәк бит инде. Кайбер авылларда халык, артык кызыксынып китеп: «Без аны мәчеткә, я булмаса, зиратка кайтарып куярбыз», — диләр. Ничек инде нык торган ташны кубарып йөрисең? Авып, сынып яткан булса, бер хәл. Менә шулай ялгыш юлда «иҗтиһад» итүчеләр дә бар. Бервакыт: «Авыл музеенда таш бар», — дигәч, шунда кердек. Анда ремонт төгәлләнеп килә иде, ләкин таш юк… Музейның җаваплы кешесе эзләде-эзләде, таба алмады. Ахыр чиктә: «Күрәсең, эшчеләр анының икәнен аңламаганнардыр һәм таш идән астында калгандыр», — дигән фикер әйтте…

Марсель Әхмәтҗанов. Лениногорск районы Тимәш авылындагы шагыйрь Габдерәхим Утыз Имәнинең (1754-1834) кабер ташы өстенә кечкенә дөрбә корып куйганнар. Моны күп авылларда эшләргә мөмкин. Бу гамәл яшь буынны тәрбияләү, тарихи аң кузгату өчен бик тә файдалы, шулай ук дөрбә сәяхәт итеп йөрүчеләргә дә кызыклы урын булыр иде.

Раиф Мәрданов. Кабер ташларына тарихчыларның мөнәсәбәте төрлечә. Безгә археологлар белән дә аралашырга туры килә. Әгәр Болгар, Алтын Урда дәвере ташлары турында сүз бармый икән, алар: «Әй, бу бит яңа таш», — дип кул гына селтиләр. Меңьеллык таш булса, ул аларга кызык. Югыйсә, Мәрҗаниләр, Г.Тукайлар заманы да тарих, ул чор ташларына да без битараф булырга тиеш түгел.

Илдус Заһидуллин. Кызганыч ки, бу өлкәдә планлы рәвештә эшләү җитенкерәми. Үзебезнең республикада гына да кабер ташларын өйрәнеп чыга алмыйбыз. Аны бит оештыру артык зур проблема түгел?!

Ирек Һадиев. Без инде оештыру мәсьәләләре белән дә шөгыльләнә башласак, кадерле вакытны шуңа исраф итсәк, зиратларга кем барыр? Хакимият даирәләренә дә мөрәҗәгать итеп карадык, кызганыч, аңлаучы табылмый.

Марсель Әхмәтҗанов. Кабер ташларына бит сәнгать, мирас дип карау юк. Бәлки карарлар иде дә, ташъязма культурасы руста юк. Рус авылы зиратына керсәң, анда череп беткән агач тәреләр, ә ташлар юк.

Ирек Һадиев. Тарихи ядкәрләргә яшь буынның игътибарын җәлеп итүгә килсәк, хәлләр бөтенләй үк аяныч түгел. Мәктәпләрдә үткәрелгән конференцияләрдә, очрашуларда без сөйләгән чыгышлардан соң яшь буынның колагына азмы-күпме мәгълүмат керде, алар: «Кара әле, безнең авылның зиратында да шундый таш бар икән, моны Казаннан ук килеп карыйлар икән», — дип уйлана башлый. Андыйлар авылларның зиратын чистарту өмәләрендә теләп катнаша, берничә мәктәп укучысының, тарихи ташларны фотога төшереп, безнең электрон почтага җибәргәне булды.

Кукмарадагы төбәкне өйрәнү музее директоры Ләбүдә ханым Дәүләтшина һәм музей хезмәткәрләре эпиграфик экспедицияләр вакытында күп авылларга безнең белән йөрде, мәсьәләнең җитдилеген аңладылар. Берәр ел уздымы икән, район хакимиятеннән һәм иганәчеләрдән акча юнәтеп, XVII гасырга нисбәтле ташларга чардуганнар куйдырдылар. Күп авылларда зиратларны тәртипкә китерә башладылар.

Фидакарь милләттәшебез Азат Сәйфетдинев инициативасы белән «tashlar.narod.ru» сайты эшләвен дә әйтергә кирәк. Бу сайтта кабер ташлары турында бик күп мәкаләләр, фәнни хезмәтләр урын алган. Фоторәсемнәр дә куелган. Сайт белән халык бик нык кызыксына. Бу — бик әйбәт тупланма.

Илдус Заһидуллин. Хөрмәтле галимнәр! Татар эпиграфикасы фәненә багышланган «түгәрәк өстәл»гә килгәнегез өчен зур рәхмәт! «Чын мирас» журналы редакциясе киләчәктә дә фикердәшегез булыр, сезнең хезмәтләрегезне халкыбызга пропагандалау, киң катлам укучыга җиткерүдә үз өлешен кертер дип ышанасы килә. Сезгә киләчәктә яңа иҗат уңышлары теләп калабыз.

Искәрмәләр:

1. Юсупов Г.В. Татарские эпиграфические памятники XV в. (К вопросу о происхождении Казанских татар). — М.-Л., 1951; Юсупов Г.В. Введение в булгаро-татарскую эпиграфику. — М.-Л., 1960. — 287 с. *(Ред.)*
2. Хакимзянов Ф.С. Язык эпитафий волжских булгар. — М.: Наука, 1978. — С.5-7; Хакимзянов Ф.С. Эпиграфические памятники Волжской Булгарии и их язык. — М.: Наука, 1987. — 191 с.; Мухаметшин Д.Г., Хакимзянов Ф.С. Эпиграфические памятники народа Булгара. — Казань: Тат.кн.изд-во, 1987. — 128 с. *(Ред.)*
3. 2008 елда текстологлар Раиф Мәрданов һәм Ирек Һадиев тарафыннан төзелеп, басмага хәзерләнеп, «Рухият» нәшриятында дөнья күргән «Гали Рәхим: тарихи-документаль, әдәби һәм библиографик җыентык» китабында галимнең «Татарские эпиграфические памятники XVI века», «О двух татарских надгробных памятниках XVII века», «Болгаро-татарские эпиграфические памятники в Вятском крае» исемле мәкаләләре урын алган. *(Ред.)*
4. Насыйри К. Зөя өязе авыллары. Сайланма әсәрләр. Дүрт томда: 3 том. — Казан: Татар. кит.нәшр., 2005. *(Ред.)*
5. Мәгърифәтче, тарихчы Ризаэддин Фәхреддин үзенең мәшһүр «Асар» исемле фәнни биобиблиографик хезмәтендә һәм «Шура» журналында басылган «Мәшһүр адәмнәр һәм олуг хәдисәләр» сәхифәсенә кергән мәкаләләр сериясендә еш кына кабер ташларына мөрәҗәгать итә. Бу турыда кара: Байбулатова Л.Ф. «Асар» Ризы Фахреддина: источниковая основа и значение свода. — Казань: Татар.кн.изд-во, 2006. — С.87-91; Фәхреддин Р. Мәшһүр адәмнәр: «Шура» журналыннан мәкаләләр / Төз. Ленар Гобәйдуллин, Рамил Миңнуллин. — Казан: Рухият, 2012. *(Ред.)*
6. Мәрданов Р.Ф., Һадиев И.Г. Әгерҗе төбәгенең ташъязма истәлекләре. — Казан: «Тамга» нәшрияты, 2008. — 148 б. *(Ред.)*
7. Әхмәтҗанов М.И. Ташбилгеләргә язылган татар әдәбияты үрнәкләре. — Казан, 2011. — 215 б. *(Рецензияне кара: Чын мирас. — 2012. — №5-6 (Ред.))*

БЕРТУГАН ХӨСӘЕНЕВЛӘР КАБЕРЛӘРЕНӘ КУЕЛГАН ТАШЪЯЗМА ИСТӘЛЕКЛӘР

ИРЕК ҺАДИЕВ,
Татарстан Республикасы Милли китапханәсе директорының фәнни эшләр буенча урынбасары

Бертуган Хөсәеневләр: Әхмәд (1837-1906), Мәхмүд (1839-1910), Гани (1839-1902) — мәшһүр татар сәүдәгәрләре, җәмәгать эшлеклеләре һәм хәйриячеиганәчеләр. Ерак бабалары Мамадыш өязенең Кибәхуҗа авылыннан чыккан, аталары Мөхәммәдгали Оренбург янындагы Каргалы бистәсе сәүдәгәре булган. Өч бертуган Оренбургта, Урта Азия һәм Европа шәһәрләрендә сәүдә йортлары тотканнар, байлыкларының шактый зур өлешен сарыф итеп, Казан, Оренбург, Уфа, Самара губерналарында күпсанлы мәктәп-мәдрәсәләр ачканнар һәм аларны, шәкертләргә гыйлем биргән мөгаллимнәрне акчалата тәэмин итеп торганнар, мәчетләр төзеткәннәр, татарча басмаханә нигезләгәннәр, сәләтле яшьләрне стипендия түләп чит илләрдә укытканнар.

Әлеге танылган затларның исемнәре белән бәйле һәм истәлекләрен бүгенгәчә саклый торган матди һәм рухи мирас ядкәрләре аз түгел. Оренбург һәм Казанның мөселман зиратларында Хөсәеневләрнең фани дөньядагы гомерләренә үзенчәлекле нокта куйган, тәрҗемәи хәлләренә йомгак ясаган, шул ук вакытта бу нәсел тарихы һәм, гомумән, милли тарихыбыз өчен кызыклы мәгълүматлар хәбәр иткән кабер ташлары бар.

Хөсәеневләрнең өлкәне Әхмәд бай 1906 елның 10 декабрендә Казанда вафат булган һәм шәһәрнең Яңа Татар бистәсендәге мөселман зиратында җирләнгән. Каберенә заманы өчен һәм шәхеснең дәрәҗәсенә күрә шактый ук зур таш (үлчәмнәре: биеклеге — 156 см, киңлеге — 45 см, калынлыгы — 23 см) куелган (1 нче фоторәсем). Ул зиратның хәзер 5 нче сан белән билгеләнгән юлындагы (аллеясындагы) элеккеге һәм заманча кабер ташларыннан биеклеге белән аерылып тора, табигый бурташны (известняк) татар кабер ташларына хас традицион калыпта эшкәртеп ясалган, кирпечләрдән тезелеп, измә белән катырылган аскуймага (постаментка) утыртылган. Алгы як өслегенә гарәп язуының тәгъликъ төре белән татарча текст уелган, өслек исә урыны-урыны белән ашалып, коелып, язудагы кайбер хәрефләр, сүзләр бозылып, юкка чыгып бара. Текстта, шәхеснең исеме, атасының исеме, фамилиясе, бу дөньяда ничә ел яшәве, кайчан вафат булуы белдерелүдән тыш, өстәмә мәгълүмат та бирелгән — кылган игелекле гамәлләренең кыскача гына нәтиҗәсе әйтелгән. Өстән аска таба 7 юл-өлешкә бүлеп, горизонталь рәвештә язылган текст түбәндәгечә:

1. Әхмәд бай
2. Гали угылы Хөсәенев дин вә гыйлем
3. өчен хәятында күп һиммәт сарыф

1 нче фоторәсем

4. итеп ахырында йөз мең сумга
5. кариб васыять кыйлып алтмыш тукыз
6. яшендә сикезенче зөлкагъдә 1324 сәнә
7. унынчы декабрьдә 1906 сәнә миладия дөньядан.

Журналга укучылар күреп танышсын, ә белгечләр гыйльми тикшеренүләрендә файдалансын өчен, әлеге кабер ташының һәм алга таба тасвирланачак башка ташъязма истәлекләрнең төсле фотосурәтләрен дә тәкъдим итәбез.

***

Мәхмүд бай һәм Гани бай Хөсәеневләрнең каберләре Оренбург шәһәренең хәзерге Җиңү проспекты буйлап урнашкан мөселман зиратында.

Кара гранитны бизәкләп кисеп, сырлап, гаҗәеп үзенчәлекле һәм затлы формага китереп ясалган, матур язулары ачык күренеп торган, мәрмәр валчыклары кушып измә белән катырган нык аскуймаларга бастырылган янәшә ике зур таш, зиратка килеп кергәч тә диярлек, һәркемнең игътибарын җәлеп итә. Болар — 1910 елның 10 августында 65 яшендә бакый дөньяга күчкән Мәхмүд байга һәм аның хәләл җефете, 1906 елның 10 декабрендә 37 яшендә вафат булган Мәфтухага (Фазлулла Акалаев кызына) куелган кабер ташлары (2 нче фоторәсем).

2 нче фоторәсем

Мәхмүд бай Хөсәенев кабер ташының тексты берсен берсе дәвам итүче өч өлештән тора: алгы як өслектәге югары һәм түбән ярусларында һәм арткы як өслегендәге югары яруста гарәп язуының сөлес төре белән уеп язылган текст мондый:

Алгы як өслектә (3 нче фоторәсем)
1. Хәйрен-нас әнфәгаһүм лин-нас
2. Оренбург сәүдәгәрләреннән Мәхмүд Мөхәммәдгали угылы Хөсәенев
3. 65 яшендә вафат булды. Аллаһүммә ирхәм рәхмәтән уасигатән
4. Шәгъбанның 17сендә унынчы августта 1328 сәнәи һиҗрия 1910 сәнәи миладия

1. Мәрхүм үз гомерендә кыйлган ингам вә ихсанларыннан
2. башка хәйрат юлына сарыфителмәк өчен
3. ярты миллион сумга якын васыять итмеш.

Арткы як өслектә (4 нче фоторәсем)
1. Бу
2. җөмләдән Оренбург вә Каргалы
3. мәктәп вә мәдрәсәләре файдасына Тәфкилев имениясе

3 нче фоторәсем

4. исемендә булган ике мең дисәтинәдән
5. зийадә җир вә урман вакыф итмештер.

Күренгәнчә, әлеге ташъязма өстәмә мәгълүматларга тагын да баерак. Хөсәеневләрнең аталары исеме дә, Мөхәммәдгали дип, тутырып язылган, «Оренбург сәүдәгәрләреннән» булган Мәхмүд байның хәйрия юнәлешендәге гамәлләре дә бик лаеклы рәвештә зурлап телгә алынган. Ташның үлчәменә килгәндә: биеклеге — 180 см, урта тирәләрендәге киңлеге — 63 см, калынлыгы — 31 см.

***

Гани бай Хөсәеневнең кабер ташы ак мәрмәрне сырлап-бизәкләп, Мәхмүд байныкына һәм аның җәмәгатенекенә караганда тыйнаграк итеп ясалган, әмма формасында да, язуында да игътибарны җәлеп итәрдәй үзенчәлекләре аз түгел (5 нче фоторәсем). Аскуймасы бетоннан булса да, аның дүрт кыры да бертөрле рәвештә бизәкләп эшләнгән. Аскуйманың үлчәме: 60х58х38 (см); ташның үз үлчәмнәре: 120х40х21 (см).

4 нче фоторәсем

Ташъязманың алгы як өслегенә текст тулаем гарәп телендә, гарәп язуының нәсех төре белән уеп язылган, ул горизонталь рәвештәге 6 юлдан тора (6 нчы фоторәсем):

1. Рәхмәте Аллаһу
2. ракыйдү һәзаль-кабер сахибе-

5 нче фоторәсем

3. -л-хәйрат Габделгани бине Гали
4. Хөсәензадә тәваффа
5. мөнтәсафе шәгъбан 1320 сәнә
6. гыйшрин вә миәтәйн вә әлфин.

Биредә мәрхүмнең вафат булу датасы һиҗри ел исәбендә саннар белән дә, сүзләр белән дә күрсәтелгән. Әмма таш текстын язучы иң астагы юлда «сәләсә миәтин», ягъни «өч йөз» дип куясы урынга «миәтәйн», ягъни «ике йөз» дигән сүзне куеп ялгышкан.

Ташъязманың арткы як өслегенә уелган текст алгы өслектәге текстның үзенчәлекләрен (язу төре, юллар саны) кабатлый, әмма ул татарча язылган (7 нче фоторәсем):

1. Ошбу
2. кабер сахибе Габделгани
3. бай Хөсәенев
4. шәгъбан унбишендә
5. 1320 нче сәнәдә
6. 1902 сәнәи миладиядә

Һиҗри 1320 елның 15 шәгъбан көне хәзер гомум кулланылыштагы ел исәбе белән (григориан стилендә) 1902 елның 17 ноябренә туры килә.

6 нчы фоторәсем

7 нче фоторәсем

СҮЗЛЕКЧӘ:

хәятында — гомерендә
һиммәт — тырышлык, кайгыртучанлык
кариб — якын
зөлкагъдә — мөселман календаренең унберенче
ае исеме
сәнә — ел
миладия — христианча ел исәбе
дөньядан — вафат булды мәгънәсендә
хәйрен-нас әнфәгаһүм лин-нас — башкаларга файдалы булган кеше — иң хәерле кеше (хәдис)
Аллаһүммә ирхәм рәхмәтән уасигатән — йә Аллаһ, киң рәхмәтләрең белән рәхимлә
шәгъбан — мөселман календаренең сигезенче ае исеме
сәнәи һиҗрия — мөселманча ел исәбе
сәнәи миладия — христианча ел исәбе
ингам вә ихсанларыннан — яхшылыкларыннан һәм ярдәмнәреннән
хәйрат — изгелек
зийадә — артык
вакыф итмештер — килерен җәмәгать файдасына тоту өчен биргән
рәхмәте Аллаһу — Аллаһы Тәгаләнең рәхмәте
ракыйдү һәзаль-кабер — ошбу кабердә ятучы
сахибел-хәйрат — изгелек иясе
тәваффа — вафат булды
мөнтәсафе шәгъбан — шәгъбан аеның уртасында
гыйшрин вә миәтәйн вә әлфин — бер мең ике йөз егерме ■

НИГЕЗ

КЕРӘШЕН СӘРДӘСЕ АВЫЛЫ ТАРИХЫННАН (XV-XIX ГАСЫРЛАР)

НИКОЛАЙ ПЕТРОВ-TEKIN,
төбәкне өйрәнүче

ТАРИХЧЫ ГАЛИМНӘР ӘЙТҮЕНЧӘ, КАЗАН ХАНЛЫГЫНДА 700ДӘН АРТЫК АВЫЛ ҺӘМ ШӘҺӘР БУЛГАН [1]. БУ ТАРИХИ АВЫЛЛАРНЫҢ ҺӘМ ШӘҺӘРЛӘРНЕҢ ЯЗМА ДОКУМЕНТЛАРДА ЭЗЛӘРЕ КАЛГАН. СОҢГЫ ЕЛЛАРДА БАСЫЛГАН ФӘННИ ХЕЗМӘТЛӘРДӘН ФАЙДАЛАНЫП, РЕСПУБЛИКАДАГЫ БАРЛЫК АВЫЛЛАРНЫҢ ДА ДИЯРЛЕК ТАРИХЛАРЫН ТОРГЫЗЫРГА БУЛА. ТАБЫЛГАН ЯҢА АРХИВ МАТЕРИАЛЛАРЫ ТАРИХИ ХӘТЕРНЕ ЯҢАРТЫРГА МӨМКИНЛЕК БИРӘ. БҮГЕНГЕ ЗАМАНДА НӘСЕЛНЕ, ТУГАН-ЫРУНЫ БЕЛҮ, КАН-КАРДӘШЛЕК НИГЕЗЕНДӘ БЕРДӘМЛӘШҮ ТОРМЫШ АВЫРЛЫКЛАРЫН ҖИҢӘРГӘ ЯРДӘМ ИТӘ.

Питрәч районында Мишә елгасына килеп кушылган саф көмеш суы яшел чирәмле ярларга сыймый аккан гүзәл Сәрдә елгасы буенда, Казан шәһәреннән 60 чакрым көнчыгышта урнашкан Керәшен Сәрдәсе авылының үткәненә һәм халкының язмышына кагылышлы документлар аша тарихи вакыйгаларны тергезик.

Шул документларның берсе, бүгенге көндә безгә билгеле булганнарның иң борынгысы, 1565-1568 елларда, Казан ханлыгы басып алынганнан соң 13 ел узгач, патша Иван IVнең хөкүмәт

1. Чернышёв Е.И. Селения Казанского ханства (по писцовым книгам) / Вопросы этногенеза тюркоязычных народов Среднего Поволжья. Казань, 1971. — С.272-292.

2. Мустафина Д.А. Писцовое описание Казани и Казанского уезда 1565-1568 годов. Публикация текста. — Казань: Издательство «ФӘН» Академии наук РТ, 2006. — 660 с.

Сәрдә Мишәсе елгасы

чиновниклары Никита Васильевич Борисов белән Кикин Андрей улы Дмитрий төзегән җир биләмәләрен теркәү кенәгәсе («Писцовое описание Казани и Казанского уезда 1565-1568 годов») дип атала [2].

Бу документта «Сәрдә елгасы буендагы Иске Сәрдә авылы» рус бояры Матвей Кузьминский уллары Семёнка белән Рахман биләмәсе итеп күрсәтелгән. Авылда биш йорт барлыгы, ул йортларның буш, ташландык хәлдә икәнлеге әйтелгән. Документта Матвей Кузьминскийның өченче улы Ивашконың, Иске Сәрдәдән күчеп, Сәрдә елгасы Мишәгә кушылган җирдә Яңа Сәрдә исемле яңа авыл нигезләве әйтелгән. Биредә сүз бүген буш урыны гына торып калган Рус Сәрдәсе авылы турында бара.

Казан тарихчысы Е.И.Чернышёв Казан ханлыгы чорында булган 700дән артык авылны теркәп төзегән исемлектә [1] Мишә буендагы Нырсы-Варзи (Нырсывар), Таутермень (Тегермән Тауы), Кибәхуҗа, Тәмте, Толкиш, Югары, Урта, Түбән Казы (Керәшен Казысы, Рус Казысы) авыллары, шулай ук Пимәр, Әльбәден, Юныс, Әтрәч, Чыты, Кибәч, Кәүәл авыллары белән беррәттән Иске Сәрдә авылы да искә алына. Сәрдәгә күрше булган Көлкәмәр авылы бераз соңрак, 1647 елгы теркәү кенәгәсендә [4] урын ала.

Без санап узган авылларда, шул исәптән Иске Сәрдә авылында да, 1565 елларда рус кешеләре хуҗалык итә, алар килгәнче биредә нинди халык вәкилләре яшәгәнлеге, кайсы төбәккә күчеп китүләре турында бернинди хәбәр дә сакланмаган.

Кызганычка каршы, күп кенә язма документлар еш кабатла-

3. Степанов Р.Н. Писцовая книга Казанского уезда 1602-1603 годов. Публикация текста. — Казань, 1978. — 240 с.
4. Ермолаев И.П., Мустафина Д.А. Писцовая книга Казанского уезда 1647-1656 годов. — Москва: Издательский центр Института российской истории РАН, 2001. — 543 с.

нып торган янгыннарда юкка чыкканнар. 1701 елда зур янгын вакытында Казан Сарае Приказы (Приказ Казанского Дворца) бинасы үзенең бик бай архивы белән бергә юкка чыккан. Казан төбәге буенча илнең үзәк архивларындагы аерым кулъязмалар һәм документлар гына сакланып калган. Алар арасыннан авыллар тарихына бәйле чыганак табу зур уңыш булып санала.

Безнең уебызча, Керәшен Сәрдәсе авылында урта гасырлардан истәлек булып Сәрдә елгасы буенда үскән берничә чыршы агачы, урман янындагы «Чирмеш куышы» урыны һәм Олы елга (Җыланлы җылга) буенда «Берле нарат», «Икеле нарат» агачлары сакланып калган. Бу карт агачлар әле 1970 елларда гына юкка чыкты.

И.Износковның хезмәтендә [16] Мишә елгасы янындагы Түбән Сәрдә (Рус Сәрдәсе) авылының чиркәвеннән көньяктагы басу кырында (150 сажень ераклыкта) борынгы кабер ташлары булганлыгы әйтелә. Алар XIX гасыр азагында инде бик тузып-җимерелеп беткән булалар. Гарәп графикасында чукып язылган текст калдыклары бу авылларда мөселман татарлар яшәгәнлеген дәлилли. Кызганыч, бүгенге көнгә кадәр ул ташбилгеләр сакланмаган.

1870 елны Казан университеты профессоры А.Н.Стоянов җитәкчелегендә башкарылган археологик тикшеренүләр вакытында, җирле полиция хезмәткәре күрсәтүе буенча, Югары Сәрдә (Керәшен Сәрдәсе) авылында иске каберлекләр эзләгәннәр [15]. Кызганычка каршы, археология экспедициясе хисапларыннан эзләүләрен кайсы урыннарда алып барылганын ачыклап булмады.

Авыл эчендә, Сәрдә суы буенда бик борынгы зират булганлыгын авыл картлары 1950 елларда сөйлиләр иде. Бу каберлекләр, һичшиксез, авылда Казан ханлыгы заманында яшәгән халыктан калган. Күрше Чыты авылы янында А.Н.Стоянов тарафыннан тикшерелгән һәм өйрәнелгән борынгы мөселман каберлеге бүген дә саклана [15]. Чыты авылы халкы бу каберлекне «иске авыл кешеләренеке» дип аңлата, аларга хөрмәт белән карый. Чыты авылында яшәүчеләрнең бабалары 1610 еллардан соң Арча районындагы Венета авылыннан һәм хәзер инде Казан шәһәренә кергән Вознесенское авылы урыныннан күчереп утыртылган булган.

Шул ук елларда Алат шәһәрчеге (хәзерге Биектау районы) янындагы Шуман һәм Чуваш Иле авылларыннан Керәшен Сәрдәсе авылына яңа хуҗалар булып Текиннар һәм Резяповлар күчеп килә. Бу күченүләр рус воеводалары тарафыннан Казанның әйләнә-тирәсендәге 40 чакрымлык «куркынычсызлык боҗрасы» оештырылган вакытта була. «Куркынычсызлык боҗрасы»на кергән барлык авыллардагы йомышлы кешеләр (служилые татары, служилые новокрещёные) югарыда санап үтелгән Мишә елгасы буендагы авылларга күчерелгән. Ә «куркынычсызлык боҗрасы»нда русларга гына яшәргә рөхсәт ителгән.

5. Ермолаев И.П. Казанский край во второй половине XVI-XVII вв. (Хронологический перечень документов). — Казань, 1980. — 263 с.
6. Ревизская сказка 1719 года Казанского уезда Ногайской дороги. Деревня Верхние Серды. — НА РТ. Ф.169, опись 2, д.6. (г.Москва РГАДА. №350-2-1085, С.605-614).
7. Ревизская сказка 1748 года Казанского уезда Ногайской дороги. Деревня Верхние Серды. —РГАДА. Ф.350, оп.2, ч.2, д.1146, С.261-264, С.248-251.
8. Ревизская сказка 1762 года. — РГАДА. Ф.350, оп.2, ч.2. д.1216, С.333.
9. Ревизская сказка 1834 года Казанской губернии Лаишевского уезда. Деревня Верхние Серды. (НА РТ. №3-2-62).

Санап үтелгән фактлар Мишә елгасы буенда урнашкан авылларның бай тарихлы булуларын ачык күрсәтә.

Атаклы «Идегәй» дастанында [16] «сәрдә» сүзе үлән исеме буларак кулланыла. Дастанда шундый юллар бар:

Сәрдә дигән салт үлән —
Аны тапсак утлаек,
Әттек дигән тамыр бар,
Аны да тапсак юшыек.

Биредә сүз яшүсмер Идегәйнең, сугышчан иптәшләре белән Туктамыш ханнан качып, «шәһре Сарайдан» далага чыгуы, анда ял иткән вакытта атларын утлату, туйдыру турында бара.

«Сәрдә» сүзе бүген дә үләнне аңлата, русча атамасы — «сныть», «подагричник». Бу үлән, кар эри башлау белән, беренчеләрдән булып дымлы үзәннәрдә, урман буендагы ачык урыннарда чыга. Элек әлеге язгы үлән белән атларны, йорт хайваннарын кышкы чорда витаминнар җитмәүдән (авитаминоз) коткарганнар. Үләннең яшь сабаклары кешеләр өчен дә бик файдалы. Кычыткан яфраклары белән берррәттән, сәрдә үләне гомер-гомергә авыл халкын язгы ачлыктан коткарган.

Дастанда искә алынган «әттек» дигән тамырны Сәрдәдә бүген «ирен яргыч үләне» дип йөртәләр, иске атамасын инде бары без — өлкән буын гына хәтерли.

Иске Сәрдә авылы 1602-1603 елларда Иван Болтин җитәкчелегендә төзелгән Казан өязендәге җир биләмәләрен теркәү кенәгәсендә искә алынмый [3]. Моның төп сәбәбе — ул елларда авыл әле рус алпавытлары кулында була, ә теркәү кенәгәсенә «рус булмаган» йомышлы һәм ясаклы кешеләр теркәлгән.

Шул ук кенәгәдә Малая Серда авылы (Рус Сәрдәсе) «пустошь» яки буш, ташландык торак урыны буларак күрсәтелгән. Бу вакытта авылның хуҗалары инде христиан динен кабул иткән татар князьләре, бик борынгы нәселле Асанмурзиннар (Асановлар) булган.

Безнең борынгы бабаларыбыз — хәрби йомышлы татарлар — 1600 нче елларга кадәр, Илет елгасына койган Ашыт янында, Алат кирмәне тирәсе авылларында, үз җирләрендә иген игеп, дәүләткә хәрби хезмәт итеп яшәгән.

1590 елда Мәскәү патшасы Иван IV боерыгы белән хәрби йомышлы Тәкәй бабайга (Тәкәй Азин (1530-1595)) Казан өязендәге Чуваш авылы (Дөбьяз районы Чуваш Иле авылы) шәхси биләмә итеп бирелгән [5].

1609 елда Иске Сәрдә авылы (Керәшен Сәрдәсе) барлык җир һәм урман-сулары белән Алат юлындагы Шуман авылының хәрби йомышлы керәшеннәре Текиннар (Тәкәневлар, Тәкәй Азинның оныклары) [11] һәм Рәҗәповлар (Арезеповлар) кулына тапшырыла. Шул елларда алар яңа урынга — Сәрдә авылына күчереләләр.

Санап үтелгән документлардагы язмалардан күренгәнчә, Мишә елгасы буендагы тагын биш авылда һәм Чулманга коя торган Бетки, Солтанка елгалары янында урнашкан ике авылда

10. Ревизская сказка 1850 года года Казанской губернии Лаишевского уезда. деревни Верхние Серды. — НА РТ. № 3-2-643.

11. 1798 г. Спорное Дело деревни Верхней Серды в фондах Межевой канцелярии. Прошение поверенного Лаишевского округа деревни Старой Серды старокрещена Якова Егорова о подлинной грамоте царя Василия Ивановича Шуйского, выданной в 1609 г. его предкам — Андрею Владимировичу Текину о додаче к поместному жеребью 42 четвертей земли в д.Шуманах. В деле имеется «Геометрический план Казанского наместничества Лаишевского уезда деревни Верхней Серды с принадлежащим к ней всей земли...» (РГАДА. Ф.1312, оп.2, ед.хр.277 на 26 листах).

яшәүче халыкларның да нәсел башы, уртак бабалары — Тәкәй Азин. Бу авылларга Тәкәй Азинның оныклары: Иске Йортка Тоганаик Давлеткильдеев, Татар Казысына (Отар Дубровка) Ишбулат Янчурин (Булакош Чуреев), Кибәхуҗага Янклыч Янбулатов, Тәмтегә — Айтуган Янбулатов, Олы Солтанга һәм Шетнёво-Черемышево авылларына (бүген бу авылда әле дә руслар яши) Тәкәй Янчурин, Токай (Тәкәй) Янбулатов күчеп килгән. Кибәч авылына Тәкәй Азинның дәдәсе Баиш (Багиш) оныгы Кузьма Башиев килеп урнаша [3,4].

Югарыда әйтелгән бүгенге керәшен һәм татар авылларында кан-кардәш туган кешеләр яшәгәнлеге ачыкланды. Мишә буенда урнашкан башка авылларда да, төрле диннәрдә булуга карамастан, бер ыру кешеләре үзара татулыкта ярдәмләшеп гомер сөрә.



Авылларга нигез салучыларның шәҗәрә-схемасы

Мәскәү патшасы Василий Шуйскийның боерыгы буенча, 1609 елның 20 августында Шуман авылында (бүгенге Биектау районы) яшәүче хәрби йомышлы керәшен Ондрей Володимирович Текинга (Андрей Владимирович Текин) грамота бирелә. Бу грамотаның 1800 елларда да варисларының берсе Яков Егорович Текин (Яков — Егор — Фёдор — Яков — Семён — Ондрей Володимирович — Володимир Текин —Тәкәй Азин) кулында саклануы хакында Мәскәү Дәүләт борынгы актлар архивындагы документта хәбәр бар. 1964 елларда тарихчы галим Р.И.Степанов бу кыйммәтле чыганакны фәнни әйләнешкә кертә [12, 13].

Бабам нигезе

Патша грамотасында хәрби йомышлы керәшен Ондрей Володимирович Текинга Шуман җир биләмәләренә өстәмә итеп Иске Сәрдә авылы янындагы басу һәм урман-болыннарның яртысын бүлеп бирергә боерыла. Авылда булган җирләрнең икенче яртысы башка грамота белән хәрби йомышлы керәшен Семён Лукич Резеповка (Арезепов) бирелә. 1647-1656 елгы җир биләмәләрен теркәү кенәгәләрендә алар авылның төп хуҗалары итеп күрсәтелгәннәр [4].

Патша боерыгыннан соң 30-40 ел узгач, Текиннар һәм Рәҗәповларның оныклары белән бергә Филипповлар һәм Багишевлар нәселләре Керәшен Сәрдәсе авылы халкын барлыкка китерә. Филипп бабайның әтисенең исемен документлардан ачыклап булмады.

Керәшен Сәрдәсе авылы керәшеннәре турында мәгълүмат 1719 [6], 1748 [7] еллардагы халык исәбен алу документларында һәм 1834 [9], 1850 [10] елларда уздырылган VIII-IX ревизия документларында сакланган. Шулай ук 1724 елдан башлап Рус Казысы [18] һәм 1744 елдан соң Рус Сәрдәсе [19] авыллары чиркәүләрендә алып барылган метрика кенәгәләрендә дә авылда яшәгән кешеләр турында бик җентекле хәбәрләр бар. Бу документлар белән Мәскәү дәүләт борынгы актлар архивында һәм Татарстан Республикасы Милли архивында танышырга мөмкин.

1719 елда авылда 12 хуҗалык, 49 ир-ат зат, хәрби йомышлы керәшен яшәгән.

1748 елда йортлар саны 15кә җиткән, бередә көн күргән 46 ир-ат «йомышлы дәүләт крестьяннары» («служилые государственные крестьяне») дип теркәлгән.

12. Степанов Р.Н. К вопросу о служилых и ясачных татарах // Сборник аспирантских работ. Право. История. Филология. — Казань, 1964. — С.53-70.

13. Степанов Р.Н. Первый этап в политике Царизма по переводу служилых татар из военного сословия в податное (конец XVII — первая четверть XVIII вв.) // Итоговая научная аспирантская конференция за 1964 год. (Тезисы докладов). — Казань, 1964. — С.129-132.

1795 елда авылда 27 йорт була, 92 ир-ат яшәгән. Аларны «ясачные старокрещёные» дип теркәгәннәр.

1834 елда Керәшен Сәрдәсендәге 46 йортта 191 ир-ат һәм 215 хатын-кыз көн күргән.

1850 елда авылда 49 хуҗалык исәпкә алынган (240 ир-ат, 263 хатын-кыз).

Әйткәнебезчә, авылда борынгыдан ук үзара туганлашкан дүрт нәсел-ыру халкы яши.

1. Текиннар нәселе: Токиновлар, Александровлар, Семёновлар, Овчинниковлар, Михайловлар, Карташовлар, Егоровлар, Конашевлар, Киселёвлар, Фадеевлар, Гавриловлар, Маловлар, Романовлар, Шалямовлар, Фёдоровлар, Тимофеевлар, Кругловлар, Никитиннар (Гүрди, Гәңки, Сәтлек), Даниловлар, Денисовлар, Топьяновлар, Никифоровлар, Сидуковлар, Цеповлар, Анисимовлар, Мойсеевлар.

2. Рәҗәповлар нәселе: Владимировлар (Бүре), Волковлар (Бүре), Мухиннар, Анисимовлар, Ивановлар (Башмаков), Цыгановлар, Кузнецовлар, Поповлар, Сергеевлар, Яковлевлар (Чтапан, Апач), Калашниковлар, Макашовлар, Быкеевлар.

3. Филипповлар нәселе: Максимовлар, Сердинскийлар, Никитиннар (Шәйхи), Казаковлар, Кузьминнар, Морозовлар, Яковлевлар (Гөркә), Николаевлар, Чукиннар, Ворожейкиннар, Фёдоровлар (Пешәү), Вараксиннар, Ермолаевлар, Дементьевлар, Лягушкиннар, Ивановлар (Бәтер), Трофимовлар, Полевойлар, Трифоновлар, Афанасьевлар.

4. Багишлар нәселе: Постниковлар.

Алардан тыш тагын ике нәсел вәкилләре бар.

5. Скворцовлар — 1870 елларда авыл ачылган «Изге Гурий кардәшлеге миссионер мәктәбенә укытучы булып килгән Николай Фёдорович нәселе — 3 йорт.

6. Белугиннар — 1890 елларда Лаеш районындагы Ташкирмән авылыннан күчеп, авыл мәктәбенә укытучы булып килгән агалы-энеле бертуган Степан Филиппович белән Ефрем Филиппович (Җәпүк) нәселе — 1 йорт.

Шулай итеп, язма чыганаклардан күренгәнчә, Керәшен Сәрдәсе авылына нигез салучылар 1600 елларга хәтле Алат даругасында яшәгән йомышлы татарларның оныклары булган. Мишә буенда урнашкан башка татар, керәшен авылларында да бер үк халык — «куркынычсызлык боҗрасы» эченнән күчерелгән йомышлы татар һәм йомышлы керәшен бабаларыбызның оныклары, нәселләре яши.

Җирле халыклар арасында христиан диненең йогынтысын көчәйтү өчен 1731 елда Зөядәге Богородицк монастыренда «Новокрещенская контора» оештырыла.

1740 елда императрица Анна Иоановнаның 11 сентябрьдә чыккан Указы нигезендә («Об отправлении архимандрита с некоторым числом священнослужителей в разные губернии для обу-

14. Петров-Текин Н.И., Сердинский В.И. Об особенностях заселения Примешинской зоны Западного Прикамья во второй половине — середине XVII вв. (1552-1660 гг.) // Сборник статей. Татарские мурзы и дворяне: история и современность. Выпуск 1. — Казань: Институт истории им.Ш.Марджани АН РТ, 2010. — С.276-284.

15. Стоянов А.Н. Отчёт о раскопках древних могил и курганов в Лаишевском и Спасском районах Лаишевского уезда Казанской губернии. // Общество испытателей при Императорском Казанском университете. — Казань, 1871.

чения новокрещёных христианскому закону и о преимуществах новообращённым дарованных») авылларда чиркәүләр төзелә башлый. 1741 елда Рус Казысы авылында таштан Благовещение чиркәве төзелә. Моңарчы анда агач чиркәү булган. 1744 елда Рус Сәрдәсе авылында Преображение Господня чиркәве салынып бетә. Бу чиркәү приходына Керәшен Сәрдәсе, Көлкәмәр, Кибәч, Әтрәч, Рус Сәрдәсе авыллары кешеләре языла.

Авылда 1870 елларда «Изге Гурий кардәшлеге» мәктәбе эшли башлый, биредә укытудан тыш балаларны төрле кул эшләренә өйрәтү түгәрәкләре дә оештырыла.

Беренче укытучылар һәм тәрбиячеләр булып Казандагы Үзәк керәшен школасын тәмамлаган, авылдагы укытучылар династияләренә нигез салган Николай Максимович, Антон Максимович, Пётр Максимович, Егор Петрович, Гурий Николаевич Максимовлар — данлыклы Сердинскийлар, Фёдор Никитович Никитин, Ташкирмән авылыннан агалы-энеле Никита Филиппович белән Степан Филиппович Белугиннар, шулай ук читтән килгән Захар Фёдорович белән Василий Захарович Скворцовлар эшли. Халык хәтерендә Субаш авылы кешесе — укытучы Гаврила Григорьев һәм Уракчы авылыннан килгән укытучы Василий Фотеевның исемнәре сакланган.

Авыл мәктәбендә төрле елларда Казан укытучылар семинариясе, укытучылар курслары тәмамлаган ир-ат һәм хатын-кыз укытучылар эшләгән.

1887 елда төбәк тарихы белән кызыксынучы чиновник И.А.Износков безнең авыл турында менәниләр хәбәр итә: «Югары Сәрдә авылы исемсез чишмә янында, Нугай сәүдә юлыннан сул якта урнашкан. Шәһәрдән 39 чакрым, волость идарәсеннән 6 чакрым (Рус Казысы авылы) ераклыкта. Авыл 2 чакрым ераклыкта урнашкан Түбән Сәрдә авылы чиркәве приходына беркетелгән. Авылда 118 хуҗалыкта 438 ир-ат һәм 452 хатын-кыз яши. Халкы — керәшен татарлары. Җир биләмәләре — 1864 дисәтинә...» [16].

Архив материалларыннан күренгәнчә, 1860 елларга кадәр авыл территориясе Олы урамның Югары оч күпере һәм Түбән оч күпере арасы белән чикләнгән булган. Авылның Югары оч (күпердән югары ягы), Түбән оч, Атау, Арт урам дип йөртелгән өлешләрендә йортлар башлыча 1860-1890 елларда хәзерге Ышна юлы, Утын юлы кырлары урыныңдагы урманнарны кисеп, ышна кырын ачкан заманнарда агач-бүрәнәләрдән төзелгән.

1900 елда авыл инде хәзерге чикләренә таралып урнашкан булган.

Шулай итеп, XVI-XIX гасырлар арасындагы 300 еллык тарихны үтеп (1609-1900), авыл яңа XX гасырга аяк баса. Җирле крестьяннар өчен башка мәшәкатьләр һәм сынаулар башлана. ■

16. Износков И.А. Список населённых мест Казанской губернии с кратким описанием их. Лаишевский уезд. (Серда Верхняя). — Казань, 1895.
17. «Идегей». Татарский народный эпос. — Казань, 2006. — 536 с.
18. Метрические книги 1724-1783 годов. Казанский уезд. — НА РТ. Ф.2.
19. Метрические книги 1782-1915 годов. Лаишевский уезд. — НА РТ. Ф.5.4.
20. Гариф Н.Г. Тарихи чыганакларда төрки-татар исемнәре һәм географик атамалар. — Казан, 2011. — Б.24.

ГАБДРАХМАН РАФИКОВ ГАИЛӘСЕ ҺӘМ ТАТАР ЗЫЯЛЫЛАРЫ

ТАТАР МӘДӘНИЯТЕН, СӘНГАТЕН, ӘДӘБИЯТЫН, МИЛЛИ МӘГАРИФЕН ҮСТЕРҮГӘ ЗУР ӨЛЕШ КЕРТКӘН РАФИКОВЛАР ГАИЛӘСЕ ҺӘМ НӘСЕЛЕ ХАЛКЫБЫЗ КҮҢЕЛЕНДӘ БҮГЕН ДӘ ЗУР УРЫН АЛЫП ТОРА.

Күренекле татар педагогы, мәгърифәтче Рафиков Габдрахман Мөхәммәтвәли улы (1873-1954) Казан шәһәрендә читекче Мөхәммәтгали һәм кәләпүш остасы Гайшә гаиләсендә дөньяга килә. Аның әтисе чыгышы белән Казан өязенең Олы Кавал авылыннан (хәзер Биектау районына карый). 1891 елда үпкә авыруыннан әнисе, ике елдан әтисе дә үлеп китә [1]. Белем алуга омтылышы зур булу Габдрахманны «Мөхәммәдия» мәдрәсәсенә китерә. 1894 елда ул Казан татар укытучылар мәктәбен тәмамлый. Яшүсмернең шәхес һәм педагог буларак үсешендә Ш.Мәрҗани хезмәтләренең роле зур була. Шуңа күрә ул Мәрҗанине үзенең остазы дип саный һәм аның карашларын тормышка ашыруны үзенә максат итә, еллар буена туплаган белемен татар балаларын мәгърифәтле итүгә багышлый.

Габдрахман Рафиков үзенең педагогик эшчәнлеген 1894 елның көзендә Казан губернасы Тәтеш өязе Чирмешән авылындагы татар-рус мәктәбендә башлап җибәрә. Әмма зур хыяллар белән кайткан яшь педагогны биредә сынаулар көтә. Чөнки авыл халкы үзләренең балаларын рус мәктәбенә

Габдрахман Рафиковка 19 яшь. 1892 ел

җибәрергә бер дә ашкынып тормый, рус телен өйрәнеп, диннән язарлар дип курка. Габдрахманга, өй саен йөреп, ата-аналарны үгетләргә, рус телен генә түгел, башка фәннәрне дә өйрәнүнең кирәклеген аңлатырга туры килә. Башта бер-ике ата-ана, алардан күреп тагын биш-алтысы баласын мәктәпкә җибәрә. Бер айдан азрак вакыт эчендә аларны укырга-язарга өйрәткән мөгаллимгә ышыныч арта. Җитмәсә, үзе дә биш вакыт нама-

зын калдырмый, мәчеткә йөри, ураза тота. Габдрахманны акрынлап Коръән мәҗлесләренә чакыра башлыйлар. Ике генә ел эшләп кала ул бу авылда. Уңышларыннан хәбәрдар булган инспекторлар Габдрахман учительне Казанга — Бишбалтадагы 2 нче номерлы рус-татар мәктәбенә [2] директор итеп күчерәләр. Бу мәктәптә ул 35 ел директор вазифасын башкара, бер үк вакытта рус теле, арифметика, чиста язу дәресләрен алып бара [3]. Шәхси үрнәк, педагоглык осталыгы, балаларны яратуы, һәрберсенә бертөрле караш, ярдәмчел булуы аркасында ул Бишбалтада гына түгел, тирә-юнь бистәләрдә дә ихтирам казана: баласын үз мәктәбенә алуын үтенеп килгән ата-аналар саны көннән-көн күбәя. Татарлар, аны олылап, «халык укытучысы», ул җитәкләгән мәктәпне революциягә кадәр үк «Рафиков мәктәбе» дип атый башлый.

Габдрахман Рафиков үз фәнен яхшы белгән педагог һәм тәрбияче генә түгел, бик әйбәт оештыручы буларак та дан казана. Аның мәктәбендә төрле елларда булачак шагыйрь Хәсән Туфан, драматург Кәрим Тинчуринның тормыш иптәше Заһидә Тинчурина, танылган тюрколог һәм этнограф Николай Катановның кызы Анна Катанова, Былбыл Ильясова, Клавдия Рихтер (милләте буенча немец, әмма татар телен бик яхшы белгән) һ.б. күренекле укытучылар эшли.

Мәктәптә белем алган укучылар арасыннан язучылар Гариф Гобәй һәм Әминә Бикчәнтәева, драматург Гамир Насрый, профессор Хәдичә Әхмәтҗанова, полковник Салих Әхмәров, Госман Усейнов һ.б. күренекле шәхесләр үсеп чыга. Габдрахман Вәли улының үз кызы Әминә дә, әтисе юлын сайлап, укытучы була, шул ук мәктәптә немец теле укыта. Улы исә, Хәбибрахман Рафиков, татарлар арасында революциягә кадәр беренчеләрдән булып, Казан елга училищесын тәмамлый һәм тәүге елга капитаны булып таныла.

Рафиковлар гаиләсе үзенең кунакчыллыгы белән (хатыны Рабига ханым да бик ачык күңелле, татар ризыкларын пешерергә оста була) заманының бик күп зыялыларын, әдәбият һәм мәдәният әһелләрен үзенә җәлеп итеп торган. Танылган татар язучысы Фатих Әмирхан иң якын гаилә дусларының берсе булган. Г.Рафиков Ф.Әмирхан белән хәтта ана теле буенча дәреслекләр дә язган [4]. Аларга Әмирханның якын дуслары — медицина фәннәре докторы, ТАССР сәламәтлек саклау комиссары Фатих Мөхәммәдьяров, язучы, җәмәгать эшлеклесе Мәхмүт Бөдәйли дә килгәләгән. Хәсән Туфан мәктәптә укыткан чорда Рафиковлар гаиләсендә 4 ел яши; Һади Такташ, Гадел Кутуй, Шәриф Камал, Риза Ишморат, Мөхетдин Корбангалиев, Салих Сәйдәшев бу кунакчыл гаиләгә даими килеп йөри, әдәбият кичәләре оештыралар. Бу кичәләрдә чыгыш ясаучылар арасында Солтан Габәши, соңрак Сара Садыйкова да була. Музыкаль белеме булмаса да, пианинода татар халык көйләрен бик оста уйнаган Габдрахман ага балаларын да татар сәнгатенә гашыйк итеп үстерә [5].

Атаклы педагог, дәреслекләр авторы [6], Татар мәгариф халык комиссариаты президиумы әгъзасы һәм инспекторы (1921-1924 елларда), РСФСР күләмендәге персональ пенсионер Габдрахман Рафиковның олы хезмәте җәмәгатьчелек кенә түгел, хөкүмәт тарафыннан да зур бәяләнә. Олуг педагог һәм мәгърифәтченең исеме бүген дә халык күңеленнән төшми. Күптән түгел Казан шәһәренең Совет районындагы яңа урамга Габдрахман Рафиков исемен бирү турындагы боерыкка кул куелды [7].

Габдрахман Рафиковның улы Хәбибрахман Рафиков (1897-1972) — 1917 елда татарлардан беренче булып Казан елга училищесын (соңыннан

техникум итеп үзгәртелә) тәмамлаган елга капитаны, укытучы, педагог. Ул атаклы шәхесләр — Галимҗан Ибраһимов, Фатих Әмирхан, Кәрим Тинчурин, Һади Такташ, Хәсән Туфан, Сара Садыйкова, Галия Кайбицкая, Илһам Шакиров һ.б. белән якыннан аралашып, дус булып яшәгән. Татар әдәбияты, мәдәнияте, тарихы белән һәрдаим кызыксынып торган Хәбибрахман әфәнденең милли җанлы кеше булуы көндәлекләреннән дә күренә. Дәфтәрләрнең күбесе татар телендә, пөхтә һәм төгәл итеп язылган. Кызы Наилә ханым Рафикова гаиләсендә саклланган әлеге язмаларда Х.Рафиковның замандашлары, күренекле шәхесләргә һәм вакыйгаларга карата мөнәсәбәте чагылыш таба. Игътибарыгызга шул көндәлекләрдән берничә өзек тәкъдим итәбез.

Искәрмәләр

1. Биографик мәгълүматлар Г.Рафиковның кызы Наилә Рафикованың гаилә архивында сакланган документлар һәм көндәлекләрдән алынды.
2. 1921 елда ул 13 нче, соңрак Н.Нариманов исемендәге 17 нче мәктәп итеп үзгәртелә.
3. Г.Рафиковның гомуми педагогик стажы 50 ел тәшкил итә. 1931 елда шәхес культы җилләренә эләккән укытучыны мәктәбеннән китәргә мәҗбүр итәләр (я динне, я совет мәктәбен сайла дигән сылтау белән), ул рабфакта, 6 нчы тегү фабрикасының осталар хәзерләү курсларында белем бирә, казармаларга йөреп хәрбиләрне укыта.
4. Ф.Әмирхан, Г.Рафиков. Ана теле. 1 нче китап. 1 нче баскыч эш мәктәпләренең 1 сыйныфына махсус. — Казан: Мәгариф, 1919. — 58 б.; Ана теле. 2 нче китап. 1 нче баскыч эш мәктәпләренең 2 сыйныфына махсус (автордаш — Әмирхан Ф.). — Казан: «Мәгариф» ширкәте, 1919. — 126 б.; Ана теле. 3 нче китап. 1 нче баскыч эш мәктәпләренең 3 сыйныфына махсус (автордаш — Әмирхан Ф.). — Казан: «Мәгариф» , 1919. — 128 б.
5. Улы Хәбибрахман пианинода оста уйный, оныгы София скрипка классы буенча музыка мәктәбен тәмамлый.
6. Рафиков Г. Кыйраәт китабы. Хәсән бабайның бал корты тугрысында файдалы сүзләре. — Казань: Тип. Б.Л.Домбровского, 1898. — 20 б.; Рафиков Г. Счёт кагыйдәләре. — Казан: Үрнәк, 1910. — 22 б.
7. Казанские ведомости. — 2012. — №160 (30 октября).

ЗУР ӘДИБЕБЕЗ ФАТИХ ӘМИРХАН ТУРЫНДА ИСТӘЛЕКЛӘР

Фатих Әмирхан белән Габдрахман Рафиковлар гаиләсе арасындагы элемтә 1906 елда башлана.

Фатих абыйның тутасы Сәгадәт ханым Бишбалтадагы яңа мәчетнең имамы Габдулла мулла Әмирхановта тормышта була. Фатих абый еш кына үзенең кадерле тутасы Сәгадәт ханымның хәлләрен белеп китә иде.

Минем әнием *(Рабига ханым. — Л.М.)* белән Сәгадәт ханымнар бик якын дуслар иде.

Габдулла мулла, мәчет имамы булуга карамастан, кара фикерле, фанатик мулла түгел иде. Үзенең балаларын урта рус школасында укытты. Аның өендә музыка коралларыннан пианино һәм мандолина бар иде. Кызы Разиягә өенә укытучы чакырып дәресләр бирдерә иде. Әмма Бишбалтаның мәчеткә йөри торган кешеләренең күпчелеге надан, бик кара фикерле йөк төяүчеләр, грузчиклар (үзләрен крушниклар дип йөртәләр иде), итек, кәвеш тегүчеләр, иске кием-салым сатып йөрүчеләр иде. Кызының пианинода уйнавын, балаларының рус мәктәпләрендә укуларын яратып бетермиләр иде. Мәчеткә йөрүчеләр үзара сөйләшкәндә: «Бу имамга намаз укырга оеганда, Аллаһ каршында зур гөнаһлы гына буласың, имансыз булып үләрсең», — диләр иде. Шуңа күрә кайберләре иске мәчеткә күчтеләр.

Фатих абый Бишбалтага апасы Сәгадәт ханым янына килгәндә, әтиебез *(Габдрахман Рафиков. — Л.М.)* аны кунакка чакырып ала иде. Безнең өйдә кояш чыгып, яктырып киткәндәй була иде, әйтерсең, иң якын туганыбыз килгән. Матур гына елмаеп, ул үзенең яңа язган әсәрләре белән таныштыра иде.

Г.Рафиков хатыны Рабига, хатынының әнисе Нәфисә Имангулова һәм балалары – гимназистка Әминә, елга училищесы курсанты Хәбибрахман белән. 1913 ел

Бәйрәмнәрдә Габдрахман Рафиков Яңа Бистәдә яшәүче туганнарына барганда, иң элек Фатих абыйның һәм аның атасы Зариф хәзрәт гаиләсенең хәлләрен белеп, бәйрәмнәр белән тәбрик итеп, озак кына утыргалап чыга иде. Туры килгәндә, башка вакытларда да кергәли иде. Габдрахман Рафиков шулай ук якын туганы, җизнәсе язучы Фатих мәгъзүм Халидигә керә иде. Ф.Халиди Габдрахман Рафиковның туганнан туганы Хәдичә апаның ире иде. Шулай ук бергә Учительская школада укыган иптәше, соңыннан Казан университетының медицина факультетын тәмамлаган табиб (врач) Исмәгыйль абзый Усманов янына да еш кына кергәләп йөри иде. Мин үзем Фатих абый янына кереп, аның белән сөйләшеп утырырга ярата идем.

Фатих абыйның апасы Сәгадәт ханым 29 яшендә дүртенче баласын тапканда үлеп китте. Фатих абый, апасы исән булмаса да, соңыннан килеп җизнәсенең һәм аның балаларының хәлләрен белеп киткәли иде. Бу нык

Хәбибрахман Рафиков. 1925 ел

Нариманов исемендәге 17 нче урта мәктәп. Казан, 1923 ел

дуслык 1926 елга кадәр, ягъни зур, хөрмәтле, кадерле, бик якын, сөекле, нурлы йөзле, шат табигатьле Фатих абыебыз мәңгегә күзен йомганчыга кадәр дәвам итте.

БӨЕК ШАГЫЙРЕБЕЗ ХӘСӘН ТУФАН ТУРЫНДА ХАТИРӘЛӘРЕМ

1924 елда мин пассажирлар йөртә торган «Нева» пароходында капитан ярдәмчесе булып йөрдем. Хөрмәтлеләрем, әткәем һәм әнкәем, бәгырькәйләрем, мин Казанга кайткач: «Хәбиб балакаем, безнең гаиләдә тагын бер бик ягымлы, мәрхәмәтле кеше артты, безгә ул икенче улыбыз кебек, аның белән синә да күңелле булыр», — диеп каршы алдылар.

Мин кайтып кергәндә, Хәсән дәресләрен бетереп менгән иде *(бу вакытта Габдрахман Рафиков гаиләсе үзе эшләгән мәктәп бинасының икенче катында яши. — Л.М.)*. Хәсән белән кочаклашып күрештек. Шунда ул әйтеп куйды: «Рабига апа, гаиләбез түгәрәкләнде, матур, тигез, сау-сәламәт яшик».

Әнкәем, бәгырькәем, мин Свердловск шәһәреннән суккан телеграмманы алгач, бәйрәмнәрдә генә пешерә торган ризыкларын пешереп куйган. Өстәл тәмле нигъмәтләр белән тулып тора иде. Иң элек әткәем, әнкәем, бәгырьләрем, һәм мин утырдым. Аннан соң Хәсән туганыбыз үз бүлмәсеннән килеп чыкты. Табыныбызга әнкәемнең анасы — газиз дәү әнием Нәфисә, безнең белән бергә яшәүче, әтием ягыннан туганнарыбыз Фатыйма җиңги (ул мәктәптә каравылчы булып эшли иде), аның кызы, мәктәптә укучы Әминә (соңыннан ул Казан төзелеш-инженерлар институтын тәмамлады) килеп кушылды. Гөрләшеп, сөенешеп, күңелле итеп ашап-эчеп утырдык. Бу минем Хәсән белән беренче тапкыр табын артында утыруым булды. Хәсән үзе дә беренче сәгатьләреннән үк мине, әйтерсең, аның бертуган абыйсы кайткан, бик җылы кабул итте, мөгамәләбез бик якын булды.

Кичен мәктәптә дәресләр тәмамланганнан соң, Хәсәнне гостинаяга (кунак бүлмәсенә) алып кердем. Ул бүлмә ширма белән бүленгән иде. Зур ягында йомшак диван, креслолар һәм

Г.Рафиков (уртада) 17 нче мәктәп укытучылары һәм укучылары белән. 2 нче рәттә: Әминә Бикчәнтәева (сул кырыйда), татар әдәбияты укытучысы Хәсән Туфан, Анна Катанова (күренекле тюрколог һәм этнограф Николай Катановның кызы). 1927 ел

Г.Рафиковның тууына 90 ел. Сулдан уңга: 17 нче мәктәпнең уку-укыту эшләре буенча директор урынбасары Былбыл Ильясова, Диләфрүз Усейнова-Хәйруллина, Хәсән Туфан, Әминә Бикчәнтәева, Әминә Рафикова, Гариф Гобәй, Хәбиб Рафиков. Казан, 1963 ел

«Зейлер» немец фирмасының пианиносы, ә кечерәк якта минем кровать иде. Анда һәрвакыт дәү әнием йоклый, ә мин кушеткада ял итә идем.

Бөтен гаиләбез шул бүлмәгә җыелды. Хәсән минем янымдагы креслога утырды. Мин пианинода «Тәфтиләү», «Сакмар буе» һәм башка борынгы татар халык җырларын уйнагач, аркамнан сыйпап: «Композиторлардан бер дә ким түгел», — дип мине мактап куйды. Дәү әнием, җанашым, елады, аннан соң әйтеп куйды: «Балакаем, син кайткач, бигрәк тә ямь керде өебезгә, рәхмәт төшсен. Хәсән дә мине бик ихтирам итә, аның ягымлы булуы минем кебек укый-яза белми торган надан карчыкның да күңелен күтәрә», — диде.

Шул биш-алты сәгать эчендә мин Хәсәнгә ияләнеп җиттем, әйтерсең, бала чактан ук бергә үскән, бертуган энем шикелле тоелды ул миңа. Әтиәнием дә Хәсәнгә килгән көннән үк үзләре тәрбияләп үстергән балалары кебек карадылар.

Хәсәннең бүлмәсе зур һәм ифрат та якты иде: биш биек тәрәзә, гомуми зурлыгы 25 квадрат метр. Бер сәгать чамасы Хәсәннең бүлмәсендә рәхәтләнеп сөйләшеп утырганнан соң, мин аңа тыныч йокы теләп чыгып киттем.

Әнием, бәгырькәем, без йокыдан торуга, иртәнге чәй янына бик күп

итеп ит пәрәмәчләре пешереп куйган. Бергәләп тәмле итеп ашап-эчкәч, әнкәебезгә рәхмәтләр укып, өстәл яныннан кузгалып киттек. Әтием белән Хәсән туганкаебыз дәрескә әзерләнер өчен учительскаяга кереп киттеләр.

Тәнәфес вакытында мин, учительскаяга кереп, таныш укытучылар белән күрештем. Миңа шунысы бик гаҗәп тоелды: тәнәфестә Хәсән ял итәргә кермәде, карасам, коридорның башында бик чибәр 15-16 яшьлек укучы кызлар һәм егетләр (егетләр дип тә булмас, малайлар), Хәсәнне чорнап алып, көлә-көлә гөрләшәләр иде. Хәсән үзе дә көлеп-көлеп ала, алар белән дәрес башланганчы сөйләште, әйтерсең лә үзенең кордашлары.

Хәсән дәресләрне югары классларда гына алып бара иде. Укучылар Хәсәнне бик яраталар, ихтирам итәләр иде. Ул аларга яхшы киңәшләр бирә, үзенең кордашлары кебек карый иде.

Кайсы көннәрне дәрестән соң укучы Гамир Насрый кереп чыга иде. Хәсән аның турында безгә: «Ул бик билгеле, танылган шагыйрьләрнең шигырьләрен зур ихлас белән дәртләнеп укый һәм шигырь язу кагыйдәләрен өйрәнү буенча һаман киңәш сорый», — дип әйтә иде. Гамир Насрыйның шагыйрь булачагына Хәсәннең ышанычы зур иде.

Кышларга өйгә кайткач, мин ике-өч көнгә Фатих ага Әмирханны үзебезгә алып килә идем. Аның Хәсән белән беренче тапкыр очрашуы да безнең өйдә булды. Фатих ага Хәсәннең кулын кысты һәм: «Мәрхабә, Хәсән туганкай, хуш килдең, бик шатмын сине күрүемә. Ерак Уралдан килгәнсең икән, заводларга бик бай яктан, файдалы мәгъдәннәр (җир асты байлыклары, рудниклар. — Л.М.) белән зур дан тота торган Уралдан», — диде. Чәй эчеп, табын яныннан киткәннән соң, Фатих абый Хәсәнгә карап әйтте: «Хәсән туганкаем, Габдрахман абый, Рабига апа гаиләсендә бергә яшәве үзе зур бәхет, аларга да бик күңелле, син инде аларның икенче уллары булдың. Мин үзем дә рухани да, мәгънәви дә яхшы ял итеп, күңелләрем күтәрелеп китәм. Бу кадерле гаилә минем өчен иң якын туганнарым кебек. Сиңа да, яшь дускаем, эшләреңдә зур уңышлар, бергә сау-сәламәт, матур яшәвегезне телим».

Икенче көнне иртән Хәсән белән әти дәрескә кереп киткәч, чәй эчеп утырганда, Фатих абый әнигә әйтеп салды: «Хәсәннең үз-үзен тотуы, әйтерсең, Һади Такташ белән бер анадан туганнармыни. Мин бик шатмын, сезнең гаиләдә яхшы укытучы да һәм шагыйрь дә яши. Әлбәттә, ул инде киләчәктә шагыйрьлек юлы белән китәр һәм Тукай, Такташлар белән бер сафтагы шагыйрь булыр. Ул миңа язган шигырьләрен укып күрсәтте, миндә бик яхшы тәэсир калдырды».

Кайсы көннәрне Хәсән дәрестән бушагач, кич белән һәм ял көннәрендә, аның янына дуслары килеп чыга иде. Һади Такташ әүвәле безгә сирәк керсә дә, Хәсән яши башлагач, ешрак күренә башлады. Аның белән бергә Риза Ишморат та килә иде. Гомәр Гали, артистка Галия Булатова килгәндә, безнең өйдә сөйләп бетермәслек күңеллелек була иде.

Мартның 15-20ләрендә мин, навигация ачылыр алдыннан, пароходым кышлаган затонга китә идем. Әткәем белән әнкәем: «Синең белән аерылышу авыр булса да, яныбызда сөекле улыбыз Хәсән кала, ул булмаса, бөтенләй күңелсез булыр иде», — дип әйтерләр иде.

Идел ачылып, Казанга пароходым белән килеп туктагач, әти-әнием һәм туганым Хәсән, бәгырькәйләрем, мине бергәләп каршы алалар иде. Әниембәгърем өйдә пешкән ризыклар алып килә иде. Мин, үз чиратымда, осетрина балыгыннан пешергән солянка белән аларны сыйлый идем.

Кайвакыт Хәсәнгә ияреп, Һади Такташ та килә иде. Алар пароход Казанда торган вакытта, югарыгы палубага менеп, Иделнең матурлыгы белән сокланып карап торырга ярата иделәр.

Туры килгәндә, наркомфин булып эшләүче Каюм Мәһдиев һ.б. дусларым һәм туганнарым да төшә иде.

Хәсән пароход киткәнче 1, 2 класслар палубасына менеп, йөреп төшә иде. Берничә мәртәбә палубаны әйләнеп чыгып, саф һаваны иснәп, акчарлакларның, Идел өстендә очып, гөрләшеп, үзләренчә су өстенә төшеп, балыклар кабып алуларын бик зур әһәмият биреп, табигатьнең матурлыгына сокланып карап утыра иде.

Пароходның китәр сәгате җиткәч, әткәем, әнкәем, туганым Хәсән бәгырькәйләремне кочаклап, үбеп саубуллаша идек. Пароход кузгалып киткәч, әтиәниләрем бераз күз яшьләре төшерәләр, Хәсән туганкаем да моңаеп, өчесе бергә озатып кала, күздән югалганчы яулыкларын селки иделәр.

Хуш, туган, матур Казаным! Тагын 12 көнгә газиз туганнарымны, дусларымны күрмичә, иркен, киң күкрәкле Иделдә йөрим. Сызылып таң атканда, урман яки тау артларыннан кып-кызыл булып кояш күтәрелгәндә, Идел буендагы урманнардагы сандугачлар һәм башка җырчы кошларның сайрауларын, пароход артыннан су өстенә төшеп, күтәрелеп уйный торган акчарлакларны карап, тыңлап, табигатьнең матурлыгына сокланып туймый идем.

Хәсән җәйләрне Казанда үткәрми иде. Ул үзенең туган авылына һәм башка шәһәрләргә дусларына сәяхәт кыла иде.

Навигация ябылып, мин Казанга кайткач, өйдә күңеллелек тагын да арта. Хәсәннең дуслары да, минем яшь укучы һәм башка якын дусларым да бергәләп сөйләшеп утырырга ярата идек. Мин шәһәрдә вакытта Фатих абый Әмирхан бездә еш була. Мин ике ай буе отпускта булып, ул килгәннән соң, беркая да чыкмый идем — ул бигрәк тә шуны ярата иде. Хәсән белән әткәем дәрестә, ә без — әнкәем, Фатих абый һәм мин табын артында озак-озак сөйләшеп утыра идек.

Хәсән дәрестән чыккач, кич белән Фатих абый аның белән бик озак мөзакәрә кылып *(фикер алышып. — Л.М.)* утыралар. Кайвакытта Фатих абый белән Гадел Кутуй, Һади Такташ, Гомәр Гали, Риза Ишморат килә иде. Хәсән барында безнең өебез әдипләр, язучылар, шагыйрьләр йорты кебек иде.

Бәйрәм көннәрендә профессор Мөхәммәтхан абзый Фазлуллин, Хәсән белән бергә укыткан Заһидә Тинчурина, Кәрим абый Тинчурин, Фәрит ага Хәсәнов һәм аларга кушылып Шәриф ага Камал да (аның агасының кызы Зәкия Байгилдиева укытучы иде) килеп чыгалар. Әтинең күптәнге дусты профессор Мөхетдин Корбангалиев, ә иң зур бәйрәмнәрдә Галимҗан Нигъмәти килә иделәр. Мәфруха ханым Ситдыйкова Хәсән белән бергә укытканга күрә, тантаналы кичәләрдә аның иптәше, Киров районы партия оешмасының беренче секретаре Гариф Ситдыйков та килеп чыга иде. Гаҗәеп, бик ягымлы, һәркемгә яхшы карашлы, якты чырайлы, һәр кешене илтифат белән тыңлый белүче, бик сөекле бу кеше шәхес культы дәверендә һәлак булды. Яшь булса да, Киров районы өчен ул, чын мәгънәсендә, матур хатирә калдырды.

***

1928 елның 10 мартында, мин иртәгә юлга чыгам дигән көндә, түгәрәк табын янына җыелыштык. Ашап-эчкәннән соң, мин һәркайсының теләгән көйләрен пианинода уйнадым. Хәсән минем Тукай сүзләренә язылган «Туган тел» көен уйнавымны үтенде. «Концерт» тәмам булгач (көлеп шулай әйтәм), бүлмәләребезгә таралыштык.

Иртән чәйләр эчкәч, барысы белән дә күрешеп чыктым. Белмим, ни өчендер (күңелем сизгән кебек), Хәсән белән саубуллашу бик моңлы булып, күңелемә авыр тоелды. Бу безнең бер гаилә булып яшәвебезнең соңгы минутлары булды. Мин аны кысып ко-

чаклап, үбеп саубуллаштым. Әткәем белән Хәсән туганкаем укытырга кереп киттеләр. Ә без әнкәем һәм сеңелем Әминә Бикмуллина белән тимер юл вокзалына киттек. Поезд кузгалып китте, әнкәем-бәгырькәем елап калды.

Мәктәптә имтиханнар беткәч, Хәсән туганкаебыз, безнең гаиләдән аерылып, июль айларында Урта Азия, Кавказ шәһәрләре, авыллары буйлап сәяхәткә чыгып китә.

Хәсән белән аннан соң сирәгрәк күрештек. 1937 елның 27 апрелендә мине, пароходларны сайга утыртучы, дәүләт милкен бозучы, диверсант һәм милләтче дигән сылтау белән (бу ел бик коры килде һәм шул сәбәпле Иделдә су кимеп, пароходлар ләмгә утыргалады), зинданга яптылар. Хәсән туганкаем белән бары тик 1956 елда гына *(Х.Туфан 16 ел буена төрмәдә һәм лагерьда булып кайтканнан соң. — Л.М.)* күрешә алдык. Ул әткәем-бәгырькәемне күрә алмады *(Г.Рафиков 1954 елның 3 маенда вафат була. — Л.М.)*.

Безгә зур бәхет насыйп булды — Хәсән дә, мин дә, башка дусларыбыз да зур афәтләрдән исән-имин котылдык. Хәсән кайткач, мин аның Свердлов урамындагы фатирына бардым. Хәсән кайтырга бер ел кала аның якты чырайлы сөекле иптәше Луиза ханым вафат булган, дүрт яшьтә калган кызы Гөлгенә әтисе кайтканда 21 яшьтә иде. Аяныч хәл, нинди аяныч тәкъдир.

20 ел аерылышып торганнан соң, күрешү бик авыр булды, Хәсәнне нык кочаклап, үбеп, тәкатем тота алмыйча еладым. Аның да күзләреннән яшь тамды. Мин барында дуслары, туганнары да килделәр. Озак утырмадым, кешеләр бераз азрак килә башлагач, килергә вәгъдә итеп, үзен чакырып китеп бардым.

Шуннан соңгы Яңа елны, 8 март, май вә башка бәйрәмнәрне бергә үткәрә башладык. Мәҗлес бездә үткәндә, килгәннәрнең күбесе нахакка михнәт чиккән кешеләр иде: Хәсән Туфан, Әхмәт Галиев, Хәйбик Сибгатуллин, шәхес культы дәверендә һәлак булган Кыям Абрамовның иптәше Җиһан Бадамшина-Абрамова, Харис Найков һ.б. Шул чорларда кулга алынмыйча, бәхетле гомер кичергән туганым, доктор Н.С.Вәлиев иптәше Камилә белән килә; якын дустыбыз, Татарстанның атказанган артисткасы Сара Садыйкова ул мәҗлестә үзе язган һәм халкыбызның иң матур җырларын, Фәйзи Биккинин бәгырькәем үзенең төрле гармуннарында һәм скрипкада уйный иде. Гастрольләрдә булмаганда, Илһам Шакиров та бу мәҗлесләрдән баш тартмый, моңлы җырларын җырлый иде. Бервакыт шагыйрә Гөлшат Зәйнашева һәм Фатыйма Ильская да килеп чыктылар. Касыйм Таһиров, Хәсән Хәйри гаиләләре дә бездә кунакта була иде.

Быел *(1971 елда. — Л.М.)* озак күрмәгән дустым Мәхмүт Бөдәйли, М.Галиев һәм мәҗлесебезгә ямь бирүче Х.Туфан белән бик озаклап сөйләшеп утырдык.

Үзем генә түгел, гаиләм өчен дә Хәсән Туфан иң кадерле, якын туганыбыз булды. Озак күрми торсам, үзем дә барып чыгып, аның хәлен белеп кайтам. Аның янына барсам, бигрәк тә Аккош күленә, ярты авыруым бетә. Үткән гомерләрне сөйләшеп, Такташларны, Кутуйларны, Ф.Әмирхан, Гомәр Гали, Галимҗан Нигъмәти һ.б. бик яхшы уртак танышларыбызны искә төшереп алабыз. Ул минем рухымны күтәрәме, урман һавасының да яхшы тәэсиредер — мин өйгә яшь егетләр кебек кайтып керәм.

Хәсәннең иптәшем Әсмага һәм миңа әйтеп куйган сүзләре гел искә төшә: «Рабига апа белән Габдрахман абыйның якын дусларны хөрмәтләү һәм ихтирам итү гадәтләрен, иске дуслар белән элемтә тотуны дәвам итәрсез».

Язмаларны басмага педагогика фәннәре кандидаты ***Ләлә Мортазина*** *әзерләде.*

ТАТАРСТАННЫҢ ХАЛЫК ШАГЫЙРЕ,
ГАБДУЛЛА ТУКАЙ ИСЕМЕНДӘГЕ ДӘҮЛӘТ ПРЕМИЯСЕ ЛАУРЕАТЫ

ФӘНИС ЯРУЛЛИН

(09.02.1938 – 09.12.2011)

ҖЫР КАЛДЫРЫЙК

Кеше китә — җыры кала, диләр,
Бер җыр калсын әле бездән дә.
Ул җыр җанга шатлык булып керсен,
Кояш булып кунсын йөзләргә.

Без һәммәбез җирдә берәү генә,
Беркемнең юк җирдә алмашы.
Кабатланмас үз язмышы белән
Туа җиргә адәм баласы.

Җыр калдырыйк җирдә, нур калдырыйк,
Җырда калсын безнең гомерләр.
Безнең дөрләү, безнең януларны
Киләчәккә җырлар илтерләр.

*Шагыйрь Фәнис Яруллинның кайбер сүз энҗеләрен журнал битләреннән чүпли аласыз.

СӘНГАТЬ

Бәгыремдә, бәргәләнеп,
Җырланмаган җырлар яна.

Фәнис Яруллин

РАУЗА ХӘЙРЕТДИНОВАГА 85 ЯШЬ

ҮГИ КЫЗДАН – МӘЙСӘРӘГӘ

ЛУАРА ШАКИРҖАН,
Татарстанның халык артисты

АРТИСТЛАР ТӨРЛЕ БУЛА... БЕР ТЕАТР СӘХНӘСЕНДӘ УЙНАСАЛАР ДА, ТӨРЛЕСЕНДӘ ТӨРЛЕ ЯЗМЫШ, ТӨРЛЕ ИҖАТ ЮЛЫ. ГАЛИЯБАНУНЫ БЕРЕНЧЕ ТАПКЫР УЙНАГАН ҖЫРЧЫ АКТРИСА ӘШРӘФ СИНЯЕВА КЕБЕК КЫСКА ГЫНА ГОМЕР ЯШӘП ТӘ, ТАРИХТА КАЛГАННАР БАР; ГОМЕР БУЕ СӘХНӘ АЛИҺӘСЕ БУЛЫП, ШӘХСИ ТОРМЫШЫ ЮГАЛТУЛАРДАН ТОРГАН ФАТЫЙМА ИЛЬСКАЯДАЙ ЙОЛДЫЗЛАР ДА; ГАИЛӘДӘ БИК БӘХЕТЛЕ БУЛЫП ТА, СӘХНӘДӘ КАНӘГАТЬЛЕК АЛМАГАННАРЫ ДА; ИҖАТЫ, МӘХӘББӘТЕ ЯРТЫ-ЙОРТЫ ГЫНА БУЛГАННАРЫ ДА...

Музыкаль героиняларны уйнап, халыкның күңеленә кереп урнашканы, матур гаилә корып, яратып, яратылып, тигез гомер иткән, бала бәхете, оныклар шатлыгын кичереп, 85 яшькә җиткәне исә — Россиянең атказанган, Татарстанның халык артисты Рауза Хәйретдинова гына шикелле... Бу язмам Аңа багышлана.

Әкиятләрдә булсынмы яисә чын тормыштамы, балачактан ятимлек ачысын үз җилкәсендә күтәргән, авыр эшкә җигелергә мәҗбүр ителгән, үгилекне татыган кыз бала моңлы күзле, аз сүзле булырга тиеш кебек... Һәм, киресенчә, безнең Рауза апа шикелле һаман шат елмаеп торган, һәрнәрсәдән тәм табып, матур яңгыравык тавышы белән кычкырып көләргә яраткан, тынгысыз, көяз дә, наян да, аралашучан, ачык күңелле кеше — һич кайгысыз яшәгән, бәхетле сабый булып үскәндер дигән тәэсир калдыра. Рауза Хәйретдинованы тормышта аз белүчеләр, мөгаен, аны әнә шулай бер авырлык та күрмәгән иркә җан дип күз алдына китерәләрдер дә... Ә ерак балачак хатирәләренә күз салсаң, Котдус абзый гаиләсенә кара кайгының ничек килеп кергәнен тыңласаң, әкиятләрдәге ачы язмышлы ятимә белән үсмер кыз Раузаның күргәннәре тәңгәл булып чыга...

Хәер, мәңге истән чыкмас рәхәт, бәхетле сабый вакыты да бар иде аның... Туган авылының (Балык Бистәсендәге Яңа Ырга авылы) чирәмле сукмаклары, су буйлары, әтисенең гармунда уйнап утырулары, әнисенең кушылып җырлаулары... Авылдагы мәдәни-рухи тормышның үзәгендә кайный иде аның укытучы әти-әнисе. Тылсымлы патефон да аларда гына иде ул чакта, велосипед дигән могҗиза да аның әтисендә генә иде. Ә өйләре китапханә күк: китап-

«Зәңгәр шәл» (К.Тинчурин) спектакленнән күренеш. Рольләрдә: Булат – Наил Әюпов, Мәйсәрә – Рауза Хәйретдинова. 1970 ел

лар, журналлар... Шул журнал тышларындагы сихри сурәтләр: Кайбицкая, Кушловская, Ильская, Даутов... Үзен бик тә алар арасында хис итәргә теләгәнме — бу рәсемнәрне ул диварга да ябыштырган, һәм алар, әйтерсең, зәңгәр күзле, дулкынланып торган куе җитен толымлы, бит чокырлары нур белән тулган кызны үз артларыннан ияртәләр. Монысы соңрак, ә ул чакта әле кечкенә Рауза әти-әнисе белән концертларга йөри, шигырь сөйли, гармунда уйный, җырлый. Халык әйтсә, хак әйтә, ди. Уйлап әйттеләрме, уйламыйча рас китерделәрме... Балалар уйнаган «Үги кыз» тамашасыннан соң, Раузаның җырлаганын ишеткән авыл хатыннары: «Әй, моңлы да җырлый инде, ятим генә калмагае», — диләр. Кыз баланың үзәгенә үтеп истә калган бу сүзләр...

Сугыш башлануга, дөньяның асты өскә килә. «Әти-әни», дип иркәләнгән балачак та шунда бетә. Әтисе фронтка китеп, сигез ай үтүгә, кырык яше дә тулмаган Сара апа, өч сабыен калдырып, бакыйлыкка күчә. «Балаларымнан аерып, больниска салырлар», — дип куркып, табибка да күренмичә, әллә тифтан, әллә салкын тиюдән өзелә аның яшь гомере. Җиде яшьлек энесенә, тугыз яшьлек сеңлесенә әти дә,

әни дә булып кала унөч яшьлек Рауза. Ышанмассың да... Утын әмәлләп мич яга, өйне җылыта, әйтерсең, эш белән берни сизми, ә өчәүләп утырып чәй эчкәч, почмак тәрәзәсеннән күренеп торган зиратка карап, өч ятим үкереп-илереп еларга тотына... Һәркемнең үз кайгысы, үз мәшәкате булса да, авылдашлар хәленнән килгәнчә, ятимнәргә ярдәм кулы суза. Әнә шулай «мир» белән сугыш еллары уза: кышкы төннәрдә урманнан утын ташу, эссе көннәрдә урак уру, йорттагы сыерны саклар өчен печән чабу; шул сыер сөте коткара да — май атлатып, ипи кисәгенә алыштыру, үсә төшкәч, хатыннар белән Казанга алып барып сөтмай сату, урын-җир җәймәсе алып, аннан күлмәк тегү... Халык артистының хәзер инде бармакларында кыйммәтле ташлар ялтыраган бу куллары нинди генә авыр хезмәт күрмәгән!..

Сугыш бетә, Котдус абый исән-сау әйләнеп кайта, яңа гаилә кормый булдыра алмый. Буй җитеп килгән Рауза, туганнарын әтисенә тапшырып, Казанга чыгып китә. Ник дисәң, сәбәбе бар... Казанда яшәүче кардәшләренең кызы Раузаның җырларга яратуын, «әртис» җене кагылу бик яхшы белгәнгә, 1946 елда татар театр студиясе ачылу турында хәбәр җибәрә. Аларның җиде балалы гаиләсенә сигезенче «кашык» килеп тә җитә.

Сәхнә өчен кирәкле буй-сын, төс-кыяфәт, матур сөйләм, темперамент, өстәвенә, табигать биргән һәм бернинди остазларсыз табигый рәвештә консерватория дәрәҗәсендә эшкәртелгән саф көчле тавыш (колоратуралы сопрано) студия җитәкчесе Нәҗип Гайнуллинны да, башка укытучыларны да әсир итә. Менә шулай Хәйретдинова театр дөньясына кереп китә. Тормышның

«Назлы кияү» (К.Тинчурин) спектакленнән күренеш. Рольләрдә (сулдан уңга): Гөлбану – Гәүһәр Камалова, Нәгыймә – Рауза Хәйретдинова, Рамазан – Наил Әюпов. 1975 ел

гүзәл яклары ачыла. Әмма Раузаны театрдагылар гына белгән ачы сынаулар көтә... Алкышлар, чәчәкләр, котлаулар, җыр, уен-көлке тулы сәхнә тормышында нинди ачы сынау булырга мөмкин соң? Бик талантлы булу, сандугачтай тавышың белән тамашачының сөеклесенә әйләнү — бу үзе дә сынау. Мактанып китеп, борын күтәрүчеләр дә аз түгел (шөкер, ул чир йокмады аңа). Тыштан елмайса да, эчтән уңышыңны күпсенгән кайбер сәхнәдәшләр белән дустанә кала белеп, иҗат итү өчен зирәклек тә кирәк була — бу да сынау. Авылдашларыннан эчкерсезлек, ярдәмчеллек кенә күреп үскән кызга, дөресен әйтергә кирәк, сәнгать дөньясына ияләшү җиңел булмый.

Ә мактаулар Рауза апага үз гомерендә бик күп ява һәм бары үз тырышлыгы нәтиҗәсендә. Бу — аның төп сыйфаты. Эшсез тора алмавы, эчке батырлыгы, режиссёр бирмәгән рольне дә үзлегеннән өйрәнеп, һәр репетицияне залдан булса да үзе аша үткәреп утырулары — берсе дә бушка китми. «Шәмсекамәр»дәге җырчы Разияны да, Галиябануны да шулай әзерли ул һәм үзенә ышаныч яулап ала.

Сәхнәдә узган гомерендә төрле исемнәр астында, адәм баласына хас сыйфатларның барысын да сурәтләп күрсәтте ул: эшчән, ялкау, мәкерле, эчкерсез, кайгыртучан, эгоист, нечкә күңелле, тыйнак, шаян, шат, кайгылы, тупас, хәйләкәр... Бер-берсенә капма-каршы холыкта булган рольләр Хәйретдинова башкаруында гаҗәеп табигый килеп чыга, шулкадәр ышандыра, сокландыра: нинди бай, күпкырлы бу артистканың сурәтләү сәләте, үзгәрә белү таланты... «Разведчиклар» исемле диплом спектаклендә үк, сөйгәнен эзләп сугышка киткән һәм һәлак булган җырчы артистканы уйнаганда, укытучылар көн дә күреп торган тыйнак авыл кызын, талибәне танымыйлар хәтта. Мәшһүр Фатыйма Ильская киеп уйнаган модалы ак тунны да киеп алгач, чын җырчы кыяфәтенә керә дә куя!

Тышкы кыяфәт дигәннән, Рауза ханым һәрчак бизәнү әйберләре, киемсалым детальләре белән дә үз героинясының эчке халәтен ачарга омтыла. Бигрәк тә характерга корылган рольләрдә — ә андыйлар артист репертуарында байтак. Г.Әпсәләмовның «Сүнмәс утлар» романы буенча куелган спектакльдә аңа кыланчык, җилбәзәк Идмас ролен бирәләр. Аннан соң М.Горькийның «Дошманнар»ында үзе турында югары фикерле, бәйләнчек Клеопатра роле эләгә. «Шушы рольләр белән бетерәм икән үземне», — дип коты чыга яшь артистның. Ашау-эчү онытыла. Образга «азык эзли-эзли» кешеләр белән кешечә сөйләшүне оныта... Йокысыз төннәр бушка китми — бу рольләр дә аның иҗат биографиясен бизәп, баетып тора.

Рольләр күп — йөз утызлап. Әлбәттә, артистканың үзе өчен, тамашачы өчен театр тарихына җәүһәр булып кереп калулары белән Мәйсәрәгә, Галиябануга тиңнәр юктыр. Үз гомерендә шушы рольләрне генә уйнап калса да, ул халык күңелендә булыр иде. 1956 елда сәхнәгә — Рауза ханым бәхетеннән дә — Кәрим Тинчурин исеме һәм «Зәңгәр шәл», «Казан сөлгесе» кайта. Бөек драматургка, аның Мәйсәрәсенә, Мөршидәсенә данлы, озын сәхнә гомерләре биреп, дистә еллар уйный ул бу әсәрләрдә. Тышкы матурлыгы, җырчы һәм драматик талантының бергә туры килүе белән бердәнбер Мәйсәрә әле ул сиксән җиде еллык тарихы булган бу мелодрамада. Кызганыч, Тинчуринга да, Сәйдәшевкә дә бу Мәйсәрәне күрергә туры килми. Хәер, Галиябануны күргәч, Мәйсәрә итеп күз алдына китерми калмагандыр Салих агасы талантлы кызны... Күренекле композитор А.Ключарёв та, сокланып: «Мондый чиста, саф тавышны әле ишеткәнем юк иде», — ди.

Төрле милләт авторларының әсәрләрендә уйнаса да, Р.Хәйретдинова —

Рауза Хәйретдинова тормыш юлдашы Нури Ганиев белән

чын мәгънәсендә, татар халык артисты, аның бөтен күзәнәге миллилек белән сугарылган. Җанга рәхәт, күңелгә якын аны сәхнәдә күрү, тыңлау, хәтта тискәре образлары белән дә күңел түренә уза ул: көлдерә дә, гыйбрәт тә бирә, уйландыра да, нәтиҗә дә ясата. Бу сүзләрне язу, әйтү җиңел. Шуны сәхнәдә ышандырырлык итеп күрсәтү генә бик сирәкләргә бирелгән. Р.Хәйретдинованың бөтен рольләрен санап чыгу мөмкин түгел: Гөлбану («Татар хатыныниләр күрми», Г.Ибраһимов), Айсылу («Миркәй белән Айсылу», Н.Исәнбәт) кебек лирик героинялардан соң Кәләмзә («Зифа», Н.Исәнбәт), Сания («Качаклар», Н.Исәнбәт), Мөршидә («Ташкыннар», Т.Гыйззәт) кебек дистәләрчә кызык, чая холыклы образлар тудыру остасы да булып китә ул.

Рауза апаның тормышны, кешеләрне яратуы, март кояшыдай балкып үзенә тартып торган шәхес булуы хакында да аерым әйтим. Аның яше юк — яшьләр арасында да ул һәрчак үз кеше. Аралашканда, нәкъ синең яшьтәшең кебек; шул ук вакытта, дөрес киңәшен, тәнкыйтен, олыларча акыллы сүзен дә ишеттерер (Г.Исхакыйча фикерли ул: кемнең булса гаебен, кимчелеген әйтми калу — аның шул хәлендә калуын теләү булыр иде) һәм дә якты талантларга хас балаларча эчкерсез беркатлылыгы белән көлдереп тә алыр. Берәр төрле тәмле ризык әзерләү серен дә сөйләп өлгерер. Үзе мактанмас һәм мактанчыкларны да үз итмәс. Әмма гади тамашачыларның, үзе дә белмәгән бик күп кешеләрнең, авылдашларының, якташларының «Рауза апабыз» дип һаман танып исәнләшүләренә, әллә кайчан уйнаган рольләрнең сүзләре белән эндәшүләренә, хатлар язуына чын күңелдән куана ул. «Тормышымның мәгънәсе, матур нәтиҗәсе булды бит, бар бит», — дип иҗатының күңелләрдә эз калдыруы белән горурлана ул.

Рауза апа — бәхетле артист. Алтмыш елга якын сәхнә тотуы белән бәхетле. Табигать биргән сәләтне, илһамны куллану фарыз, ди бит. Аның иҗаты, җырлы язмалары — кояшлы күкне, чишмәләр, киң болыннарны күз алдына китереп, күңелдә яшәү көчен арттыра. Ә сәнгатьнең изге вә җаваплы миссиясе әнә шул.

Рауза апа — бәхетле кеше. Үзәкләре өзелгәндә, «әни» дип әйтер кешесе булмаса да, аның үзенә «әнкәй» дип, «дәү

әни» дип өзелеп әйтүче улы, килене, оныклары бар. Сәхнәне сөйгән кебек, гомере буе гаиләсен, бердәнбер һәм гомерлек яшьлек мәхәббәтен — ирен, йөрәк парәсе — улын сөеп, тәрбияләп яшәргә һәм дә иҗат итәргә көч, мөмкинлек, вакыт таба белгән сирәк артисткаларның, уңган-булган хуҗабикәләрнең берсе ул. Уллары Марат — гаҗәеп инсафлы, укымышлы (хәрби белем өстенә, тагын бер югары уку йортын тәмамлап, докторлык диссертациясе яклаган). Лариса да бик уңган килен, кызлары кебек якын. Ул да заман белән бергә атлый, ике югары белеме бар, үз һөнәре өлкәсендә хөрмәтле җитәкче. Оныгы Марина — чит телләр белгече, Тимур да, бу гаиләгә хас рәвештә белемгә омтылып, әти-әнигә, әби-бабайга хөрмәт, мәхәббәт белән тәрбияләнә. Ә инде Рауза апаның ире — 60 ел буе тугрылыклы юлдаш, таяныч, киңәшче булган Нури абый турында бер җөмлә генә булса да әйтми калу мөмкин түгел. Бу парның мәхәббәте риваятькә тиң, уены-чыны белән әйтсәм, Нури ага кебек ир-атны мин «сирәк очрый торган зат» дип, Кызыл китапка кертер идем. Ул Раузасын өрмәгән җиргә утыртмас. Сәхнәдә мәхәббәт сылуларын уйнаган чибәр артистның ире булу, мондый сынауга түзү — аның үз көченә һәм сөйгәненә нык ышануы дигән сүз. Мәйсәрә булып унбиш ел берсеннән-берсе асыл Булатлар — А.Аббасов, А.Арсланов, М.Имашев, Н.Әюпов кочагында назланган артистның күз нуры исә һәрчак үз Нуриена төбәлгән иде. Нури — аның өлешенә чыккан көмеше. Туган авылындагы «Нури чишмәсе»ннән су алып кайтканда, «бәхетемне бир, Ходаем», дип юкка гына теләмәгән икән шул. Нуретдин исемле егет Балтач районының Хәсәншәех авылыннан. Ул да кечкенәдән тормышның бөтен ачысын татый. Уналты яшьтә үзе теләп фронтка китә, 1951 елда гына Казанга кайта. Куйган максатына ирешә торган, булдыклы, эшчән, тырыш кеше ул Нури абый. Кичке мәктәптә, университетта, аспирантурада укый, фәлсәфә фәннәре буенча диссертация яклый, медицина институтында укыта. «Мин Нуриемнан башка уңышларга да ирешә алмаган булыр идем, ансыз саулыгым да, байлыгым да, бәхетем дә булмас иде, иҗатым да уңмас иде», — ди Рауза апа, сөйкемле бит чокырларыннан нурлар чәчеп. Нури абыйны без күптән театр кешесе итеп күрәбез. Алар гел бергә. Нури абый кайсы елны нинди спектакль куелганын, режиссёры, катнашучылары кем булганын һәм, әлбәттә, сөекле Раузасы кемне уйнаганын төнлә уятып сорасалар да белә. Р.Хәйретдинова исеме кергән һәр мәкалә, программа, фоторәсемнәр тәртипләп җыелган. Рауза ханым башкарган җырларның музыкаль альбомы һәм «Гомер сәхнәсе» дигән китабы өчен дә без әле Нури абыйга күбрәк рәхмәт әйтергә тиештер. Бу китапта Рауза апа үзе турында гына сөйләми, истәлекләрдә — театр тормышы, сәхнәдәшләр язмышы. Шуңа да ул безгә һәм киләчәк буыннар өчен әһәмиятле. Әнә шулай: күренекле артистыбыз лаеклы ялга чыккач та, яраткан театрын уйлап яши. Татар хатынкызының холкы-фигыле, асылда, менә шундыйдыр ул — сабыр, тыйнак, эшчән генә түгел, җор сүзле, шат күңелле, үзенә каратып торырлык, үз артыннан әйдәрлек, дәртле, кыю, югалып калмас, башын имәс, талантлары белән ирләрне дә көнләштерерлек гүзәл зат. Шуңа да яшидер татар халкы!

Афәрин, рәхмәт, Рауза апа!

Гомер үтәр, юк шул әле
Мәңге яшәү хәйләсе.
Ханбикәдәй онытылмассың,
Татарның Мәйсәрәсе! ■

АЛЬТЕРНАТИВ... ЯКИ КИНӘСЕЗ КИНО*

ӘХТӘМ ЗАРИПОВ,
режиссёр, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе

– Узган көз миңа документаль фильм өчен кунак каршылау һәм каз йолку өмәсен видеога төшерергә Башкортстанның татарлар гына яшәгән бер авылында булырга туры килде. Фатирга ире — мәктәп директоры, хатыны фельдшер булып эшләгән зыялы бер гаиләгә керттеләр. Кич белән үзебез төшергән музыкаль фильмны күрсәтеп, тамашачылар белән очрашу-әңгәмә кору да иде ният. Кызганычка, очрашуга фатир хуҗаларыбыздан башка кеше килмәде. Гаҗәпләнүебез чиктән ашкан булса да, сер бирмәдек, пассивлыкны бәйрәм көн булуга сылтап, өйгә кайттык, чәйгә утырып, әңгәмә кордык.

— Театрлар килгәндә дә шулай хәзер. Билетны сатып ала, карарга керми. Шар суга, туп бәрә...

— Сәбәп?

— Заманында Ленин бабабыз: «Сәнгать төрләреннән иң мөһиме кино», — дигән булса да, бүген массаларны көрәшкә оештыру коралы буларак, киноны беренче урынга куеп булмый. Телевидение һәм интернет хакимлек иткәндә, кесә телефоннары котырып үрчегән заманда киноның оештыру, туплау коэффициенты элеккедән күпкә түбәнәйде. Лозунглар да үзгә хәзер. Элек, чынлап та, «важнейшим искусством для нас является кино», дисәк һәм ул үзен акласа, хәзер исә «из всех кино важнейшим является искусство» категориясенә кертерлек киноның соңгы елларда күренгәне юк. Суррогат басты дөньяны, каплады. Реклама шаушуы белән сарыф ителгән акча күләме генә — фильмның сәнгатьчә сыйфатын билгеләгән төп күрсәткеч, аның халык телендә урын алуы, фольклорга үтеп керүе. «Чапаев» фильмыннан соң, аның каһарманнары турында үрчегән анекдотлар әле хәзер дә кызыклы...

Теликта үзен гел кинофильм карап утырырга мәҗбүр ителгәнгә күрәдер, россияле аннан котылу әмәлен эзли — карамый. Караса да, күрми, ишетми. Шул юл белән ул үзен саклый, саулыгын, сафлыгын саклый.

— Сезнең өчен нәрсә генә кызык соң?

— Үзебезнең язмышлар, үзебезнең тарих, үзебезнең киләчәк! Кеше кинодан үзен эзли. Тапмагач, аңа битараф кала. Элек исеректән көлдек. Хәзер наркоманнан. Шул хәлдә калуның сәбәпләрен күрсәтүдән куркып, нәтиҗәне генә күрсәтәбез. Бик күп фильмнарда тамашачыны катлаулы спецэффектлы кадрлар белән шаккатырмакчы булалар. Иң кызыклы спецэффект ул — Кеше! Сез, кала халкы, без — сала халкын үзегезне аңламауда, тәрәккыяттән калышуда гаеплисез, безне «провинциаллар», дисез. Шушы күренеш үзе үк «провинциализм» түгелме? Мин үзем гомер буе авылым мәктәбендә тарих, география фәннәрен укыттым.

*Дәвамы. Башы журналның 1 нче санында

Дөресен әйткәндә, гомер буе ялган сөйләргә мәҗбүр идем. Мин генә түгел, бөтен ил ялган сөйләде, ялганга ышанды, ялганга өндәде. Тарихчылар гына түгел, сәнгатькәрләр дә. Бүген дә ялган күп. Аны фаш итүгә бик сак киләбез. Мәсәлән, быел беренче класска керерлек яшьтә авылда бер бала да юк. Киләсе елга икәү. Исән үссәләр. Чөнки берсенең ата-анасы алкоголик, икенчесенең атасы кем икәне дә билгесез. Менә сез авылда кунак каршылау, кунак сыйлау йолаларын кинога төшермәкче идегез. Булмады. Чөнки кешеләре белән бергә йолалары да үзгәрә, кайда да «оптимизация» бара. Менә сезгә фильм өчен материал! Ник төшермисез?

...Менә шушындый сөйләшү булды безнең экспедиция вакытында. Әлбәттә, күңеллерәк очрашулар да булгалый. Ләкин бусы үзенең ихласлыгы белән күңелдә аерым урын биләде һәм һәрчак үзен хәтерләтеп тора: дөрес яшибезме? Яшәвебезнең рәвешен һәм максатын дөрес аңлыйбызмы, дөрес чагылдырабызмы?

— Юк, дөрес түгел! — диде күршем.

— Компьютерлар һәм интернет заманы килде. Киләчәктә китап белән генә түгел, фильмнар белән дә нәрсә булуын әйтеп булмый. Мәдәният цивилизация белән кайчан чишелүе билгесез булган каршылык халәтендә яши. Кешелекне нәрсә көтүе турында фаразлар күптөрле. «Дөнья матур, дөнья киң!» — дибез. Шул матурлыкны, шул киңлекләрне саклау өчен кулдан килгәнне дә, килмәгәнне дә гамәлгә ашырырга тырышу — безнең изге бурычыбыз.

Үзебезне «кинематографист» дип йөрибез икән, аны төп эшебез дип карап, нәтиҗәгә омтылырга кирәк. Нәтиҗәгә ирешә алмауның сәбәпләреннән иң кәттәсе финанслау мәсьәләсе булса да, төп сәбәп энергиягә әверелгән идея — иман, ышаныч юклыктадыр, мөгаен.

— Ул энергиягә әверелгән идея, ягъни иман кайда саклана, кемдә?

— Аны заман тудыра. Сакланышы илдә... Табып күрсәтүчесе...

— Сценаристмы?..

— Сценаристмы, режиссёрмы — кем тапса да, ул — иҗатчы.

— Һәрхәлдә, әүвәл сценарий туа, аннары гына фильм төшерелә.

— Фильмнан соң язылган сценарийлар да була һәм алары күбрәк. Сценарий ул — я төзеләчәк корылманың сызымы, я төзелгән корылманың аңлатмасы кебек арадашчы.

— Бу язучы һөнәрен кимсетү түгелме?

— Һәр сценарист язучы булмаган кебек, һәр язучы сценарист та була алмый. Сценарист ул — үз ирке белән режиссёрга хезмәт күрсәтүче. Дәрәҗәле, сирәк очрый торган хезмәт. Аерым талант сорый торган иҗади хезмәт.

Бер сценарий буенча икенче фильм төшерелү очрагы юклык аны оригиналь итә.

— «Анна Каренина» буенча мин белгәне генә биш фильм төшерелде.

— Проза әсәрләре буенча төшерелгән фильмнар, андагы идеяләр ныклыгын раслый.

— Милли әдәбиятыбызда иман сыекмыни?

— Макталганнары буенча телевизион фильмнар төшерелде.

— Ләкин алар вакыйга ясамады кебек.

— Димәк, иманнары сыек булган.

— Иман белән иман арасы Җир белән Күк арасы гына түгел...

...Кино төшерәм дип йөрүче бер кәсепче әйтә: «Бик яхшы сценарий очраса, мин аны үз акчама сатып алыр идем», — ди. Ә бит чын сәнгатькәр сценарий юклыктан зарланмый. Мәшһүр кинорежиссёр Вуди Ален: «Әйтер фикерем әйтелеп беткәндә, режиссёрлык эшемне куеп, хикәяләр, пьесалар язам», — ди. Бу цитатадан, беренчедән, кинорежиссёрның универсаль иҗатчы булырга тиешлеге күренә, икенчедән, «читләр белән булган тарихны күрсәтеп уңышка ирешүгә караганда, уңышсыз

булса да, үзе күргән-белгәнне, үзенә якынны, үз иткәнен генә күрсәтергә» тырышучы иҗатчының флюгер булмаска тиешлеген дәлилли.

Хикмәт сценарийлар юклыгында түгел, ә фильм аша, фильм белән генә әйтү мөмкин булган идея юклыкта. «Сценарий юк» дигән сылтау ул — идея фәкыйрьлеген яшерергә тырышу. Аннары... «Сценарийлар юк» дигән ширма ул тормышта яшәгән идеяләрне күрмәскә, танымаска тырышу.

Үзебезнең чор классигы Әмирхан Еники әсәрләренең һәркайсы сценарий бит! «Әйтелмәгән васыять»еме, «Кем җырлады?!»сымы, «Шаяру»ымы, «Матурлык»мы — бернинди өстәмәсез әзер сценарийлар. Замандашыбыз Айдар Хәлим хикәяләрен алып карыйк: һәркайсы буенча татарлар гына түгел, ә бөтендөнья халкы гыйбрәт алырлык фильмнар төшерерлек универсаль чыганаклар. Мәхмүт Галәү, Нурихан Фәттах, Мөхәммәт Мәһдиев әсәрләре нәфис фильмнар өчен идеяләр кишәрлеге түгелме?! Заманында Чыңгыз Айтматовның һәр проза әсәре буенча фильм төшерелеп, бөтенсоюз экраннарында күрсәтелде. Бүген мин аларның берсенең дә сценаристларын хәтерләмим. Ә менә фикерләре онытылмый, идеясе искерми, һәрчак сафта һәм сакталар. Режиссёр эшләре бу! Әлбәттә, сценарист ярдәмендәдер.

Кулына кәгазь-каләм тотып катнашмаса да, режиссёр, үзе аша фильмның һәр эпизодын, персонажларның һәр сүзен, һәр хәрәкәтен үткәреп, аларны үзгәртеп, урыннарын алыштырып, кыскартып яки озынайтып, әсәрнең драматик нигезен үзенчә төзи, үзенчә кора. Бу эшләрнең һәрчак уңышка китермәве дә гаҗәп түгел. Чөнки барлык экспериментлар да уңай нәтиҗәләр генә бирми. Шунысы факт: теләсә нинди экспериментның да бер нәтиҗәсе була. Режиссёрның һәр эше эксперимент. Билгесезлеккә сәяхәт.

— Бездә эксперименты да, билгесезлеккә сәяхәте дә юк.

— Ә теләүчеләре бар...

— Теләк көчле булганда, максатка ирешү ысулы табыла. Димәк, теләк тонык.

— Сәнгать әсәре туу ул яңа йолдыз ачылуга тиң.

— Ярый, йолдызны ачсыннар да, ди. Аны һәркем күрә алырмы? Яктысы җиргә җитәрме?

— Сәнгать җәмгыятьтә барган, күзгә күренмәсә дә, үзен сиздереп торган, халык мәнфәгатьләренә кагылышлы иҗтимагый процессларны чагылдырырга тиеш. Турыдан-туры түгел икән, киная белән яисә башка оригиналь алым белән чор чагылырга тиеш.

Бөтен халыкны берләштергән универсаль идеал юкка чыкты. Бүген һәр төркемнең үз интересы үзе белән, ул аны теләсә кем белән уртаклашмый, фиркасен — «өерен» эзли.

— Без — идеалларыбыз белән бергә кумирларыбызны да югалткан чорда яшәүчеләр идеалын югалткан, кыйбласын алыштырган, максатлары да, мөмкинлекләре дә төрле булган төркемнәрнең һәркайсына ярарлык нинди сюжет уйлап чыгарырга, нинди каһарман тәкъдим итәргә тиеш бүген?

— Андый каһарман була микән?

— ...Бөек Ватан сугышыннан кайтканнар фронтта сугышка кадәр төшерелгән шома фильмнарны гына яратып караулары турында сөйлиләр иде. «Ялган икәнен дә беләсең, әмма үлем куркынычы янаган афәтле тормышта матур әкият карау яшәүгә өметләндерә», — диләр иде.

Ә тылда безнекеләрнең гел җиңеп алга баруына багышланган фильмнар гына күрсәтелер иде. Анысына үзебез шаһит. Ул чак болай да авыр чынбарлыкны ничек бар шулай күрсәтү теләге сәнгатькәрләребезнең уйларында да йөрмәгән, диярсең.

— Шулай кирәк булган.

— Бүген дә күпләрнең экраннарда чынбарлыкны күрәсе килмидер, бәлки?!

Артык кырыс, мәрхәмәтсез, аяусыз, шәфкатьсез ул чынбарлык.

— Хыял җитмәс кансызлыкларны күреп, «кешеләрме соң без?» дип кычкырасы килә хәтта кайчакларда.

— Экраннардагы чагылышы түгел, чынбарлык үзе кеше ышанмаслык бүген. Шуңадыр тамашачы фильмнардан бу хәлләрдән чыгу юлын эзли, аның кризистан котылган яки коткаручы шәхесләрне күрәсе килә; үзе күреп, ишетеп белмәгән каһарман кирәк, вакыйга кирәк. Бүген кеше кино карарга дип бара икән, ул могҗиза эзли. Төрле илләрдә, төрле милләтләрдә кино сәнгатенең туу һәм үсү тарихына күз салганда, кыргыз киносы тарихы гыйбрәтле. Чыңгыз Айтматовка кадәр кыргызларда кино төшерү экзотика хәлендә генә булса, «Җәмилә» повестеннан соң, әйтерсең, кыргызлар, йокыдан уянып, бүгенге эшләренә генә түгел, электән кала-кала җыелып килгән эшләренә дә дәррәү тотыналар һәм, бер-бер артлы «Беренче укытучы», «Анам кыры», «Ак пароход» кебек гүзәл фильмнар төшерәләр.

Дөнья халыклары кыргыз әдәбияты, кыргыз киносы, кыргыз халкы турында сүз алып бара башлый.

Димәк, кино төшерүгә тотынганчы әйтә торган хакыйкать табылырга тиеш. Әйтер сүз булу кирәк! Яңа сүз, Яңа герой! Безнең заман герое! Нинди ул, кем ул безнең заман герое? Аның холык-фигылендәге төп сыйфатлар нинди? Кино кадәр кино төшерелгәч, тамашачының шундый сорауларга да җавап көтәргә хакы бардыр? Үрнәк алырлык эшлеклеме ул? Акыллымы? Юмартмы? Гайрәтлеме? Кыюмы? Фильм каһарманы булыр өчен нәкъ менә санап узган сыйфатлар гына булырга тиеш димәгән, әлбәттә.

СССРда 1988 елдагы иң уңышлы фильмның каһарманы бер кәнтәй кыз иде. Ул фильмны 56 миллион тамашачы карый һәм «Иң яраткан кино героегыз кем?» дигән сорауга 56 миллион тамашачы «кечкенә Вера» дип җавап бирә. М.Ю.Лермонтовның «Безнең заман герое» кем? Үз-үзенә гашыйк, булдыксыз Печорин. Пушкинның Онегинын алып карагыз, Гогольнең Чичиковын яки Хлестаковын…

Персонажлар кылган эшләрнең заман логикасына сыюы, шул чор логикасыннан чыгуы кирәк.

1988 ел «героинясына» кечкенә Вераны сайлаганга карап, ул чорда бөтен кешенең уенда уйнаш булган икән дигән фикер тумый. Киресенчә, тамашачы Вераны гаепләмәве белән аны тудырган, аны тәрбияләгән мохитне, җәмгыятьне гаепли.

Без — булганыбыз белән барыбыз да «эстрадалы» мохиттә яшибез. Тәмәке төтененә ияләшкәндәй, без аңа ияләшкән, күнеккән, агуланган. Бүгенге эстрада — яшәү рәвеше, ул — тормышның бер төре, бер өлеше. Күңелгә ял, юаныч бирә торган тамаша жанрыннан тормыш фәлсәфәсен чагылдыручы күренешкә әверелде эстрада. Күрсәтеп сөю, күрсәтеп елау, уйнау, күрсәтеп юмарт, мәрхәмәтле булу, мактау һәм мактану — болар бүген иң киң таралган һәм гадәти күренешләр.

Бу — эстрадача фикерләү рәвешенең, тормыш-яшәешнең һәр өлкәсенә үтеп кереп, идарә итүче көчкә әверелүе. Бүген җәмгыять эшчәнлегенең кай өлкәсенә тукталып карасак та, булсын өченнән бигрәк, күрсеннәр, белсеннәр өчен генә эшләү киң мәйданнар яулап, тирәнрәк үтә бара. Эше һәм нәтиҗәсе түгел — шул турыда сөйләнүе хаҗәт. Эстрада!

Юбилейлар үткәрүне генә алып карыйк. Кемнәр генә үткәрми аны. Күп итеп халык чакырып, мактаучылар яллап, бүләкләр җыеп! Имеш, ир белән хатынның аерылышмый 50 ел яшәүләре илкүләм билгеләп үтелергә тиешле вакыйга! Ә инде кемнеңдер бер үк эштә бернинди үзгәрешсез 50 ел эшләве дөньякүләм әһәмияткә ия икән! Гомере буе бер көй җырлап шөһрәт яулаган артист елга икешәр тапкыр юбилей кичәсе үткәрү җаен таба. Берсе үзен «Сәхнәдә ярты гасыр», дип атаса, икенчесе «50 ел сезнең белән», ди. Теләге булгач,

сылтавы табыла. Биш ел саен юбилей үткәрү сәнгатькәрләрнең төп эшенә әверелде. Сәнгатьтән ерак хисапчыларга кадәр «бенефис» кичәләре уздыра. «Башкача ничек үзеңне күрсәтергә?» — дип аклана алар. Мантыйклары: җәмәгать алдында ешрак күренү, үзеңне таныту, тавышыңны ишеттерү. «Не быть, а казаться!» Эстрада чире!

Игелек кылу өчен дип оештырган төрле фондларның эшчәнлегенә карагыз! Тоташ эстрада! Кайсысыннан кем нинди игелек күрә икән? Наркоманиягә каршы көрәшәбез, дип уздырылган төрле хәйрия җыеннарыннан соң наркоманнар саны кимедеме? СПИДка каршы көрәшче-каһарман исемен күтәреп, җәмгыять акчасын исраф итүчеләр саны да чирле авыручылар саны белән бермә-бер арта тора.

— Булмаганны сөйләү, булмастайны сөйләү, сүз булсын өчен генә сөйләү, күренү өчен генә сөйләү, «мин әйттем, миннән калмады» өчен генә сөйләү... илкүләм олы корылтайларда да гадәти күренешкә әверелгәч, сөйлиләр дә сөйлиләр инде. Юкса, ирекле илдә иркен яшәүне ничек күрсәтмәк кирәк? Ни белән? Бүген кеше үзе күргәнне түгел — кеше сөйләгәнне сөйли, ишеткәнен сөйли. Бүген ул кайда нинди сүз кирәк, нинди сүз тиешле, шуны әйтергә өйрәнде. Өйрәнеп кенә калмады, моның яшәү нормасы икәнен аңлап, тормышында куллана башлады. Берәүләре үзләре дә ышанмаганга башкаларны өндәсә, икенчеләре шул мәдхиядә әйтелгәннәрне үзгәртү мөмкинлеге булмаган чынбарлык дип кабул итә.

Бу икейөзлелек фәлсәфәсе буларак, бик куркыныч. Ә инде гадәткә керә баруы белән — афәт. Моңа тормыштан бик күп мисаллар китерергә булыр иде, сүзебез фильм турында, кинәсез кино турында. Сәнгать турында, әдәбият турында, язылу көткән замана сценарийлары, фильмнар турында.

Сценарий яки фильм белешмә китабы түгел — мәсьәләләр җыентыгы ул. Мәсьәләләрнең җавабы да китап ахырында түгел, һәркемнең үзендә, үзенчә. Тамашачыга шуларны чишү, аңларга тырышу гына кала.

Һәр заман үзе куйган сорауларга үзенчә җавабын да, аларның сәнгатьчә чагылышын да эзли. Хәзер, мәсәлән, әгәр сәнгать дип атарга яраса, «клип» дигән нәмәрсә басып барган чор. Бернинди мантыйкка буйсынмыйча, сәнгатьтә кабул ителгән кануннарны бозып, кешене аңгыралатуның чигенә җиткерә торган кыска гына җырлыбиюле логикасыз тамашалар алар. Тора-бара ул тамашаларның озынаю ихтималы юкмыни?

— Кеше социаль яктан гына түгел, генетик, биологик яктан да нык үзгәрде. Моны кешенең үзенә бүген ничек күрсәтергә, нинди алымнар кулланып аңлатырга? Рецепт бер генә: кино! Бары тик кино гына кешегә кешенең эчке дөньясын бөтен барлыгы белән күрсәтә ала.

— Клип замана киносы түгелме? Корабтагы тишекне ямаучы?!

— Илаһи биеклектән янгын сүндерүчегә яисә тишек ямаучыга төшердек, ахрысы, сәнгатьне? Ямаучыга түгел — чаң сугучыга!

— Чаң сугуның да төрлесе була. Сәнгать суккан чаң колакка ишетелми, ә күңелләргә үтеп керә, күңелләрне уята. ...Клип шул бурычны үтиме?

— Яраталар ич! Бу — иң мөһиме.

— Ай-һай... Яратумы икән бу?..

— Кеше «бурыч» дигәннән курыкса, хакыйкатьнең күзенә караудан качарга тырыша. Караса, чынбарлык белән сүз-хыял арасындагы аерманы күрер һәм бик читен хәлдә калыр иде. Башкача әйткәндә, кеше үзенең кем булуын белүдән кача. Клип — сәнгатькәрләрнең төп бурычы буларак, кешегә кеше булуын ачып бирү ул.

Дәвамы киләсе саннарда

ӘДӘБИЯТ

Төшмә, каләм, кулларымнан,
Төшмә соңгы көнгәчә.
Син әйтәсен беркем әйтмәс,
Әйтер сүзең әйт, яшә.

Фәнис Яруллин

ГАЯЗ ИСХАКЫЙНЫҢ ТУУЫНА 135 ЕЛ

ТЕЛЕБЕЗ САФЛЫГЫ САГЫНДА

Февраль аенда әдәбиятчы, публицист, җәмәгать эшлеклесе, сәясәтче, нахакка рәнҗетелеп, чит җирләрдә мөһаҗирлектә яшәп, татар халкының азатлыгы, башка милләтләр белән тигез хокуклы булып яшәргә тиешлеген алга сөреп, аның бөеклегенә дан җырлаган, үзе иҗат иткән һәм яшәгән чордагы вакыйгаларның татар милләте өчен никадәр аянычлы икәнлеге хакында бөтен дөньяга яңгыраткан, халкыбызны көрәшкә, азатлык юнәлешендә эш итәргә чакырган Гаяз Исхакыйның туган көне. Аның тууына быел 135 ел була. 21 февраль көнне исә дөнья халыклары Халыкара туган тел көнен билгеләп үтә. Шул уңайдан без журнал битләрендә Гаяз Исхакыйның «Татарстанда «фәнни истыйляхлар» ясау. Мәскәүнең яңа һөҗүме» дип аталган мәкаләсен тәкъдим итәбез. Мәкалә «Яңа милли юл» журналының 1931 елгы 9 нчы (сентябрь) санында гарәп графикасында «Гаяз Исхакый» имзасы белән басылган.

Язма бүген дә актуаль булган темага, ягъни татар телендәге фәнни терминология мәсьәләсенә багышланган. Автор узган гасырның 20-30 нчы елларында татарча фәнни терминологиянең нинди принцип белән төзелүе, аның нинди юлдан баруы хакында фикер йөртә һәм үзенең кискен нәтиҗәләрен дә ясый.

1921 елның 25 июнендә Татарстан АССРның Үзәк Башкарма комитеты һәм Халык Комиссарлары советы тарафыннан Татарстан Республикасында татар телен реализацияләү турында декрет кабул ителә, аны гамәлгә

ашыру буенча махсус комиссия оештырыла. Шул сәбәпле төрле фәннәр буенча фәнни терминология булдыру мәсьәләсе дә көн тәртибенә килеп баса. Татарстанда фәнни-тикшеренү институтлары, фәнни оешмалар төзелә һәм алар актив рәвештә эшли башлый. Әмма аларның гомерләре кыска була. Дәһшәтле, хәвеф-хәтәрле утызынчы еллар якынлаша, илдә шәхес культы чоры башлана. Бу афәттән бигрәк тә фәнни интеллигенция вәкилләре зур зыян күрә. Аларны, «солтангалиевчелектә, төрекчелектә, милләтчелектә, буржуа идеологиясенә, буржуа милләтчелеге идеясенә таянып иҗат итүдә» гаепләп, төрмәләрдә черетәләр, сөргеннәрдә юк итәләр. Фәнгә, бигрәк тә рус булмаган милләтләрнең фәнни үсешенә зур зыян китерелә. Мондый аяныч хәл берничә дистә ел дәвам итә һәм, әйтергә кирәк, фән дөньясында үзенең «тирән эзен» калдыра.

ТАТАРСТАНДА «ФӘННИ ИСТЫЙЛЯХЛАР» ЯСАУ. МӘСКӘҮНЕҢ ЯҢА ҺӨҖҮМЕ

ГАЯЗ ИСХАКЫЙ

СОҢГЫ АЙЛАРДА КАЗАНДА МӘКТӘПЛӘРНЕ ТАТАРЛАШТЫРУ ҺӘЙЬӘТЕ УРТА ҺӘМ ЮГАРЫ МӘКТӘПЛӘРДӘ УКЫЛА ТОРГАН ФӘННӘРГӘ ИСТЫЙЛЯХЛАР [АТАМАЛАР, ТЕРМИННАР] ХӘЗЕРЛӘҮ БЕРЛӘ ШӨГЫЛЬЛӘНӘ ИДЕ. БУ МӘСЬӘЛӘ БИК ЧИТЕН ВӘ ЗУР БУЛГАНГА, БУ ЭШКӘ ТАТАРНЫҢ КАЙБЕР УКЫМЫШЛЫЛАРЫ ДА ТАРТЫЛГАН ИДЕ.

Гыйлем юлында хезмәт итә торган төрле укымышлылар үзләренең кисеп алган фәннәренә истыйляхлар эзләү вә гыйльми тәгъбирләр билгеләү өстендә эшлиләр һәм шул юлдагы нәтиҗәләрне комиссиягә белдерә киләләр иде. Болар бу авыр эштә үзләреннән элегрәк шул юлдан үткән башка халыкларны [фин, чин, һ.б.] үрнәк итеп алырга мәҗбүр иделәр. Алар да, шул халыклар юлыннан барып, бу истыйляхларны татарның үз теленнән, аның иске дәверләреннән сакланган язмаларыннан, шулай ук башка кардәш төрек ләһҗәләреннән [телләреннән] — анатули, әзәри, үзбәк, казах, кыргыздан эзләргә тиеш иделәр. Тугры юл, эшнең гыйльми методы шуны теләгәнгә, истыйлях һәйьәтендә эшләүчеләрнең күпчелеге шул табигый юлдан киткәннәр; кайбер фәнни истыйляхларны анатули төрекчәсеннән табып алганнар вә башкалары өчен башка төрек ләһҗәләрдән киң рәвештә файдаланганнар; шулай итеп, телнең агышына-барышына истыйляхлар хәзерләнгән һәм татар теленең гыйльми бер тел булып китүенә кирәк булган нигез салынган иде.

Укымышлыларыбызның бу авыр эшләре нинди генә яктан караганда да рәхмәт әйтерлек бер эш булганга, Татарстанның мәктәпләрен татарлаштырабыз, дип барабан кагучы коммунистлар татар эшчесенә җиңеллек ясаган бу әфәнделәргә иң башлап рәхмәт әйтергә кирәк иде. Гакыл, мантыйк шуны тели иде. Ләкин Совет Русиясе гакыл берлә йөри торган бер ил булмаган кебек, андагы файда һәм зарар да фән вә мантыйк берлә үлчәнми. Анда үлчәү матди нәрсәләр өчен дә, мәгънәви байлыклар өчен дә бер генә — ленинизм гына.

Менә шул ленинизм үлчәвеннән караганда, татарның бу укымышлылары үзләренең әлеге хезмәтләре илә татар эшчесе берлә урыс эшчесен бер-

береннән ераклаштырырга юл ачканнар, имеш. Алар, муллалар, кулаклар тәэсиренә бирелеп, «төрекчелек» юлына кергәннәр, имеш. Алар ленинизм юлыннан тайпылганнар, имеш. Алар «зыянчылар», имеш... Фәлән, имеш, төгән, имеш.

Татарстанның бөтен гәзитләре соңгы атналарда менә бу яңа «зыянчылар»ны тиргәү берлә шөгыльләнәләр; аларның буржуа йөзләрен ачу тәҗрибәләрен ясыйлар. Аларның нәсел-нәсәпләрен тикшереп, кайсының әбисе мөәзин кызы, кайсының кодагые сәүдәгәр хатыны икәнен дәлилләндереп-балландырып язалар. Бу эшкә шул мәсьәлә берлә шөгыльләнергә тиеш булган Татарстанның Гыйльми үзәге дә катыша. Ул, укымышлыларның эшләгән эшләренә үзенең карашын күрсәтеп, бу юлда моннан соң булачак эзләнүләрдә асыл максат итеп ике нәрсәне билгели:

Берсе — истыйлях эзләүдә нигез итеп, урыс эшчесе берлә татар эшчесен берләштерүне күздә тота;

Икенчесе — татар милләтчеләреннән мирас булып калган «төрекчелек»тән ерак тора.

Кыска гына итеп әйткәндә, татар теленә фән истыйляхлары төрекчәдән алынмыйча, урысчадан алынсын! Гыйльми үзәк мондый әмер бирү берлә генә калмый, ул бик күп татар укымышлыларын «төрекчелек»тә гаепләп, аларны эштән ераклаштыра һәм алар урынына Мәскәүнең һәрбер әмеренә «ләббәйкә вә сәгъде бәк» дип тора торган кешеләрне билгели. Ул, шулай итеп, татар теле өчен фәнни истыйляхлар ясау, гыйльми тәгъбирләр билгеләүне гыйльми юлдан чыгарып, сәясәт юлына бора вә там [тулысынча] урыс милләтчелеге сукмагына кертә.

Әгәр Татарстан мәктәпләрен татарлаштыру шул юлдан китәчәк булса, әгәр татар теленә фәнни истыйляхлар ясау шул эздән барачак булса, татар мәктәпләре татар халкын урыслаштыру өчен бер корал хәленә китерелгән булачак. Татарстанда идарә эшләрен татарлаштыру һәм гыйлемне, фәнне татарлаштыру дигән сүзләр төп урыслаштыруны яшерер өчен матур сүзләрдән ясалган бер пәрдә генә булып калачак.

Без Мәскәү коммунистларының татарларны коммунист итәргә, аларны милләтчелек агымыннан читкә чыгарырга тырышуларын, аларны милләттәшләре булган үзбәк, казах, кыргыз, хосусан анатули төрекләреннән ераклаштырырга теләүләрен аңлыйбыз. Милләт агымы ул таралган төрек кабиләләренең берлек уен, төреклек тойгысын, Русия төрек кабиләләренең милли зурлык уен уята. Ул аларда тарихи дошман булган урысларга ышанмау хисен тирәнәйтә. Ул аларда, үз көченә таянып, башка милләтләр кебек үз башына бер мәмләкәт төзү фикерен куәтләндерә. Бигрәк тә аларның анатули төрекләре берлә бер булганын хис итү бу авыр көннәрдә аларга бер күңел җуанычы булып китә. Болар бары да тугры. Большевикларның бу 25-30 миллионлы төрекне бер-берсенә башка күрсәтеп, аерырга, бүләргә теләве дә аларның карашларыннан тугры. Ләкин үзен интернационалчы дип бакыра торган Мәскәү коммунистының татарны урыслаштырырга тырышуы, аның мәктәпләрен, фәнен, әдәбиятын кара урыслыкка өстери торган бер корал ясарга теләве генә коммунизм мәсләге берлә һичбер оеша-сыеша торган нәрсә түгел. Димәк, үзләрен милләтчеләрдән өстен торучы дип дәгъва итә торган Мәскәү коммунистлары, безнең төрек-татар эшенә килгәндә, чеп-чи урыс булып калалар һәм, күзләрен дә йоммыйча, борынгы Победоносцев-Ильминскийлар салган сукмактан йөри бирәләр. Аерма шунда гына: тегеләре өч төрле байрак астында тәре күтәреп киләләр иде, болары кызыл чүпрәк астында Ленин-Маркс сурәтләрен тагып киләләр. Гыйльми

яктан караганда, болар тагын бер зур җинаятьне эшләргә хәзерләнәләр.

Татар теле — төрек теленең бер ләһҗәсе генә. Бу ләһҗә, җәгърафи, тарихи сәбәпләр аркасында анатули һәм әзәри ләһҗәләреннән бераз аермалы булса да, үзенең якын күршеләр булган үзбәк, нугай, казах, кыргыз ләһҗәләре берлә аермасы юк дәрәҗәдә. Җәгърафи шартлардан килгән кайбер нәрсәләрнең исемнәре, кайбер сүзләрнең әйтелүе бераз аермалы кебек күренсә дә, телнең төбе, нигезе һәр җирдә бер. Болар арасындагы кечкенә аерманың һичбер җирдә алманнарның Пруссия берлә Бавария ләһҗәләре арасындагы аермалары дәрәҗәсенә килеп җиткәне юк.

Татар ләһҗәсе үзенең үсүендә, баюында һичбер вакыт төп тамыры булган иске төрекчәдән ераклашмады. Ул, чит телләрдән сүзләр алганда да, үзенең «үзлеген», төреклеген югалтмады. Гарәп, фарсы һәм урыстан алынган сүзләрен дә ул үзенең тешләре арасында чәйнәп, кабыргаларын кырып, сындырып, аларны төрек өлгесенә куйды. Тел галимнәренең фикеренә күрә, бу ләһҗә әле бер дә арымаган, картаймаган, үзенең үсү дәверен үткәрмәгән. Әле аның эчендә яңадан сүз төрләре ясау өчен булган имкян [мөмкинлекләр] тулы килеш файдаланып бетмәгән. Шуңа күрә аның киләчәге бик зур өметләр тудыра. Һәм табигый юлыннан барганда, аның фән истыйляхларын ясап, гыйльми тел ярачагы катгый.

Ләкин Мәскәү коммунистларының әмерләре берлә бу телгә һичбер мөнәсәбәте булмаган урыс истыйляхлары тутырылачак булса, ул үзенең үзлеген югалтачак, аның ашказаны бу кадәр күп бирелгән чит ашны сеңдереп бетерә алмаячак. Аның тәне, җаны бу дуңгыз итен кабул итә алмаячак. Ул я бик каты итеп косачак, я авырып, эңгерсеңгер генә йөри торган бер чирле җан булып калачак. Бу рәвешчә ясалган гыйльми тел дә яһүди теле кебек бер «жаргон» төсенә керәчәк. Ул жаргонны халык аңламаячак. Иске дәвердә госманлы төрекләрендә булган кебек, икетеллелек туачак һәм халык берлә аның укыганнары арасында үтә алмаслык бер чокыр казылачак.

Мәскәү коммунистлар партиясенең эчендә мондый шайтанлыкларны белүчеләр бар икәнен без аларның «милли сәясәтләре»нең барышыннан күреп торабыз. Шулай ук татар мәктәпләрен татарлаштыру астында татар телен бозу, урыслаштыру сәясәте алып бару аңлы рәвештә эшләнә дип ышанабыз. Бу эш Татарстанда уңышлы чыкса, аның артыннан шул ук метод Казахстанда, Үзбәкстанда, Төркестан, Кырым һәм Кавказда да кулланылачак. Шул юл берлә аларның да ләһҗәләренең ана тамыры киселергә тырышылачак.

Ләкин төрек халкы һәм аның кабиләләре мондый авыр дәверне беренче мәртәбә генә кичерми. Аның тарихында «инде бетте» дигән өметсезлек туганның икенче көнендә үк зур-зур дәүләтләр корып, шәүкәтле хөкүмәтләр ясаганын беләбез вә аның һичбер төрле авырлык каршында да үзенең «үзлеген» югалтмаганын күрәбез. Шуңар күрә без бу әүҗүҗ-мәүҗүҗ тоткарлыгыннан малыбыз-милкебезне бетереп чыксак та, үзлегебезне һәм шул җөмләдән телебезне саклап чыгуыбызга ышанабыз. Большевикларның бу соңгы һөҗүмнәреннән дә курыкмыйбыз; аны урысларның кызылыкарасының безгә милли дошман булганын күрсәтә торган яңа бер дәлил итеп кенә карыйбыз һәм алган юлыбызда булабыз.

Кереш мәкаләне һәм текстны басмага филология фәннәре кандидаты ***Гөлназ Хөснетдинова әзерләде.***

ФӘНИС ЯРУЛЛИННЫҢ ТУУЫНА 75 ЕЛ

БАЛАЛАР КҮҢЕЛЕНӘ АЧКЫЧ ТАПКАН ӘДИП

СӘҮИЯ ХӘКИМОВА,
филология фәннәре кандидаты

БЕЗНЕҢ ӘДӘБИЯТ БЕЛЕМЕНДӘ БАЛАЛАР ӘДӘБИЯТЫ АЕРЫМ ӨЙРӘНЕЛӘ. БӘЛКИ, БУ ДӨРЕСТЕР ДӘ. КҮП КЕНӘ ӘДИПЛӘРНЕҢ ИҖАТЫНДА БАЛАЛАР ӘДӘБИЯТЫ ӨЛКӘННӘР ӨЧЕН ЯЗЫЛГАН ӘСӘРЛӘР БЕЛӘН ТЫГЫЗ ҮРЕЛЕП БАРА ҺӘМ АЛАРНЫ АЕРЫП КАРАУ ДА КЫЕН.

Фәнис Яруллинның күп кенә әсәрләре әнә шундый: аларны өлкәне дә, кечесе дә үзе өчен язылган дип укый. Мисалга «Җилкәннәр җилдә сынала», «Яралы язмышлар» повестьларын, бихисап шигырь һәм хикәяләрен атарга мөмкин. Ләкин әле бу Ф.Яруллин балалар өчен махсус атап әсәрләр язмаган дигән сүз түгел. Аның шигырьләр дәфтәрендә кечкенәләр һәм өлкәннәр өчен язылган шигырьләр гел аралашып бара. Күп кенә шагыйрьләрнең иҗат башы балаларга багышланып, соңыннан зурлар өчен язуга күчкәнен беләбез. Ф.Яруллинның әле сабыйларча, әле өлкәннәрчә фикер йөртүе нәрсәдән килә соң? Бәлки дөньяга карашы утырып җитмәүдәндер? Юк, һич юк! Киресенчә, ул балаларның шаяру катыш җитди фикерле алуына, аларның үзләренә хас фәлсәфәсе булуына, кыскасы, дөньяга уй аша, акыл аша карый алуына ышана. Шул ук вакытта өлкәннәр күңелендә балачак яшеренеп ятуын һәм вакыт-вакыт балачакның өскә калкып чыгуын яхшы аңлый Ф.Яруллин.

Менә шуны аңлау (моны хәтта аңлау дип кенә әйтү дә дөрес түгелдер, бу сыйфат әдипнең табигатендә ята) аның иҗатында да чагылыш таба. Авторның беренче мөстәкыйль китабы — «Мин тормышка гашыйк»ка тупланган шигырьләрнең күпчелеге зурларга багышланган, ләкин монда да «Өйдә калам», «Аңламыйм мин абыйны», «Каян белгән» кебек шигырьләре балаларга аталган. Шагыйрьнең 1968 елда дөнья күргән «Минем елмаю» китабы тулаем балалар өчен язылган шигырьләрдән тора.

Ф.Яруллинның бу өлкәдәге үзенчәлеге шунда: аның нәни геройлары уйлый, зурлар кебек сагына, матурлыкка соклана һәм, әлбәттә инде, шаярта да белә. «Әллә кайчак» дигән шигырьдә нәни кызчыкның әнисе бер атнага кунакка китә. Башка вакытта атнаның узганын сизми дә кала торган кыз әнисе өйдә юкта көнне үткәрә алмый азаплана.

Әллә кайбер атналарда
Көннәр күбрәк буламы?

Автор «сагыну» сүзен кертми генә, кызның көннәрне санавы, әнисез үткән атнаның бик озын булуы кебек детальләр аша үз героеның сагыну хисләрен ача. «Бушлык» шигырендә дә шуңа охшаш мотив. «Әнисез өй буш» дигән зур фәлсәфәне автор бала теле белән һәм ышандырырлык итеп ике строфада әйтеп биргән.

Ф.Яруллинның шигырьләре баланы уйландыра, тирә-юньне күзәтергә өйрәтә. Ел фасылларына карата язылган шигырьләрдә һәр фасылның үзенчәлеге белән бергә аерым бер матур сыйфаты да ачыла. «Суык төсе» дигән шигырь аеруча үзенчәлекле. Монда катлауландырылган метафора-синестезия алымы кулланыла.

Кышның төсе ак була...
Суык кызыл төстә икән,
Ансын яңа төшендем.
Салкынга чыккач, битләре
Кызара бар кешенең.

Ассоциатив фикерләүгә нигезләнгән күзаллауны гади формага салып, бала күңеленә бер укуда ук кереп калырлык итеп сурәтләү өчен осталык һәм телнең барлык нечкәлекләрен белү кирәк. Авторның «Яз гөлләре» дигән шигырь китабы, «Серле дөнья» исемле проза җыентыгында тупланган җитди фикергә корылган повесть һәм хикәяләре нәни укучыны кызык булуы белән җәлеп итә. Аның проза белән язылган әкиятләре дә шигырь кебек укыла. Шуңа күрә бала күңеленә тиз сеңеп кала.

Ф.Яруллин балалар психологиясен, алар күңелендә яшеренеп яткан шаянлыкны яхшы белә.

Әби килде авылдан,
Безне шундый сагынган.
Без дә аны сагындык —
Күчтәнәчкә сарылдык.
(«Әби килде авылдан»)

Биредә шуклык аша балаларның холкы ачыла.

Көлкеле шигырьләрендә дә ул балаларның физик кимчелегеннән көлми, ә үз геройларының нинди дер ситуацияләрдән чыгу юлларын эзләгәндә олыларга гына хас фикерле белүләрен сурәтли. Балалар гына куллана торган сүзләр таба.

Бала өчен ана — иң кадерле газиз зат. Шушы олы хисне, ата-анага булган мәхәббәтне бала күңеленә гомергә сеңдереп калдырырга теләгән әдип шигъриятендә тәрбияче роленнән дә оста файдалана («Ана турында баллада», «Минем әни», «Әни»).

Ф.Яруллин иҗатында сорау формасында язылган шигырьләр дә бар. Мисалга «Кайсы көчлерәк» дигән шигырьне китерик:

Җил мактанды: мин көчле,
Мин аударам агачны?
Ә гөл әйтте: мин көчле,
Мин тишеп чыгам ташны?

Менә монда бала уйлана инде: җимереп ташлаучы көчлеме, әллә дөньяга матурлык тудыручымы? Сорау гади кебек, ләкин шигырьнең нигезендә җавап эзләүдән бигрәк эстетик мәгънә ята. Монда матурлык категориясе батырлык төшенчәсе белән синтезлаша. Шуның нәтиҗәсендә шигырьнең тәэсир көче арта.

Гадәттә, балалар шаян телдә, кызыклы сюжетка корылган әсәрләрне ныграк яраталар һәм аларны күңелләренә тизрәк сеңдерәләр. Ф.Яруллинның да шаян шигырьләре бар, ләкин алар тапталып беткән арзанлы мәзәккә корылмаган. Шаянлык, баланы көлдерү аның өчен үзмаксат түгел: әдип көлү аша берәр кимчелекне ача (ләкин физик кимчелекне түгел), начар гадәтнең аяныч хәлдә калдырырга мөмкин икәнен искәртә. Нәни герой һәр очракта диярлек ачышны үзе ясый. Авторның тел очында шаян сүз булса, әсәрнең нигезендә яшәү фәлсәфәсе ята.

Сюжетны кызыклы итеп кору да әһәмиятле. Әсәр мавыктыргыч итеп язылa икән, андыйларны балалар бик рәхәтләнеп укый. Әйтик, «Өч кыз һәм унөч алма» поэмасы. Бу әсәрдән бала бик күп гыйбрәтләр ала. Үзең утыртып үстергән алмагачның алма бирә башлавын көтүләр, беренче алмаларны кемнәргә бирү хакында баш ватулар,

Кызылъяр авылында укучылар белән очрашу 1970 ел

кыскасы, монда әхлак кагыйдәләре матур образларга төрелеп баланы эш сөяргә, матурлыкка омтылырга, юмарт һәм кешелекле булырга чакыра. «Канатлы егет», «Хыялый чебеш», «Ай турында әкият», «Песи һәм тычканнар», «Юылмас хурлык» дигән әкият-поэмаларга да бик күп тәрбияви проблемалар салынган.

Ф.Яруллин үзе сайлаган кыйблага тугры калып, балаларга багышланган әсәрләрендә дә әхлак проблемаларын күтәрә. Аның «Солдат пәкесе», «Ак төнбоек», «Бүректәге бүре баласы», «Аксак Тимер», «Акбәкәл», «Кем син, абый?», «Акмаңгай» һ.б. хикәяләрендә әхлаксызлык, намуссызлык кебек категорияләр кискен тәнкыйтьләнә, үз вөҗданына тугры калган, хыянәт итмәгән яшүсмер бәхетле тормышка лаек була.

Мисалга «Ак төнбоек» хикәясен алыйк. Әсәр Гадилә исемле кыз белән Шөһрәт исемле малайның бергәләп су коенырга йөрүләре, анда кызның төнбоек чәчәкләрен, аларның да акларын җыярга яратуы белән башланып китә. Автор, бернинди хәвеф-хәтәр булачагына ишарә ясамыйча әсәрен тыныч тонда башлап җибәрә. Кыз романтик күңелле, ашкынучан җанлы зат итеп сурәтләнә. Шөһрәт исә — киресенчә, алдын-артын уйлап эш итүче, су коенганда да тирәнгә кермәскәрәк тырышучы гади малай. Ул Гадиләне дә: «Тирәнгә кермә!» — дип кисәтеп тора. Шөһрәтнең: «Тирәнгә кермә!» — дип кисәтүендә символик мәгънә ята. Бу сүзләр үсмер малайның характерын ача, киләчәктә кем булып үсәчәген күрсәтә. Ә Гадилә гүзәллек өчен тирәнгә керергә, еракка йөзәргә курыкмый. Шуның нәтиҗәсендә суга бата башлый, Шөһрәт ярдәмендә генә котылып кала.

Хикәянең башлангыч өлешендә салмак темп өстенлек итә. Вакыйгалар барышы елганың тигез агышын хәтерләтә. Ләкин кыз коткарылганнан соң, хәлләр кинәт үзгәрә. Шөһрәтнең берни уйламыйча, бары тик кызны коткару нияте белән генә, ягъни күңелендәге яхшы омтылышка буйсынып эшләнгән эшен өлкәннәрнең зур батырлык дип кабул итүләре малайны үзгәртә. Менә шунда Шөһрәтнең ныгып җитмәгән психикасы какшый. *«Дан иярле ат булмаса да, кайберәүләр аңа атланырга, шуның*

белән тормыш юлындагы киртәләрне сикереп чыгарга телиләр. Шөһрәт исә бу атка үзе атланмады, ияргә аны башкалар утыртты», — ди автор.

Әсәрнең үстерелеш өлешендә әдип вакыйгаларны әнә шулай куертып җибәрә. Бөтен кеше мактап торгач, Шөһрәт үзен чын геройга саный һәм Гадиләне үзенә гомерлек бурычлы дип исәпли.

Автор геройларына исемне дә аларның характерына карап сайлый. Һәм геройларның исемнәре вакыйганың идеясен ачарга ярдәм итә. Мондый әсәрләрне зурлар да, кечкенәләр дә мавыгып укый.

Ф.Яруллинның балалар әдәбиятына караган «Язмышлар язылганда» һәм «Яшел утрау хуҗалары» дип исемләнгән ике повесте бар. Аларның икесендә дә яшь геройларның тормышта мөстәкыйль булырга, үзләренең сорауларына үзләре җавап табарга тырышуы, ягъни яшәү серләренә үз акыллары белән төшенәсе килүләре сурәтләнә.

«Яшел утрау хуҗалары» повестенда Үзле Яр авылында яшәүче малайлар язгы ташу вакытында барлыкка килгән утрау табалар һәм аны җәй көне үзләренә ял итү урыны ясар өчен кулларыннан килгән кадәр тырышалар. Балаларга өлкәннәр дә ярдәм итә. Тормыш куйган авырлыклар алдында куркып калмау, үз хезмәтләренең нәтиҗәсен күрү аларның характерларын ныгыта, мөстәкыйльлеккә өйрәтә, күңелләрендә горурлык уята.

Бу әсәре белән әдип матурлыкны, яшәү, ял итү өчен уңайлыкларны үзең тудырганда гына боларның җанга кадерле булуын чын художникларча, балаларның психологиясен белеп, хыял-омтылышлары һәм кылган гамәлләре аша ачып бирә.

«Язмышлар язылганда» повестенең төп герое — Рәйхана. Ул безнең алда төрле яклап ачыла. Әсәрдә Рәйхана тормышының бик катлаулы чоры — формалашу һәм балалыктан үсмерлеккә күчү вакыты тасвирлана. Рәйхана кечкенәдән классташларыннан тазарак булып үсә. Шуңа күрә ул, сигезенче сыйныфны тәмамлаганнан соң, мәктәпкә барудан баш тарта. Автор үзе дә яшь кешегә һөнәр сайлауда мөстәкыйльлек бирүне яклый һәм олыларның фикерләре белән килешмәвен кечкенә герое — Рәйхананың энесе — Фәйрүз образы аша әйттерә: *«Өлкәннәр һәрвакыт үзләрен акыллыга санныйлар. Безгә акыл өйрәтәләр. Безнең нинди булып үсәргә тиешлегебезне, хәтта нинди эш сайларга тиешлегебезне дә билгеләп куялар».*

Рәйхана повестьнең ахырында үзенең күңеленә ятышлы эшне таба. Ул, умартачылар курсы бетереп, колхозда умартачы булып эшли башлый. Әлбәттә, кыз бу юлга эзләнүләр, ялгышулар аша килә. Нәкъ менә каршысына очраган авырлыкларны җиңеп чыга алуы, тормышта үз урынын дөрес табуы аны шәхес буларак үстерә.

Г.Тукай традицияләрен дәвам итеп, балалар өчен матур-матур әкиятләр язучы татар әдипләре шактый. Әдәбият галиме һәм тәнкыйтьче Рифат Сверигин хаклы рәвештә: «Абдулла Алиш, Нәкый Исәнбәт, Әхмәт Фәйзиләр дә заманында бик матур әкиятләр иҗат иткәннәр иде. Һәм менә бүген шушы юнәлешнең бер тарафдары буларак — Фәнис Яруллин!» [1] — дип яза. Ф.Яруллинның «Зәңгәр күлдә Ай коена», «Өе балчык — иясе карчык», «Биюче бака» һәм «Серле дөнья» китапларында бик күп әкиятләр тупланган. Аның әкиятләре башка авторларныкыннан кайсы ягы белән аерылып тора дисәк, иң беренче, шигъри теле, образлы сөйләме белән, дип җавап биреп булыр иде. Үзе шагыйрь булгангамы, чәчмә формадагы әкиятләрен дә ул шигъри телдә яза. Шунсын да әйтергә кирәк: бу шигъриятлелек җөмлә ахырында нindидер сүзләрнең

Фәнис Яруллин һәм Нурсөя ханым туган як сахраларында. Баулы

рифмалашып килүе генә түгел, ә эчке халәттән, җан таләбеннән, әсәрне матур укылышлы итеп бирергә теләүдән килә. Мисалга кайбер әкиятләрдән өзек китереп узсак, урынлы булыр. Әйтик, менә «Рәссам кыз» әкияте болай башланып китә. *«Борын-борын заманда, бәп-бәләкәй авылда, ун терәүле бер өйдә яшәгән, ди, үзенең нәни кызы белән бер карчык. Таң нурлары офыкларга таралуга, урманнарда, болыннарда сандугачлар уянуга, карчык өйдән чыгып китә икән. Китмәс иде, карын икмәк таләп иткән...»* [2]. Биредә шигъриятькә генә хас эчке һәм тышкы рифмалар белән бергә җөмләләрнең үз ритмнары, үз көе булуын да тоясың. Авторның бик күп әкиятләрендә баштан ахыргача үз моңы, үз дулкыны белән укучыны тотып тора торган эчке агым бара. Дөрес, А.Алиш әкиятләрендә дә мондый күренешләр очрый, ләкин алар күп түгел. Ф.Яруллинның әлеге стиль үзенчәлеге бала психологиясен яхшы белүдән килә. Әгәр әсәр баланы агымсудай кинәт бөтереп алмый икән — ул аны укымый. Эчтәлектә әллә нинди маҗаралар тулып ятса да, һәр сүз бала телендә канат ярып очып китәргә тормаса, әсәр үзенә тартмый, мавыктырмый.

Ф.Яруллин әкиятләрендәге эчке рифмалар, вакыйгаларның үсә барып, герой рухы белән укучы җанының берләшүе сихри күтәренкелек бирә. Ә инде әкият геройларының тышкы кыяфәтләрен сурәтләгәндә, образлылык өстенлек итә. *«Карурманда бер Буар елан яшәгән, ди. Юанлыгы бүрәнәдәй, озынлыгы дилбегәдәй, күзләре кабактай, авызы табактай булган, ди аның»* [3].

Алынган өзектә әкият героеның тышкы кыяфәте белән бергә характерлы сыйфатлары да бик ачык һәм истә калырлык булып күз алдына килеп баса.

Тел — язучы өчен иң зур байлык. Сынчылар үзле балчыктан гади чүлмәк тә, гүзәллекне, күркәмлекне үзенә туплаган илаһи затлар да ясый

алган кебек, язучылар да тел белән әллә нинди дөньяда булмаган Дию пәриләрен, йорт ияләрен, албастыларны һәм тагын бик күптөрле әкият геройларының кыяфәтен, холык-фигылен, уй-гамәлләрен сурәтли. Хикәяләрдән аермалы буларак, әкиятләрнең функциясе — баланы мавыктыру, хыялын үстерү, күңелен баету; гаделлеккә бару юлындагы каршылыклы киртәләрне җимерүдә акылның, зиһеннең, хәйләнең, тапкырлыкның, батырлыкның кеше тормышында никадәр зур роль уйнавын кечкенә укучы җанына сеңдерә барудан гыйбарәт. Әкияткә тирән фәлсәфә дә, сабыйларча беркатлылык та сыя.

Ф.Яруллин үз әкиятләрендә тел белән зәркәнчеләрчә эш итә. Бу сүзләрне раслау өчен, китапның теләсә кайсы битен ачып карау да җитә. Аеруча автор башлам өлешкә зур игътибар бирә.

Билгеле, татар халык әкиятләрендә дә башлам өлеше бик кызыклы һәм мавыктыргыч була. Ләкин аларның күпчелегендә күп мәртәбәләр сөйләнелеп, тәмам калыплашкан форма, ягъни «борын-борын заманда» дип башлап китү өстенлек итә. Ә Фәнис Яруллин иҗатында исә бертөрлелектән качарга тырышу бар. Аның әкиятләренең икенче үзенчәлеге шунда да инде.

Ф.Яруллинның әкиятләрендәге өченче үзенчәлек — ул тормышчанлык, ягъни хикәягә тартым булуы күзәтелә. «Бөкре урман сакчысы», «Тиен малае Тим-Тим», «Хәтерсез күке» һәм башкалар аша сүзебезне раслап булыр иде.

Ф.Яруллин әкиятләрендә төп геройлар үз максатларына ирешкәндә генә зур канәгатьләнү ала. Билгеле, максатка ирешү авыр. Моның өчен кыюлык, тәвәккәллек, киң күңеллелек, юмартлык, альтруизм сыйфатларына ия булу кирәк. Әгәр син үз-үзеңне генә яратасың, мохтаҗларга, көчсезләргә ярдәм итмисең икән, тормышның сине бик кыен хәлдә калдыруы ихтимал. Югарыда әйтелгән фикерне «Алсу чәчәк» бик матур расլый. Аның әкиятләрендә ялкаулар, алдакчылар, киребеткәннәр һичбер вакыт максатларына ирешә алмый.

Татар халык әкиятләрендә, гадәттә, батырлык, хәйләкәрлек, ситуациядән шома чыга алу макталса, Фәнис Яруллин әкиятләрендә әхлакый батырлыкка өстенлек бирелә. «Яралы торна», «Кыядагы ояда» кебек иҗат җимешләрендә бу аеруча ачык чагыла.

Кайчандыр, борын-борын заманнарда, әлбәттә, көч-гайрәт беренче планга куелган. Кешеләрнең яшәү рәвеше гади, кораллары тупас, фикерләүләре примитив булган чорда әкият-легендаларның төп герое Дию пәриләрен җиңәрлек итеп тасвирлануы бик табигый. Цивилизация өстенлек ала барган саен, әкиятләргә дә икенче төсмер иңә. Аларга акыллы, тапкыр, кирәк чакта хәйләкәр геройлар килеп керә. Әйтик, Ф.Яруллинның «Хәзинә», «Хәким карт урманы» әсәрләрендә экологиягә кагылышлы мәсьәләләр яктыртыла.

Йомгаклап шуны әйтергә мөмкин: Ф.Яруллин балалар әдәбиятында да үзенең какшамас ныклы урынын булдырды. Аның балалар өчен язылган шигырь, поэма, хикәя, повесть һәм әкиятләрен балалар гына түгел, өлкәннәр дә яратып укый. Гадәттә, баласына китап алганда, ата-ана үзенә ошаган әсәрләрне сайлый. Ф.Яруллин ата-аналар белән балалар арасын якынайтучы буларак зур бер вазифа башкара.

Әдәбият

1. Сверигин Р. Аны беләбезме? // Казан утлары. — 2003. — № 2. — Б.136.
2. Яруллин Ф. Рәссам кыз: Әкият // Яшь ленинчы. — 1975. — 1 февраль.
3. Яруллин Ф. Буар елан: Әкият // Зәңгәр күлдә Ай коена: Әкиятләр. — Казан: Татар.кит. нәшр., 1990. — Б.83.

БАЛКЫШ, ЯКИ ХӘЙРЕТДИН МӨҖӘЙНЕҢ СУГЫШ ЯЗМАЛАРЫННАН ЮЛЛАР

(Поэма-рулада)

ЗИННУР МАНСУРОВ,
шагыйрь, Татарстанның Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты

АВТОРДАН

Рулада... Җырның бик тиз башкарыла торган өлеше музыкантлар телендә шулай атала. Көй агышының тизәюе күбесенчә азактарак була. Гомер җырының руладасы кешедә кайчан башлана? Язмыш юллары ахырына табамы? Шулайдыр... Төпкә кадәр янган шәм дә якты балкыш ясап сүнә. Вакыт тарафыннан билгеләнгән соңгы гомер чиге ягасында, имеш, һәркем хыялый тизлектә балачак сукмакларыннан йөгереп кайтыр...

Сугыш фаҗигасе күпләрнең гомер агышын тизләтте һәм яшен яшәмәгән яшьләрнең дә чәчен агартты. Кырык чиген узып киткәч, гадәттә, еллар болай да ашыга башлый. Ниндидер катализатор вакыт агышын тизләтә шикелле. «Минем җилкәдәге кырык яшь...» Данлыклы полк командиры полковник Мөҗәһит Хәйретдиновка да гомеренең соңгы өч елында аеруча тыгызга килгәндер. Соңгы чиккәчә кысылган шушы вакыт аралыгында ул үзе бер гомергә торырлык еллар кичкән. Гомер буена янучы йөрәге Дахау миченә дөрләгән хәлдә кергән!..

Гомер җыры руладасы. Яшьнәп үткән еллар. Рәхимсез сынау вакыты. Цейтнот эзәрлекләве. Йөрәкнең бөтен барлыгына янып балкуы!.. Кыскасы, әлеге әсәр Ватан солдаты, шагыйрь Хәйретдин Мөҗәй турында.

Һәм башкалар хакында да.

I

«Монда, нәкъ безнең Ык елгасы буендагы кебек, кара бөрлегән уңган. Бүген көн буе куаклар арасында бөрлегән ашап йөрдек. Бармакларым да, иреннәрем дә бөрлегән төсле күмкүк булды».

«Сугыш язмалары», 27.8.41

«Монда җиләк күп икән,
Аю-бүре юк икән...»

Әгәр төштә йөрсәм ашап
бөрлегәннең карасын,
әнкәй мәрхүм сыгар иде
күзендәге бар яшен...

«И Ходаем! Хәтәр-хәвеф
килмәгәе илләргә...» —
Кулларымның каралуын
юрар әллә ниләргә!..

«Нишләтмәкче кара язмыш,
кара җиләк йоттырып?
Юкка гына алар шулай
уңмагандыр котырып...»

Үзе булса, «Кагылма!» — дип
сугар иде кулыма...
...Төштә түгел, өндә ашыйм —
аермасы шул менә.

Нигә юрап торуларың,
килгән инде киләсе...
Ачыттыра кара җиләк —
тамган мәллә ил яше?!

Соңгылары күңелемә
ятышмады бигрәк тә.
Шундый тойгы: җиләк каптым
үзем яткан зиратта?!

Әллә сугыш сыйламакчы
мине шундый сый белән?!

...Куакларга җиләк түгел,
кара күмер сибелгән...

Мондый хәлне ни дип юрыйм –
бәлки, йөрәк сизәдер?!
Җиргә кара җиләк булып
кайтырга да без әзер…

Куйчы әле — ватандарның
буламыни үз гаме;
бөрлегәнгә кунган бары
олы юлның тузаны.

Безне күмер хәлендә дә
танучылар табылыр.
Бөек җиңү табынында…
кара җиләк тә булыр.

…Соңгылары күңелемә
ятышмады бигрәк тә.
Шундый тойгы: җиләк каптым
үзем яткан зиратта…

II

«Минем блиндаж янында бертуктаусыз снарядлар ярыла. Башны күтәреп-күтәреп карыйм. Менә окопта аягы өзелгән ак әтәч тыпырчына…»

19.9.41

…Әллә ниләр хәтерләтеп,
әйләнде дә тулганды.

Бакчасарай тарихында
шундый бер хәл булган, ди…

Дошман явы якынлашкан
шушы гүзәл мәркәзгә.
Килеп җиткәч, кем әйтмешли,
очраган, ди, бер тазга…

Сукранганнар:
«Җенле урын!
Әйләндереп йөретте…
Килгәчтен дә табып булмый,
әллә үзен җир йотты?!»
Хан сарае табылмаган,
кайнап ташкан яу үче,
һәм шулвакыт ишетелгән
«сатлык» әтәч тавышы…

Манаралы түбәләрен
бакчаларга күмгән дә
утыра, ди, Бакчасарай,
оеп, тирән үзәндә…

Туган йортны искәрмәстән
була икән сатып та.
…Яраланган әтәчебез
тыпырчына окопта.

Ярый әле баш өстендә
канат җилпеп очынмый, —
дошман күзе ак әләмгә
охшатмасын өченме?!

Җәрәхәтле гаярь кошкай
кызганыч та, кызык та,
гыйбрәтле дә:
                    әтәчләнеп
булмый алгы сызыкта!

Әле сугыш башы гына –
көрәш инде кисәтте.

Теге чакта әтәчләргә
самурай да төз атты…

Бөркетләрем!
Әтәчлектән –
куркаклыкка бер адым…
…Сугыш коштан корбан чалды –
исәнлеккә юрадым.

III

«…Басудагы эскертләргә ут төртеп, төтен каплавы астында Журовкага кадәр китәргә булдык».

19.9.41

Ничек инде ышанмыйсың
сезләрдә дә җан барга.
Рәнҗемәгез, эскертләрем —
кемдер тиеш янарга!

Тәрәккыят паровозы
алга бармый һич кенә,
Лазо төсле фидакярләр
ташланмаса миченә.

«…Атсаң, яндырсаң да…»

Немчурага җавабымны
шулай әйттем шигырьдә.
Вөҗдан кушып яздырганда
алдаламыйм мин бер дә.

Кирәк икән, утка каршы
кабынырмын ут булып.
Төтен очар, көлем калыр
Җир шарына йотылып.

Эскертләрем, менә шулай
утырыгыз җай янып.
(Илеңдәге төтенгә дә
була икән таянып!)

...Төрекмәнем*. Урта басу.
Шулкадәрле үз инде...

Авылыма чигендереп,
каралтсагыз йөземне?!
Кара мунча төтененә
качырмагыз сез мине!

Мәсләгемнән тайпылмыйча,
кичтем күпме төн-көнне.
Исерталмас теге яктан
кергән ладан төтене!

Гүрдән атам-анам каргар:
«Ватанга да син үксез!»
Адашмаска!
Туган йортка
кайта алмыйм җиңүсез.

...Тотынырга сыңар салам
калдырмыйча үзенә,
төтенеңнең очкынлысын
җибәр фашист күзенә!

Мәңгелеккә томалансын —
уртак максат шушы ла.
Сезнең төтен Жанна д’Арк
һәм дә... Болгар тәрәккые
төтененә кушыла...

Әнкәй яккан коймак миче
төтенен дә табарсыз.
Ә хәзергә озатыгыз
Журовкага кадәр сез.

IV

«Таң ата. Аз гына ятып аласы килә. Ятам, ләкин күзләр йомылмый, баш һаман уйлавын дәвам итә. Кайчагында бөтен гәүдә кисәк-кисәк сикереп куйган төсле була».

20.9.41

Тәүлек буе башым уйда —
татым беткән йокларга.
Вакыт әрәм
черем итү
кебек җыен юк-барга.

Инде менә ничә атна
итекләрне салган юк.
Сәгатемдә минут угы
гына йөри әйләнеп.

Салмак аккан вакыт хәзер
шарлавыктай ишелә!
Сәер халәт: уяу килеш
әллә нинди төш килә...

Күкрәгемдә йөрәк типми,
ә сәгатьле шартлаткыч!..
Мандолинам кыска көйләр
генә уйный — шаккаткыч...

Янар көчкә ашыктыра —
башка вакыт үлчәве.
Арттан дулап килгән чалгы
кыеп ала үкчәне.

Вакыт белән санашмаган
чак та булды югыйсә.
Ә сәгатең шартлаткычта
гомереңә чик куйса?!

Үкенечле салмаклыкта
башкарылган көй башы.
Көндәлеккә әллә нокта,
әллә өтер куясы?!
Мәрьямемә «Исән!» сүзен

*Төрекмән — Хәйретдин Мөҗәйнең туган авылы.

язарга дип мең кыздым.
Хатың килсә,
нуры төсле
инде сүнгән йолдызның?!
Булсын шундый тизлегендә
гомер атлы көй-агыш!
Куса да ул, үзебезнең
тегермәнгә коя ич.

Җилкәдәге кырык яшем
җитәр әле, хуш, әйдә,
ахыр чиктә газиз халкым
гомеренә кушарга.

V

«...Күзәтү урыны өчен җил тегермәненең эчен һәм эшләнүен карадым. Мин ул тегермәннәрне бик күп очраткан булсам да, эченә кереп караганым юк иде әле. Онга буялып чыктым».

6.10.41

Яшәү утын көчәйтергә
ташы күпме ут биргән.
Нигезенә көнләп-еллап
он тузаны утырган...

Онта белән ныгытылган —
кальгаларга торырлык!
...Ничек күзләү торбасына
керә алган бер орлык?!

Карап туймыйм — шуннан гына
тора, имеш, бар эшем.
Олуг икмәк күзе аша
күзлим сугыш барышын.

Ачлык явы тылдан бәрсә?! —
җиңү авыр монысын...
Тегермәндә дары исе
баса төште он исен.

Миндәй авыл баласына
иң авыры шул хәзер.
Безнең өчен сугыш исе,
бәлки, шундый буладыр.
Бутамаска иде бергә
дары белән он исен!
Тегермәннең канатына
Дон-Кихотның сөңгесен
кадап, җиргә егылудан
файда килә кем өчен?

Икмәк атлы хакыйкатькә
кадый җыеп бар көчен...
...Дурбиндагы бөртек аша
күзлим һөҗүм барышын.

Бәлки, алар сугыш ачкан,
синең өчен җир даулап?! —
Авыр сорау төсле орлык
тора мием бораулап...

...Туган йортта мине көткән
икмәк хәзер таш инде...
Ризык — булыр, әгәр сугыш
ашамаса башымны.
Ятып калсам, шытып чыгар
кесәмдәге арышым.
...Яуга икмәк аша карыйм,
шуннан тора бар эшем...

VI

«Эчтем, бераз үзем дә кыздым...»

24.11.41

Йоттым шул, тахилгә генә
эчкән, ди, бит тавык та.
Яшәү өчен күтәрдем мин,
утырсам да табутта*.

Юк, әҗәлгә каршы дару
салып эчмим касәмә...
Сугышта син көн дә үләр
куркак булсаң —
яшәмә!

Халыкларның канын эчеп,
исергәндә паразит,
көн дә үлем исереклеге
белән йөрү — хәрам бит!

* Җор күңелле сугышчылар землянканы шулай атаган.

Эчми исерек булырлар, ди,
мәхшәр-үлем күзендә.
Ә мин аеклыктан гаҗиз —
нигә? —
Белмим үзем дә.

Шәраб сорап тилмерттеме
җанымдагы хәйямлык?!
Бераз кыздым, әмма җебеп
мәлҗерәргә чамам юк!

Юк, кыюлык өчен түгел —
кыз катына ашкынмыйм;
шулай ук җан сызлавын да
хәмер белән басмыйм мин.

Тиредән үк чыга-чыга,
бер сөйләшер өчен дә
эчмәдем мин. Болай да сүз
тоткын түгел эчемдә.
Шундый афәт вакытында
түгел күңел ачуым.
Бу башыма йөз ләззәттән
өстен бер уй баш бүген.

Риза: янып үләргә дә,
булсын хәерхаһ кына.
Эчтем гомер шәрабымны
Ватанымның
исәнлеге хакына!

VII

«Бүген мунча кердем...»

28.11.41

Юындырды каен кызы! —
әйләндем күк сабыйга.
Карт тәнемә төште бугай
себеркенең сабы да.

Без бит сөттә коенмаган —
ник яшерим мин аны?!
Юк, үзең дә керләнмичә
пакьләп булмый дөньяны.

Ләйсән, үзе пычранмыйча,
Җирне ничек агартсын?!

Дөлдел түгел, тапсыз тотып
булмый мирнең ак атын.
Кызу сугыш үзе үк, дим,
кара мунча түгелме?
Йокса йоксын тәнгә корым —
каралтмасын күңелне!

...Ә мин, бәлки, үз мәетен
үзе юган үлемдар?!

Җирне мунча кертешергә
әле гомер түлем бар!

Пычрануга түзалырмын
ант пакьлеге хакына.
Тик төшмәсен ил алдында
йөзгә нахак тап кына.

Җанга — мунча?!
Сафлануның
бардыр башка юлы да.
Халкың өчен фида булсаң,
барысы да юыла.

VIII

«Ат бер юрта, бер атлый. Кучер – 39 яшендәге бер кызылармеец, аның үзе дә, тавышы да акрын, бер дә минем гадәткә дә, минем әтәйнең гадәтенә дә охшамый. Акрын хәрәкәтенә эч кенә поша...»

7.12.41

Атның салмак атлавыннан
җаным өшеп, кан катты.
Бәгыремнән өстерәлә
салпы чана канаты.

Әгәр өйсәм алашага
иңемдәге бар йөкне!..

— Дошман угы каршысына
коштай очып барыйкмы?!

Эчпошыргыч үшән кучер
әнә шулай «ду» килә.

Ә мин ярсыйм: «Соңарырга
ярамый, — дип, — дуэльгә!»

— Бүлдерергә теләмисең
йоклап барган ат төшен...
— Ашыктырмыйк, Хәйретдиныч,
алгыр вакыт агышын.

Әллә сәгать туктап калган —
салып карыйм учка да.
Кыймылдамый утырамдыр
сыман кара мушкада...

Әллә инде тибрәткәләп
саташтырды ат мине?!
Шушы мыштыр кучерымда
күрәм Сапый абзыйны.

Ябык чана зинданында
Апуш бара Җаекка!
Үрсәләнә янәшәдән
йөгерерлек җай юкка...

Шулай урап чыгуымы
тәкъдирендә язганны?
Әллә ясый манёврлар,
алыр өчен Казанны?

Атышырга ашыгамы
Кара елга катына?
Шул ук канлы чана бугай,
башка, ахры, ат кына...

Кемгә икән, кемгә икән
артка таккан чанасы?!
Бөтен илгә яный бүген
бароннарның яңасы.

Буран булып сукты оран:
«Патроннарны не жалеть!..»
Юк, җәяүле йокы, җитте —
бишегеңдә син ял ит!

Яный барлык шагыйрьләргә
бәрелешнең яңасы.
Ватан исән калсын өчен,
кемнәргәдер — атыласы,
кемнәргәдер — асыласы,
кемнәргәдер — янасы...

...Әкренлектән йөрәк сызлый,
кучерымның — янбашы...
Төштәй кыска гомеренә
гасырларны сыйдыралган
Тукайҗанның чанасы алсачы!..

IX

«Бүген бер фотокорреспондент мине, ак халат киертеп, фотога төшерде».

15.2.42

Гасырлардан: «Төш, төш! — диеп,
киңәш бирә Кол Гали. —
Сүздән сурәт ясаучылар
сурәтсез дә калгалый...»

Канкай углы Бәхтиярдан
ишетмәдем хаклау ник?
«Дастан булып калучыга
сурәт нигә, полковник?..»

Мәгълүм инглиз китапчысы
сорап язгач фотосын,
Шиһабетдин Мәрҗанидән
галим ник бер хат алсын...

Мондый ядкарь таратуны,
бәлки, чүпкә саныйдыр:
«Хәтердәге сурәтеңнән
гайреләре фанидыр!..»

Сукыр Каюм: «Минем кебек
сурәт-сынсыз калма, дим!..
Һичьюгында, охранкадан
төшерттерә алмадым...»

Шаярткандай итте шулай
«академик» Насыйри.
Фанатиклар кычкырышты:
«Сурәт — хәрам — җан сорый!
Җан сорый!!
Җан сорый!!!»

…Фото-маһир Ксенофонтов
биләп алды бар гамем.
Бреслауда төшермәкче
булган фашист мәргәнен…

«Истәлеккә» калдырырга
ниятләгән ул аны.
Һәм төшергән… йөрәгенә
очып килгән пуляны…
Сурәтчене аткан фашист,
аткан, димәк, үзен дә.
Кара шәүләң катып калса
үлмәс халык күзендә?!
……………………………….
Аермачык күзаллана
Кол Галидәй зур затлар.
«Мәңгелекнең суларында
агып китте сурәтләр,
агып китте сурәтләр…»

…Ә фотокорр ашыктыра,
алдырмыйча сулыш та:
«Моңланмагыз — Сезне ташка
басыйк әле шук төстә…»

Юк, рәсемгә уйсыз гына
төшеп булмый сугышта.

X

«Сугыш башланганчы, хатын-кызга минем караш бик ялгыш булган. Мин хатыннарны сугышта паника күтәрергә генә ярый торган кешеләр дип саный идем».

9.11.41

«Бүген Настя белән (без торган квартирада торучы 21 яшьлек кыз, кара чәчле, мөлаем йөзле, аның белән ни сөйләшсәң дә, хәтере калмый): «Мин бу Скородноеда үлсәм, минем исемгә бер колхоз төзергә», — дип сүз бирештек».

21.11.41

«Көн матур, кояшлы. Яз. Кызлар да матуррак та, дәртлерәк тә кебек күренәләр».

21.4.42

«…Әтәч менгән читәнгә,
«Кик-ри-күк!» итәргә.
Әтәчкә хәбәр килгән
армиягә китәргә.
Әтәч әйтә: «Бармыйм», — ди,
Тавык әйтә: «Калмыйм, — ди, —
син армиягә китсәң,
бер күкәй дә салмыйм», — ди.
Әтәч армиягә китте,
чабатага утырып.
Тавык, мескен, карап калды,
күзкәйләрен тутырып…»

Көйли-көйли киткән идем
шушы никрут җыруын.
Итегемне әле һаман
сала алмый йөрүем.

«Җиңеп» кайткач басмачыны —
әллә ничә бәк явын,
мине күпме үгетләде
Хаҗуафа апаем…

«Кал», — дип, кызлар кочагына
кертмәк булды җим белән.
Имеш, гыйшык гашрәтендә
сәргаскәрләр җиңелгән!..

Йотылырсың — әгәр язса
юха кыздай зәһәр яр.
«Китәм, — дидем, — өйдә ятып,
алып булмас шәһәрләр…»

Ымсындыргыч «Калчы!..» сүзе —
агып тора баллары…
Сугышта да очраштырды
арзан ишек баулары.

Әсир фашист кесәләрен
әйләндергән чагында,
туры килде күргәләргә
«шикле резин» кабын да…

Гыйбрәтләрнең төрлеләрен
күрдем сугыш юлында:
Мәхәббәттән нәфрәткәчә
төшкән гаурәт колын да,

«Илем, анам, ярым!» — диеп
янган йөрәк көлен дә...
....

«Зәгыйфь затлар» аркасында
чыккан кайчак сугыш та...
Юк, юк, мондый нәтиҗәгә
килмәм соңгы сулышта.
...Бүген Настя әйтеп куйды
үзәгемне өзәр сүз...
Ярый, кызлар, исемемне
кушып колхоз төзерсез.

Ташбилгем дә калмас, бәлки,
ядка алып еларга.
Яратудан янды, диеп,
я-ра-ту-дан ян-ды, диеп
аңлатырсыз елларга.

XI

«...Минем үлемем — минем Ватаным, минем сыйныфым үлүе түгел ич. Шулай булгач, без: «Безгә үлем юк!» — дибез».

«Сугыш язмалары», 6.1.42

Үзен-үзе утка бирер
әкияти феникс —
янә көлдән яралучы
мәңге үлмәс фани кош...

Шушы җанкай әллә ничек
төшкә кереп йөдәтә.
Нигә язмыш катгый сүзен
читләп-читләп йөз әйтә?!

Юраунамә, чегән төсле,
матур алдап көл миннән.
Без... яңадан яралганнар
мәгъмүр Болгар күленнән!

«...Шәһре Болгар каласында
Көлбикәнең
коесы тирән, суы юк.
Шәһре Болгар каласының
исеме калган, үзе юк,
исеме калган, үзе юк...»
Хәтта нәсел агачының
көле күккә очса да,
халык рухы, феникстай,
яңарырга көч таба!

Кат-кат янган Идел-йортын
яңабаштан гөл итә.
Хәрабәдән Мәрьям ана
булып калка Көлбикә...

Утка каршы фидаича
януыңны ил көтә!
Синнән тимер бөти* генә
торып калса көллектә?!

Мәңгелекнең балдакланган
кошы булу язганмы?
Башка уйлар әзәрлекли
әле бүген абзаңны.

Фашизмның каракошы янар —
тынмас җан һаман.
Әллә ничә башлы булып
терелмәсме яңадан?

Тагын гайрәт иңдерсәләр,
авызына салып кан?!
...Җирдә күпме мәдәният,
янып, кабат калыккан.

Җирең янса, Кояш улы
янган төсле яшендә, —
көлгә җан-рух өрер өчен
ярдәм итмәс әфсен дә...

Миләремне изә вакыт —
тыгызланган бигрәк тә.
Тамырларым бикфорд кебек
янып килә йөрәккә!

Утка каршы фидаича
януыңны ил көтә.
Йөрәккәйне күңел кошы
«Үлем юк!» дип җилкетә,
«Үлем юк!» дип җилкетә!.. ■

---

*Хәрбиләрнең кемлеген ачыклаучы янмый торган тимер билге күздә тотыла.

БАТЫРША

ФӘҮЗИЯ БӘЙРӘМОВА,
язучы, Г.Исхакый исемендәге премия лауреаты,
тарих фәннәре кандидаты

Рус гаскәрләре белән тигезсез көрәштә баш күтәрүчеләр җиңелсәләр дә, алар куйган максатлар патша хакимиятен тетрәнергә мәҗбүр итә. Батырша хәзрәт язган өндәмәдән күренгәнчә (ә аны, тәрҗемә итеп, шунда ук патшага җиткерәләр), инде беткән дип уйлаган татарлар, Идел-Урал арасында берләшеп, русларны аннан куып чыгарырга җыеналар. Мөселманнар Идел-Уралда үз бәйсез дәүләтләрен торгызырга телиләр! Бу хәл патша хакимиятенең котын ала, шуңа күрә Батырша явы әле башланып та китмәс борын, аңа каршы тиңсез көрәш башлана. Батырша хәзрәт турында язганда, бу яуның җиңелү сәбәпләрен һәм, җиңелүгә карамастан, халык өчен уңай нәтиҗәләрен дә әйтеп үтәргә кирәк.

Шулай итеп, 1755 елның 3 июленә билгеләнгән күтәрелеш булмый кала, дин әһелләре һәм халык белән каткат киңәшкәннән соң, яуның вакытын көзгә чигерәләр. Әмма август башында бөрҗән башкортлары янә фетнә чыгаралар һәм бу юлы инде алар русларны гына түгел, хәллерәк татарларны да талый, үтерә башлыйлар. Русларның заводларын талап, юлларында очраган күп кешеләрне суеп, Җаек елгасы аша казах далаларына качалар… Батырша хәзрәт халык күтәрелешенә күпме генә дини һәм милли төсмер бирергә тырышса да, аларны дәүләт өчен яуга тупларга омтылса да, бөрҗән башкортлары бер көнлек талауны артыграк күрәләр. Батырша хәзрәт аларны дин һәм дәүләт өчен көрәшкә юнәлдерә алмый, чөнки тау башкортларының күбесенә дин һәм

*Дәвамы. Башы журналның 2012 елгы 10-12 нче, 2013 елгы 1 нче саннарында.

дәүләт төшенчәләре ят була. Ларның укымышлы татар-мишәрләрне рәттән үтерә башлаулары да Батырша хәзрәтне хәвефкә сала, ул кыргый халык өчен җиһад төшенчәсенең ят булуын аңлый. Батырша хәзрәтнең тормышын һәм иҗатын өйрәнүгә күп гомерен багышлаган филология фәннәре докторы Мәсгуд ага Гайнетдин исә бөрҗән башкортларының бу яуны махсус, провокация юлы белән өзүләрен искәртә.

Татарларның күпчелек өлеше Батырша хәзрәтне аңлап, аның яклы булса да, хәллерәк кешеләр, бөрҗән башкортларының ничек итеп күренекле татарларны үтереп йөрүләрен белгәч, баш күтәрүдән баш тарталар, кайберләре хәтта аңа каршы чыга. Ул арада бөрҗән башкортларының кылган явызлыклары өчен рус гаскәрләре татарларны кыра башлый, күпләп кулга алулар, җәзалаулар, сөргенгә сөрүләр башлана. Казах далаларына качкан башкортлар исә анда җирле халык белән сугыша, казахларны суярга, үтерергә тотына. Шулай итеп, Батырша хәзрәт кисәткән бу хәлләр дә була — мөселман-төрки халыклар бер-берләренә каршы корал күтәрәләр. Кыргыз-казах халкы, баш күтәрүчеләргә ярдәм итәсе урында, качак башкортлар белән сугыш сәбәпле, татарларга да булышмый. Россия империясенең иң курыккан нәрсәсе — мөселман-төркиләрнең русларга каршы берләшүе булмыйча кала…

Алга таба Батырша хәзрәтнең бөтен өмете Себер һәм Уса юлы татарларына кала. Ул әле Казан юлы татарлары да баш күтәрерләр, бу изге эшкә катнашырлар дип өмет итә, аларны оештыру өчен, халык арасыннан кайтып керми, шәкертләренә дә шуны куша. Баш күтәрү көне кичектерелеп, көзгә билгеләнә.

Мөселман-татарларга каршы гаять рәхимсез һәм мәкерле эш иткән патша түрәләре дә тик ятмый, аларга каршы Оренбург губернасында тиңе булмаган эшчәнлек җәелдереп җибәрәләр. Бер яктан, гаскәр белән һөҗүм итеп, халыкның канын эчсәләр, икенче яктан, мәкер юлы белән татарларның арасын бутыйлар, кемне куркытып, кемне сатып алып, кузгалыш юлыннан читкә алып ташлыйлар. Кулга корал алырдай татар ирләренең кайсыларын яу башланганчы ук төрмәләргә утырталар, кайсыларын Себергә сөрәләр, кайсыларын хәрби походларга дип җыеп алып чыгып китәләр.

Мөселман-татарларга каршы көрәштә Оренбург губернаторы И.И.Неплюев тиңе булмаган мәкер алымнары уйлап таба, ул хәтта Ибраһим ахун исеменнән Батырша хәзрәткә каршы ялган хат язып таратуга хәтле барып җитә. Шулай ук казах ханнарын баш күтәргән татарларга каршы котырта, аларга ярдәм итмәскә чакыра, аерым казах түрәләрен зур бүләкләр белән сатып ала. Урал буйлары Казан губернасына кергәндә, русларның бирегә хәтле куллары килеп җитә алмаса, аерым Оренбург губернасы төзелгәч, рус түрәләре җирле халыкны, аның тормыш-көнкүрешен бик җентекләп өйрәнә башлый, һәр татар авылы, милләтнең күренеп торган һәр кешесе зур күзәтү астында кала. Әмма Батырша хәзрәт яуга хәзерлеген дәвам итә.

Ул арада, август ахырында, Батырша хәзрәтнең өндәмәсе нигезендә һәм эшчәнлеге сәбәпле, Гайнә волостенда чуалышлар башлана. Күтәрелеш башында татар муллалары тора һәм алар Батырша хәзрәт белән даими элемтә тоталар. Халык кораллана, чирү-отрядлар төзелә, алар алдында Батырша хәзрәтнең өндәмәсе кычкырып укыла. Берничә авылда сатлык старшиналар үтерелә, татар кузгалышы турында ишеткән руслар Уса һәм Көнгәр өязләреннән кача башлый. Бөтен Гайнә татарларының зур кузгалышы 1755

елның 1 сентябренә билгеләнә. Әмма бу эшкә башкортның кайбер старшиналары кискен рәвештә каршы төшә. Алар Тохтамыш Ишбулатов дигән башкорт старшинасы тирәсендә берләшеп (соңыннан аны дүрт юл башкортлары үзләренең депутатлары итеп сайлыйлар), баш күтәрүче татар авылларына бәреп керәләр, халыкны куып тараталар, Батырша хәзрәтнең илчешәкертләрен, яу җитәкчеләрен тотып, хөкүмәт гаскәрләре кулына тапшыралар. Август ахырында алар Батырша хәзрәтнең туган авылы Карышбашка да бәреп керәләр, йөздән артык коралллы сатлыклар мулланың өен чорнап алалар. Әмма гаять дәрәҗәдә билгеле һәм хөрмәткә лаек дин әһеленә кул күтәрергә батырчылык итмиләр — көчле сак астында аны гаиләсе һәм балалары белән өеннән чыгарып, урманга куып кертәләр. Шәкертләре Батырша хәзрәткә иярә, баш күтәрүче татарлар аңа ярдәмгә килергә өлгермичә кала...

Татарлар ил белән яуга күтәрелмәсен өчен, җирле рус түрәләре генә түгел, патша хакимияте дә күп эш башкара. Күпсанлы регуляр армия өстенә, калмык далаларыннан, Дон, Оренбург казакларыннан чирү туплап, татарлар өстенә җибәрәләр. Ул вакытта Оренбург губернасында, Урал тауларында 50 меңлек рус гаскәре хәрәкәт иткәне билгеле. XVIII гасыр уртасында Россиядә регуляр армиянең саны 200 мең кеше икәнлеген истә тотсак, шуның чиреге Идел-Урал арасында, татарларны бастыру өчен җибәрелә. Шул ук вакытта патшабикә Елизавета Петровна, җирле халыкка яхшы булып күренер өчен, 1755 елның 1 сентябрендә манифест та чыгарып өлгерә — имеш, баш күтәрүчеләр ирекле рәвештә бирелсәләр, ул аларны кичерәчәк икән... Казах далаларына качучыларны ул 6 айда илгә кайтырга чакыра. Патша манифесты рус һәм татар телләрендә халык арасында күпләп таратыла.

Шул ук вакытта, инде «икенче кул» белән, баш күтәрүчеләрне кискен рәвештә бастырырга һәм хөкем итәргә, дигән әмерләр дә языла. Батырша хәзрәтнең үзенә һәм тарафдарларына карата чын мәгънәсендә ау башлана. Аның күп шәкертләре һәм урыннардагы яу җитәкчеләре кулга алына, хөкем ителә. Батырша хәзрәтнең башы өчен зур суммалар билгеләнә, аны эзләүгә һәм эзәрлекләүгә комсыз татар түрәләре һәм сатлык башкорт старшиналары да кушыла.

Көзге урманда патша гаскәрләре һәм сатлык старшиналар белән булган берничә бәрелештән соң, Батырша хәзрәт гаиләсен Урал аръягына, каеналарына озата. Әмма урманнан чыкканда, Батырша хәзрәтнең гаиләсен кулга төшерәләр, аларга Урал аръягына чыгып җитәргә насыйп булмый. Зөлхәбирәнең үзен һәм балаларын, аның янындагы яугир татар ирләрен дә кул-аякларына богау салып, Уфа төрмәсенә озаталар. 1755 елның 14 октябрендә Уфа төрмәсендә Батырша хәзрәтнең хатыны Зөлхәбирә абыстайдан һәм шәкертләреннән сорау алалар. Хакыйкатьне боза-боза, үзләренә җайлаштырып һәм әйтмәгәннәрне дә кыйнап «әйттереп» сорау алганнан соң, Зөлхәбирәне өч баласы белән Уфа төрмәсенең тар камерасына ябалар, аякларын богаулап, идәнгә беркетеп куялар. Аннан һаман ире Батыршаны таптыралар, аның турында сорашып газаплыйлар. Ә аның кайда икәнлеген Зөлхәбирә үзе дә белми, ул Аллаһтан ире Баһадиршаһның исән булуын сорый, аның тоткын хурлыкларыннан азат булуын тели...

1756 елның 18 гыйнварында махсус указ белән Зөлхәбирәнең хәтта кулларына да богау салалар. Кече кызы Салиханы ул богаулы кулларына алып имезә, тоткын анага сыенган Зөләйха белән Таҗетдинен тимер чыңы аралаш иркәли... 1756 елның 8 февралендә

Оренбург губерна канцеляриясе аша Уфа төрмәсенә патшабикә исеменнән тагын бер әмер килеп төшә. Анда «Вор Батырша» хатыны Зөлхәбирәне, балалары белән бергә әсир итеп, Мәскәүгә озатырга кушылган була: «Вора Батырши жену Зюлбухарнею Асанову с детьми, двумя дочерьми и одним сыном, по причине известного от мужа её вора Батырши к бунту возмущения была с ним, Батыршою, в побеге и укрывательстве в лесах, где и поймана, отправить в Московскую губернскую канцелярию без наказания».

Имеш, «җәза бирмичә генә, Мәскәүгә озатырга!» Нинди икейөзлелек, кәгазьдә тарих өчен булса да яхшы булып кылану! Кул-аяклары богауланган хатынны өч сабый баласы белән кышкы көндә атка утыртып, сак астында бер төрмәдән икенчесенә сөрү — ул җәза түгелмени?! Үзен кыйнап, җәберләп барган рус сакчыларының бер сүзен аңламаса да, Зөлхәбирә бу кышкы озын юлга аларны үтерер өчен алып чыкканнарын сизенә. 1756 елның 6 мартында ат чанасында олы уллары Таҗетдин катып үлә, ул анасының богаулы кулларында күккә карап җан бирә… Анага аны күмәргә дә рөхсәт бирмиләр, конвой атларны туктаусыз куа, бары тик юл өстендәге бер татар авылында туктап, баланы күмәргә биреп калдыралар. Шулай итеп, Батырша хәзрәтнең бердәнбер улы тоткынлык газапларыннан да, чукындыру хурлыкларыннан да котыла, балигъ булмаган килеш, мөселман булып бу дөньядан китә… Зөлхәбирәнең ике сабый кызы исә аналарының куенында катып үлүдән исән калалар, аның белән бергә Мәскәүгә хәтле килеп җитәләр. Бирелә аларны яңа газаплар һәм хурлыклар көтеп тора…

Мәскәү Батырша гаиләсен тәре һәм камчы белән каршы ала…

Зөлхәбирәне башта Яшерен канцелярия төрмәсенә бикләп, көне-төне сорау алалар, һаман ире Батырша турында сорыйлар, аның исеме белән газаплыйлар… Бу татар хатыныннан үзләренә кирәкле сүзне ишетә алмагач, ярсыган патша хөкүмәте Батырша гаиләсе өчен җәзаның иң мәкерлесен кулланырга уйлый — 1756 елның ахырында аларны көчләп чукындыралар һәм рус байларына хезмәтче итеп бирәләр. Шулай итеп, Зөлхәбирә Хәсән кызы Мария Александровнага әйләнә, Батыршаның олы кызы Зөләйха — Наталья, сабый Салиха исә Вера, дип йөртелә башлый. Бер авыз русча белмәгән, тоткынлыкта да көнгә биш вакыт намаз укыган абыстайның муенына кыйнап тәре асалар. Әле телләре дә рәтләп ачылмаган сабыйлардан көчләп христиан ясыйлар.

Ә Батырша хәзрәт суга төшкәндәй юк була…

Батырша мулланы патшага тотып бирү өчен, рус генералларын да уздырып, татар-башкорт старшиналары тырыша. Бигрәк тә Яныш старшина котыра. Ул Батырша хәзрәт кереп киткән урманны 300 кешелек гаскәре белән чорнап ала, моның өстенә Гайнә, Тубыл, Казан якларына үзенең шымчыларын җибәрә, әмма алар буш кул белән әйләнеп кайта. Нәтиҗәдә, генерал-губернатор Неплюев Батыршаны эзләргә үзенең иң көчле, иң мәкерле гаскәрләрен юлларга мәҗбүр була. Урал таулары, Оренбург далалары коралы гаскәр белән тула.

Аны патша ялчылары ай эзли, ел эзли, әмма бер җирдән дә таба алмыйлар. Батырша турында халык арасында берсеннән-берсе тетрәндергеч, берсеннән-берсе шомлы хәбәрләр йөри. Имеш, ул урманнан чыкканда бик нык яраланган да, Уралдагы кайсыдыр тау тишегендә дәваланып ята икән. Имеш, ул инде күптән руслар белән бәрелештә үтерелгән, гәүдәсен шәкертләр яшереп күмгәннәр, ди. Юк, алай да түгел икән, Батырша хәзрәт исән, ди, руска

каршы сугышырга ярдәм сорап, Төркиягә, Кырым якларына киткән икән... Кемдер аны Хажда йөри, дип сөйли, кемдер үз күзләре белән аны Тубыл-Иртыш якларында күргәнлеген әйтә, хәтта Бохарада да аңа охшаш кешене күреп кайтканнар, имеш.

Кайсы дөрес бу хәбәрләрнең, кайсы ялган — беркем белми. Әмма әле Гайнә ягында, әле Нугай юлында русларның бер-бер артлы крепость һәм заводлары яна башлагач, Батырша мулла турында сүз тагы куерып китә. Имеш, аны ак атына атланган хәлдә шул тирәдә күргәннәр икән, бу кара көздә кабынып киткән яу Батырша хәзрәт һәм аның шәкертләренең эше икән. Хәтта Оренбургның борын төбендәге Преображенски заводы да дөрләп янып киткәч, моның Батырша мулла эше икәнлегенә беркем шикләнми. Заводның гарнизоны кырып салынган, рус сакчылары барысы да үтерелгән була.

1755 елның октябрендә баш күтәрүчеләр Каноникольски заводын ут төртеп яндыралар, аны саклаган рус гаскәре юк ителә, моны да Батырша хәзрәттән һәм аңа иярүчеләрдән күрәләр. Шул ук елның ахырында Вознесенски, Петровски заводлары татар яугирләре тарафыннан чорнап алына һәм юк ителә. Ул арада Гайнә якларында, Көнгер, Уса, Красноуфимски тирәсендә зур янгыннар кабынып китә, заводлар һәм рус кальгалары юк ителә, патша түрәләре моның артында Батырша хәзрәт торганлыгына шикләнмиләр. Халык арасында берсеннән-берсе шаккатырырлык хәбәрләр тарала — имеш, татарлар зур яуга купканнар икән, Екатеринбург һәм Оренбург калаларын алып, Казан өстенә яу белән баралар икән! Бу олы яуның башында татар мулласы Батырша хәзрәт тора икән! Ул исән икән, Казанны алырга, яңадан татар дәүләтен торгызырга зур яу туплый икән!

Патшабикә халыкны яудан туктату өчен нинди генә указлар чыгарса да, Идел-Уралда кабынып киткән утны тиз генә сүндерә алмый. Татар җирендә һаман рус заводлары яна, һаман кальгалар юк ителә, һаман рус солдатлары кырыла... Бөтен татар илендә кинәт кабынып китәргә тиешле яу астан янып килә торган утны хәтерләтә башлый, мондый хәл исә патша хөкүмәте өчен тагын да куркынычрак була. Чөнки җир астындагы бу янгын бик озак дәвам итәргә һәм бөтен империяне юк итмичә туктамаска мөмкин!

Батыршаны һаман тота алмавына генерал-губенатор Иван Неплюев шартлар хәлгә килә. Ул патшабикәнең Идел-Уралда һаман-һаман йөз меңлек гаскәр тотмаячагын яхшы белә, алда Пруссия белән сугыш көтелә, димәк, рус армиясе анда кирәк булачак, Неплюевка исә берничә меңлек регуляр гаскәр белән генә канәгатьләнергә туры киләчәк. Батыршаның һаман тотылмавы патша даирәләрен дә зур борчуга сала — 1755 елның ноябрь уртасында Сенат бу хакта тагын махсус указ чыгара, анда Батыршаны тотучыларга зур күләмдә акча һәм бүләкләр вәгъдә ителә, эзләүчеләргә бөтен яктан ярдәм күрсәтергә кирәклеге әйтелә. Һәм тагын бер яктан — рус генералы Иван Неплюев, икенче яктан — мишәр старшинасы Яныш Абдуллин Батыршаны эзләргә Казан, Тубыл, Исәт тирәләренә гаскәр арты гаскәр, шымчы арты шымчы җибәрәләр. Әмма батыр татар мулласын таба да, тота да алмыйлар.

Шулай итеп, 1755 елның сентябрь, октябрь, ноябрь, декабрь айлары эзләүчеләр өчен бернинди нәтиҗәсез үтә. 1756 елның салкын кышы һәм эссе җәе дә Батырша хәзрәтнең эзләрен табарга ярдәм итми.

Бу вакытта Батырша хәзрәт кайда булган соң?

Соңыннан кулга алынгач, патшага язган аңлатмасыннан күренгәнчә, Батырша үзенең бу вакытта Казан ягында булуын, Надир старшина командасы авылларында кыш уздыруын әйтә. Әмма, безнең фикеребезчә, Батырша хәзрәт моны эз югалту өчен генә шулай язган. Ул үзенең бу вакыт эчендә патша гаскәрләре белән сугышып йөрүен яза алмый, әлбәттә, үзе булган, үзенә ярдәм иткән халыклар турында да патшага хәбәр итүне кирәк дип тапмый. Киресенчә, бу эшләрдә бөтен җаваплылыкны үз өстенә ала, ә мөселманнарның бу хәлгә төшүләрендә явыз генералларны һәм түрәләрне гаепле итеп күрсәтә.

Батырша хәзрәт 1756 елның 8 августында Карышбаштан ерак булмаган Әзәкәй татар-мишәр авылында тотыла. Мөгаен, аның үз авылына кайтып барышы булгандыр, мөгаен, ул гаиләсенең хәлен белеп, илне яңа яуга әзерләргә ниятләгәндер. Әмма аңа туган авылы Карышбашны күрү дә, гаиләсен очрату да насыйп булмый. Алда аны зур сынаулар һәм газаплар көтә... Рус төрмәсендә аягүрә басып үлү һәм татар тарихында мәңге үлемсезлек көтә...

Аяк-куллары богаулы Батырша хәзрәтне шул көнне үк, ягъни 1756 елның 8 августында Себер юлы буйлап Уфага озаталар. Әзәкәйдән Уфага ара шактый, юлда туктый-туктый, төн кунып баралар, Батыршаны көчле конвой саклый. Батыршаның тотылуы турында хәбәр Оренбургка, генерал-губернатор Иван Неплюевка 1756 елның 12 августы көнне килеп җитә, ул исә сакны тагын да көчәйтергә куша. Татар авыллары аша аяк-куллары богаулы килеш үткәндә, Батырша бәлки халыкның күтәрелеп чыгуын, үзен яклавын һәм әсирлектән коткаруын да өмет иткәндер... Әмма оешкан яугирләр юк, оештыручы гайрәтле ирләр юк, аларның кайсы төрмәдә, кайсы качкынлыкта йөри. Авыллар белән үз шәүләләреннән дә куркып торган старшиналар идарә итә. Озак еллар тоташ талаудан халык тәмам фәкыйрьләнгән, бөтен җирдә җимерелгән өйләр, янган мәчетләр, ятим балалар.

Берничә көндә Батырша хәзрәтне Уфа төрмәсенә китереп җиткерәләр. Уфа кәнсәләре исә бу хакта тизрәк Оренбургка хәбәр итә һәм Неплюев 12 август көнне Батыршаның Уфага килеп җитүен белә. Сөенечле хәбәрне ул патшабикәнең үзенә дә җиткерергә ашыга. Инде хәзер татар мулласын юлда бик нык саклап, маҗарасыз Оренбургка китереп җиткерү мәсьәләсе тора. Бу гаять мөһим операция белән генерал-губернатор Иван Неплюев үзе җитәкчелек итә. Ул шул көнне үк Уфага махсус күрсәтмәләр белән курьерын озата. Бөтен саклык чаралары күрелгәннән соң, Батырша хәзрәтне яшерен рәвештә Оренбургка озаталар. Аны 60 кешелек драгун, 40 кешелек казак отряды саклап бара, гаскәр башында рус капитаны тора. 100 кешелек каты сак астында 1756 елның 23 августында Батыршаны Оренбургка алып китереп җиткерәләр, шул кичне үк генерал-губернатор Иван Неплюев башбирмәс татар мулласыннан үзе сорау ала башлый.

Батыршаның тотылуы турында хәбәр Петербургка да тиз барып ирешә. Татарларны, Идел-Урал мөселманнарын Россия империясенә каршы яуга күтәргән дин әһеленнән Яшерен канцелярия (Тайная канцелярия) үзе сорау алырга ниятли һәм 1756 елның 26 августында Сенат бу хакта махсус карар чыгара. 9 сентябрь көнне бу карар кинәт кенә авырып киткән Неплюев кулына да барып керә, анда хөкүмәт өчен аеруча куркыныч булган «бур Батыршаны» кичекмәстән көчле сак астында Петербургка җибәрергә, диелгән, аның

исән-сау килеш хөкем каршына басарга тиешлеге кат-кат кисәтелгән була. Шулай итеп Неплюевның канлы куллары Батырша хәзрәткә барып җитә алмый, генерал урын өстендә ятып кала, Батыршаны исә, аяк-кулларын богаулап, көчле сак астында 1756 елның 16 сентябрендә ерак юлга озаталар. Батырша белән бер үк көнне Уфа төрмәсеннән Петербургка аның шәкертләре һәм тарафдарлары да озатыла.

Алда озын юл — каторжаннар юлы... Бу юл, чыннан да, бик озын була: Оренбургтан — Самарага, Самарадан — Арзамаска, Арзамастан — Муромга, Муромнан — Владимирга, Владимирдан — Мәскәү шәһәренә, ә Мәскәүдән исә — Санкт-Петербургның үзенә... Батырша мулланы һәм аның шәкертләрен 36 драгун солдаты, 1 капрал, 1 унтер-офицер, поручик Левашов һәм капитан, князь Иван Болховский озата бара. Самарада аларга тагы 20 драгун солдаты, 6 атлы казак өстәлә. Бу операцияне башкарып чыгу өчен казнадан 500 сум акча бүлеп бирелә. Көзге томанлы көндә, җәмгысе 25 олау булып, кәрван юлга кузгала. Батырша хәзрәтне, кул-аякларын богаулап, аерым бөркәүле арбага утырталар, янына коралны ике сакчы куялар, аларның мылтыклары һәрвакыт корылган була һәм атып җибәрергә әзер тора.

Һәм — кеше ышанмаслык хәл — шушы хәтле каты күзәтү астында да Батырша сакчылар кулыннан кача ала! 1756 елның 1 октябрь көнне ул, Муром шәһәре тирәсендә сакчылардан ычкынып, урманга кереп кача. Батырша кяферләр кулыннан котылуны үзенә максат итеп куя һәм вакытлыча булса да моңа ирешә. Әлбәттә, качуга ул алдан бик нык әзерләнгән булырга тиеш, бу хакта ул соңыннан патшабикәгә язган «Гарызнамә»сендә дә сиздерә.

Әйткәнебезчә, аны кабат тоталар, кыйнап, арбага бәйләп салалар, ә Муром шәһәренә килеп җиткәч, аяк-кулларына тагын богау салалар. Батыршаның качуында үз гаепләрен сизгән гаскәриләр бу хакта анда-монда язмыйлар, сүз куертып тормыйлар һәм, әлбәттә, тоткынны кыйнаулары турында да беркемгә әйтмиләр. Патшага язган аңлатмасында Батырша да үзен юлда кыйнаулары турында әйтми, әмма аннан соң булган хәлләр шулай дип уйларга мөмкинлек бирә. Качу вакыйгасыннан соң Батырша бик нык чирләп китә.

1756 елның 6 октябрендә Владимир каласына килеп җиткәндә, ул инде ярымаңсыз хәлдә була. Аның кыйналган башы һәм йөзе шешеп чыга, тәне ут кебек яна. Ә бит Батыршаны Петербургка исән-сау китереп җиткерергә боерылган! Батыршаның көтмәгәндә үлеп китүеннән коты очкан конвой, күзенә ак-кара күренмичә, көзге пычрак юлдан атларны Мәскәүгә таба куа. Аларның исәпләре — ничек тә исән-сау Мәскәүгә килеп җиту, әле генә үзләре үтергәнче кыйнаган татар ристаны өчен табиб табу, ничек тә аны, Мәскәүдә аякка бастырып, сорау алырлык хәлгә китерү! Иң мөһиме — юлда нәрсә булганын зур түрәләр белмәсен, иң кирәге — бу бур татар Мәскәүгә җиткәнче үлеп китмәсен. Батырша хәзрәтнең әле тагын биш елдан артык гомере барлыгын, әле аның тагын да зуррак сынаулар үтәсен һәм авырлыклар күрәсен белми шул рус сакчылары. Бу хакта Батырша хәзрәт үзе дә белми әле, әмма үз язмышы өчен, милләте, дине хакына аждаһаның авызында көрәшергә туры киләсен ул инде сизенә.

Ахыры киләсе санда

ТУКАЙ ЭНЦИКЛОПЕДИЯСЕНӘ

ДАҺИГӘ (1913), шигырь. Шагыйрьнең иң соңгы әсәре. Тукай үләренә ике ай чамасы калган вакытта да татар милли-азатлык хәрәкәтендә сизелгән җанлану күренешләре һәм халкын колониаль изүдән коткару турында уйлана, аны сәяси-иҗтимагый, мәдәни яңарышка алып чыгу юлларын эзли, инкыйлабчы яшьләр образын барлый. Шагыйрьнең: *«Гайрәт иттең, армый-талмый йөрдең ушбу юлда син, / Чын сөбатлә алга бардың, бакмый уңга-сулга син»*, дигән бәйте тулысы белән XX гасыр башы татар милли азатлык хәрәкәтенең танылган вәкиле Г.Исхакый шәхесенә, аның әдәби-сәяси эшчәнлегенә туры килә. Милли азатлык һәм Яңарыш идеалларын тормышка ашыру юлындагы «сөбатлеге» — ныклыгы өчен Тукай Г.Исхакыйны «даһи» дип атый. Шигырьдә романтик эчтәлекле метафора һәм символлардан мул файдаланыла. Гасырлар дәвамында коллыкта һәм торгынлыкта яшәгән татар халкы тормышы «мәңге төн» сурәте белән символлаштырылган. Антиномия рәвешендә бирелгән «ут» метафорасына исә ике төрле мәгънә салынган. Аның беренчесе — нурлысы, җылысы, мөкатдәсе — хөр яшәү һәм рухи яңару өчен көрәшкә юнәлтелгән илаһи идеал уты. Икенчесе — зыялы яшьләрне иҗтимагый тартышлардан, чын идеаллардан читкә алып китүче, алдалаучы, сатылырга мәҗбүр итүче — сары алтын ялтыравы. Идеал утына бик якын — бер адым гына торган «даһи» Г.Исхакый шәхесенә бәйле Тукай беренче рус революциясе елларына да күз ташлый, ул чордагы азатлык хәрәкәтендә катнашучы татар зыялыларының милләт алдындагы вазифаларын аңлап бетермәүләренә, вакыйгаларның асылын төшенеп җиткермәүләренә гаҗәпләнә, хәйран кала. Иң элек ул кайбер замандашларының икенче бер утка — алтын ялтыравына алдануларын искә төшерә, милли азатлык һәм иҗтимагый-мәдәни тәрәккыят дигән изге юлдан читкә тайпылулары турында яза: *«Изге юлны һәрвакыт алдап шулай кыскарта ул, / Син сатылмассыңмы дип, фикрең үзенә тарта ул»*.

Ару-талуны белмәс Даһиның чын идеалга таба ихлас хәрәкәт итүен Тукай «мөкатдәс нур»лы, «изге юл» дип атый. Азатлык һәм Яңарыш идеалларының татар милләте өчен әле һаман да тормышка ашырылырга тиешле илаһи бөек максат булып калуы турында түбәндәге нәтиҗәне ясый: *«Артка бакма, даһием, идеал һаман да алда ул; / Алга барганнарга тик табыла табылса — Алла ул»*. Бу юллар XX гасыр башында милли яңарыш өчен көрәш мәйданына чыккан татар халкы өчен бүген дә «ярты юлда күкрәген тотып йөткерүче» шагыйрьнең олы васыяте сыман яңгырый. Көрәшче «даһи» — Гаяз Исхакый юлын Хак Тәгалә юлы дип атау Тукайдан соң С.Рәмиевнең «Сүз» шигырендә күзәтелә: *«Хак юлыннан тагын алда / Иркен итсен сулышыңны!»* Ташкентта яшәгән татар шагыйре Хәмит Төхфи татарларга: «Инкыйраз» кебек юл күрсәтүче әсәрне язган өчен генә дә Гаяз Исхакыйны «Даһи» диеп атасам да, аз булыр күк», — ди.

«Даһигә» шигыре русчага Я.Хелемский, Р.Кутуй, Н.Сафина, В.Думаева-Вәлиева тарафыннан тәрҗемә ителгән.

Шигырь аа бб рәвешендә рифмалашкан, 6 бәйтле, һәр юлы 15 иҗекле, 4 ритмик буынлы; гарузның рәмәл төрендә язылган. Кульъязмасы сакланмаган. Беренче мәртәбә «Аң» журналының 1913 елгы 4 нче (1 февраль) санында басылган. Гыйнвар азагында язылган булса кирәк.

Чыганак
Тукай Г. Әсәрләр: 5 томда. — II том. — Б.266.
Әдәбият
Нуруллин И. Габдулла Тукай. — Казан: Татар. кит.нәшр. — 1979. — Б.271-272; Халит Г. Тукай и его современники. — Казань: Татар.кн.изд. — 1966. — С.171; Төхфи Хәмит. Даһигә // Ватаным Татарстан. — 1992. — 28 март.

Резеда Ганиева,
филология фәннәре докторы

محمد
عليه السلام

БӘЙРӘМНӘРЕБЕЗ

Җаннарда уята шәфкать
Моңлы яңгыраган азан.

Фәнис Яруллин

МӘҮЛИД БӘЙРӘМЕ ҺӘМ АНЫҢ ТАРИХЫ

БИСМИЛЛӘҺИРРАХМӘНИРРАХИМ



ИНСАНИЯТНЕҢ ГОРУРЛЫГЫ ДӨНЬЯГА КИЛГӘН КӨННЕ БӨТЕН КЕШЕЛЕК ГАЛӘМЕ ЯҢАДАН ТУГАНДАЙ БУЛДЫ. УЛ ҖИР ЙӨЗЕНӘ ШӘРӘФ БИРГӘНЧЕГӘ КАДӘР АК КАРАДАН, ТӨН КӨНДЕЗДӘН, ГӨЛ ЧӘНЕЧКЕДӘН АЕРГЫСЫЗ; ДӨНЬЯ ӘЙТЕРСЕҢ ЛӘ ГОМУМИ БЕР МАТӘМ ЙОРТЫ, БАРЧА МӘХЛҮКАТ ИСӘ ХАОСТАН ГЫЙБАРӘТ ИДЕ.

МӘҮЛИД БӘЙРӘМЕНЕҢ КИЛЕП ЧЫГЫШЫ

Мәүлид — Рәсүлебез Мөхәммәднең (с.г.в.) туган урыны, вакытына (12 Рабигүл әүвәл 571 ел) һәм бу уңайдан уздырылган төрле мәрасимнәргә [искә алу йолалары] бирелгән гомуми атама. Пәйгамбәребезнең туу вакыйгасын тасвирлаган чәчмә һәм тезмә әсәрләр дә «мәүлид» дип йөртелә. Кыскасы, Рәсүлуллаһ хәзрәтләренең туган көнен һәм бу уңайдан уздырылган чараларны «мәүлид», ул туган айны «Мәүлид ае», ә төнне исә «Мәүлид кичәсе» дип атау гадәткә кергән.

«Мәүлид», ягъни Пәйгамбәребез дөньяга килгән кичә һәрчак «Кадер киче», «Мигъраҗ кичәсе», «Гарәфә киче», «Җомга киче» кебек хәербәрәкәте мул көннәр белән бер сафта торган. Хәтта аны Кадер киченнән дә өстенрәк куючылар булган.

Пәйгамбәребезнең туган көне мәсьәләсе барыннан да әүвәл аның үз сүзләрендә, ягъни хәдис шәрифләрдә очрый. Мәсәлән, дүшәмбе көне уразасы турында сораган кешегә, ул: «Мин дүшәмбе дөньяга килгәнмен, Коръән дә миңа шул көндә иңдерелде», — дип җавап бирә. Шуңа охшаш сорауны хәзрәте Гомәр биргәч тә, җавабы алда әйтелгәнчә була. Ә инде Ибн Габбас хәзрәтләреннән килгән хәдистә: «Пәйгамбәребез дүшәмбе көнне дөньяга килгән, аңа пәйгамбәрлек дүшәмбе бирелгән, Мәккәдән дүшәмбе һиҗрәт сәфәренә кузгалган, Мәдинәгә дүшәмбе аяк баскан, вафатына ишарә булып саналган аять тә дүшәмбе иңгән һәм, ниһаять, ошбу көндә бу фани дөньяны калдырып киткән», — дигән сүзләр бар. *(Сахих Мөслим, Т.II, Б.819; Мөснәд Әхмәд, Т.V, Б.297; Сөнәнүл Бәйһакый, Т.IV, Б.300).*

Пәйгамбәребезнең туу датасы булып, хәдис һәм тарих галимнәренең уртак карашы буенча, Әбрәхә исемле патша кәгъбәне җимерү нияте белән Мәккәгә яу чапкан елда, мәшһүр «Фил вакыйгасы»ннан илле көн әүвәл; Кисра солтанлыгының кырыгынчы елында; Иранда Әнуширван патша идарәсенең 42 елында; Рабигүл әүвәл аеның уникесе, дүшәмбе көн санала. Шул сәбәпле, бик борынгы чорлардан бирле «Уникенче Рабигүл әүвәл, дүшәмбе көн» Пәйгамбәребезнең туган көне буларак мәгълүм.

Әйтергә кирәк, Рәсүлебез яшәгән чорда да (571-632), Тугъры хәлифәләр (632-661) һәм Әмәвиләр (661-750) дәверендә дә Хәзрәте Пәйгамбәрнең (с.г.в.) туган көненә мөнәсәбәтле мәрасим форматындагы чаралар уздырылмаган. Шулай да, Пәйгамбәрнең «туган көне» төшенчәсе әле сәхабәләр дәверендә үк көн кадагына куелып, бу уңайдан аерым гамәлләр кылу омтылышлары булган. Мәсәлән, яңа тәкъвим [календарь] кертү мәсьәләсе сөйләшенгәндә (638), ел башы итеп Пәйгамбәр «туган көн»не тәкъдим итүчеләрнең булуы «туган көн» төшенчәсенең инде шул чорда ук иҗтимагый аңда шактый әһәмиятле урын алганлыгын исбатлый. Шуңа да Мәүлиднең чишмә башын Хәзрәте Гомәр дәвереннән (634-644) үк эзләү дөрес булыр.

Бу тезисны куәтләп, шуны да әйтик: Хәлифә хәзрәте Гомәр чорында зур тизлек белән арткан мөселман халкына, бигрәк тә балаларга белем бирү өчен мәктәпләр ачылган, рәсми мөгаллимнәр билгеләнгән, һәм Сүрия алыну белән (634-635), атнаның һәр көнендә дәресләр дә укытыла башлаган. Шамнан Мәдинәгә әйләнеп кайткан хәзрәте Гомәрне бик күп халык каршы ала. Алар арасында укучы балалар да булган. Бу көн чәршәмбе була. Хәзрәте Гомәр үзен каршылаучылар сафында балаларны да күргәч, чәршәмбе белән бергә пәнҗешәмбе һәм җомга көннәрен дә ял дип игълан итә. Моннан тыш балалар өчен һәр елны Корбан бәйрәмендә 4 көн һәм «Мәүлид кичәсе» уңаеннан бер атна буе каникул билгеләнгән. Бу гадәтне дәвам итүчеләргә хәер-догалар, ә ташлаучыларга бәддога кылынган. Традиция соңгы гасырга кадәр дәвам иткән. *(Габделхәй әл-Кәттани, әт-Тәратибүл Идарийә (Низамүл хүкумәтин Нәбәвийә), Бәйрут, Т.II, Б.200)*. Моны куәтләгән башка мәгълүматлар да бар. Мәсәлән, Әбү Габдуллаһ Мөхәммәд әл-Ләхми әс-Сәбти (1236 елда вафат) исемле Әндәлүс (Андалусия) тарихчысы Мәүлид турында язганда, әлеге каникуллар турында да искәртеп үтә. Мәүлид чараларына каршы чыккан остазына исә болай җавап бирә: «...ошбу бөек көндә, Мәүлид көнендә, балаларның мәчет һәм мәдрәсәләрдәге сабакларын туктатып торуларына каршы чыга һәм башка төбәк халыкларында бу яллар юк дип уйлый». *(Әбү Габдуллаһ Мөхәммәд, әд-Дүррүл моназзам фи мәүлиди Нәбийил могаззам, кәг.12/а.)* Әбү Габдуллаһ Мөхәммәд әс-Сәбти бу сүзләре белән Әндәлүстә үткәрелгән чараларның башка төбәкләрдә, шул исәптән Хиҗазда да узганлыгын, шул сәбәпле мәктәпләрнең ялга туктаганлыгын искәртергә теләгән. Шуңа өстәп, хаҗ юлчылары һәм сәяхәтчеләрнең Мәккәдәге бәйрәм чараларын сурәтләвен дәлил итеп китерә. Инде килеп, хәзрәте Гомәр чорында башланып, урта гасырларда Әндәлүстә гамәлдә булган Мәүлид ялларының Мәккә-Мәдинә якларында да күзәтелүен раслаган башка чыганаклар да бар.

Мәүлид куаныч-шатлык көне булу сәбәпле, VIII гасырда Багдад якларындагы кайбер суфиларның Корбан һәм Рамазан гаетләрендәгечә ураза тотмаулары риваять кылына. Ягъни Мәүлид чын мәгънәсендә бәйрәм дип кабул ителгән.

Шулай да бүгенге форматтагы Мәүлид мәрасимнәрен кемнең, кайчан, кайда һәм ни рәвешле башлап җибәрүе турында артык тәфсилле мәгълүмат сакланмаган. Ләкин IX йөздән башлап әлеге гадәтнең ислам галәме буйлап җәелүе, рәсми тантаналар рәвешендә ел саен үткәрелгән бу мәрасимнәрнең Гыйрак, Хиҗаз төбәге, Йәмән, Хорасан, Һиндстан, Мисыр, Мәгъриб (Марокко, Тунис, Җәзаир (Алжир)) һәм Әндәлүс кебек мөселманнар гомер иткән барча төбәкләрдә диярлек таралган булуы аңлашыла.

Бәйрәм чараларында Мәккә белән Мәдинә шәһәрләренең роле искиткеч зур булган. Бигрәк тә, Пәйгамбәребез дөньяга килгән йорт Мәүлиден нәби мәрасимнәренең башлангыч ноктасы һәм үзәге санала. Мәккәдә Мәүлид урамы дип аталган җирдә урнашкан һәм Хаҗҗаҗ бин Йосыф әл-Бәйза дип исемләгән бу йорт, соңрак Харун Рәшиднең анасы әл-Хайзуран тарафыннан мәчеткә әйләндерелгән. Ул Мәүлид көнне зиярәтчеләргә ачыла, Мәүлид кичләрендә монда вәгазь-нәсыйхәт әйтелә торган була. Мәшһүр галим Гали әл-Кари хәзрәтләре Мәккәдәге бу чараларга шәхсән катнашуын һәм Пәйгамбәребез туган йортны зиярәт кылуын теркәп калдырган. Мәдинә шәһәрендә Рәсүлебезнең Раузасы (кабер шәрифләре) алдында мәүлид шигырьләре укылуы хакында да риваятьләр килеп җиткән.

Мәүлид тантаналарының иң атаклысы, һичшиксез, Әрбилдә [Гыйрактагы Көрд төбәге башкаласы] булганыдыр. Бу тантаналар «мәүлид котлауларын оештырган тәүге солтан», «гарәп һәм гаҗәмнәрнең мәүлид зыяфәтен уздырган беренче падишаһ» исемнәрен йөрткән Әрбил атабәге Мозаффареддин Күкбүре (1190-1233) тарафыннан рәсми дәрәҗәгә күтәрелә. Әүвәл Әрбил, соңрак Мусулда Мәүлид чаралары шактый тантаналы рәвештә үткәрелә торган була. Якын-тирәдән җыелган фәкыйһләр [шәригать законнары белгече], суфилар, оста вәгазьчеләр, карилар [Коръәнне яттан укый алучы], әдип вә шагыйрьләр, гади халык белән янәшә түрәләр дә катнашкан бу чаралар өчен сый-хөрмәт әзерләнгән, аеруча юксыл-фәкыйрьләргә мул ярдәм өләшенгән. Ул арада вәгазьчеләр хөтбә сөйләгән, гаскәрләр тамаша күрсәткән. 12 көн дәвам иткән тантана ярдәмендә халык күңелен яулаган Мозаффареддин Күкбүре галим-голамә каршында да ихтирам казанган.

Әндәлүстә һәм Гырнатада (Гранада) [Испаниядәге шәһәрләр], Җәзаирның [Алжир] Тилимсан шәһәре Зәйтүния мәчетендә үткәрелгән Мәүлид мәрасимнәре бик мәшһүр. Аеруча Әндәлүстәге котлаулар тора-бара әдәби бәйге формасын ала башлаган. Мәүлидкә багышлап язылган шигырь һәм касыйдәләр ел саен төрләнә барган, беренчелекне алучыларга исә зур бүләкләр бирелгән.

Мәүлид тантаналары иң киң таралган төбәкләрнең берсе — Мисыр. Монда шигыйлык мәзһәбен тоткан Фатыймиләрнең озак еллар хакимлек итүенең (909-1171), Мәүлид чаралары программасына шигыйлар аеруча олылаган хәзрәте Гали, хәзрәте Фатыйми һәм хәзрәте Хөсәеннәр истәлеген саклаган элементлар кертелүнең дә тәэсире зур. Ләкин Мәүлид тантаналары бөтенләе белән Фатыйми гадәтләреннән туган, дип кистереп әйтү дөрес түгел.

Бу котлаулар Госманлы дәүләтендә Сөләйман Чәләбинең (1422 елда вафат) «Вәсиләтүн нәҗат» (1409) поэмасын уку формасында дәвамын таба. Солтан Морад III заманында (1574-1595) рәсми бәйрәм статусын алган Мәүлид мәрасимнәре солтан Әхмәд II чорында (1691-1695) иң югары ноктасына җитә. Госманлыда гыйлем әһелләре һәм шәйхелисламнар, үз чиратында, финанс ярдәме күрсәтү һәм вакыфлар кору кебек юллар аша бу мәрасимнәрне уздыруга булышлык иткән. Шәйхелислам Яхъя әфәнденең Рабигүл әүвәл аеннан Рамазан аена кадәр атна саен мәдрәсәсендә мәүлид укытып, сый-хөрмәт әзерләве, шәйхелислам Чәркәс Хәлил әфәнденең (1821 елда вафат) мәүлид укыту өчен зур микъдарда акча биреп калдыруы, шәйхелислам Хуҗа Сәгъдетдин әфәнденең солтан Морад III нең вафат көне уңаеннан Ая Суфия мәчетендә укылган хәтем һәм мәүлидкә катнашуы, шулай ук Мәккәи Мөкәррәмәдә Мәүлид чаралары вакытында мәүлид укыла торган көрсигә ябылган бизәкленәкышле җәймәләр җибәреп тору кебек фактлар госманлыларның Мәүлид мәрасимнәренә биргән әһәмиятен күрсәтә. Мәүлидкә багышланган ял көннәре госманлыларда да булган. Вәкилләр мәҗлесе [дәүләт шурасы] 1910 елның мартында чыгарган карары нигезендә, Мәүлид көне рәсми яллар исемлегенә кертелгән.

МӘҮЛИДНЕҢ МАКСАТЫ ҺӘМ ЭЧТӘЛЕГЕ

Ислам динен тоткан халыкларда Мәүлиднең максаты турында мөһим карашлар яшәп килә. Күпләрнең фикеренчә, Мәүлид — гыйбадәт булудан бигрәк, дини эчтәлеккә ия бер төркем игелекле гамәлләрне үз эченә алган иҗтимагый чара. Чамадан ашмыйча, белеп үткәрелгәндә, аның уздырылуы җәмгыять өчен файдалы.

Ошбу максат сакланган очракта, бик күп хәдисче, тәфсирче, фикъһ [хокук мәсьәләре турындагы гыйлем], кыйраәт [дөрес итеп уку] галимнәре һәм тарихчылар бу бәйрәмне бик тә кирәкле, күркәм гадәт дип бәяләгән. Бу мәсьәләгә уңай караган борынгы чор галимнәреннән Әбү Шамә әл-Мәкъдиси (1267 елда вафат) үз фикерен болай белдерә: «Чорыбызның иң күркәм яңалыкларының берсе — һәр ел Әрбилдә Пәйгамбәребезнең (с.г.в.) туган көне уңаеннан уздырылган чаралар; бирелгән садакалар, фәкыйрьләргә таратылган ярдәмнәр һ.б. Болар Рәсүлебезгә булган мәхәббәт вә сөюнең күрсәткечләредер». Әбү Шамәнең бу карашын Ибнүл Җәүзи (1116-1201), Имам ән-Нәвәви (1233-1277), Ибнүл Җәзәри (1350-1429), Ибн Һаҗәр әл-Гаскәлани (1372-1449), Җәләледдин әс-Сөйути (1506 елда вафат), Ибн Һаҗәр әл-Һәйтәми (1504-1567) һәм Гали әл-Кари (1605 елда вафат) кебек ислам галәменең мәшһүр затлары да уртаклашкан. Алар да әлеге чараларга теләктәшлек белдергән. Кирәге чыкканда, тәнкыйтьчеләрнең авызын томалагарга да күп сорамаганнар. Бигрәк тә галим Ибн Һаҗәр әл-Һәйтәми: «Мәүлид — Коръән уку, Пәйгамбәргә (с.г.в.) салават әйтү, шигырь уку һәм фәкыйрьләргә хәер-садака өләшүдән гыйбарәт», — дип, бәйрәмнең чикләрен һәм кагыйдәләрен билгеләргә тырышкан. Мәүлидне бик тә мөһим бер иҗтимагый күренеш буларак бәяләгән Ибн Һаҗәр фикеренчә, бу гамәлләрнең яхшы якларын алга чыгарып, билгеләнгән критерийларга каршы килгән күренешләрдән ерак тору мәслихәт. Шулчакта бик тә күркәм бер гамәл булыр. Әлеге карашларны сүзен-сүзгә кабатлаган Җәләледдин әс-Сөйути дә Мәүлидне яклап чыга һәм каршы килүчеләргә кыска, ләкин үтемле итеп түбәндәгеләрне әйтә: «Болар Пәйгамбәргә карата мәхәббәтнең чагылышы, куаныч-шатлык күрсәткече булганга, эшләүчесен савапка илтәчәк яңалыктыр, шуннан артык берни юк». Мәүлиднең максатын Пәйгамбәребезгә карата мәхәббәтнең җәелдерелүендә күргән Сөйути бу тантаналарны гавам арасында популярлаштырган Мозаффареддин Күкбүрене дә рәхмәт хисләре белән искә ала.

Госманлы тәсаувыф [суфи] галимнәреннән булган Габдрахман бин Ягъкуб Чәләби Мәүлиднең максат һәм эчтәлеген тагын да системалырак рәвештә аңлатырга тырышкан: «Мәүлид, тематик җәһәттән карaганда, Пәйгамбәребезнең тормыш юлын өйрәнгән сийәр гыйлеменең бер бүлеге. Ул Рабигүл әүвәл аенда мөселманнарның, дөнья вә ахирәт савабын өмет итеп, җыйнаулашып Коръән укуы, салават әйтүе, хәзрәте Пәйгамбәрнең өстенлеген һәм күркәм сыйфатларын бәян иткән шигырь-касыйдәләр укуы, хәер-садака өләшүе, сөенү-шатлануы, сый-хөрмәт күрсәтүеннән гыйбарәттер». Аның карашынча, Мәүлиднең «хөкеме», ягъни мәгънәсе һәм максаты Пәйгамбәребезнең дөньяга килү мөнәсәбәте белән куану булса, үткәрелү рәвеше исә — Коръән уку, Пәйгамбәргә салават китерү, Аның дөньяга килүен тасвирлаган шигырь һәм мәдхияләр уку, хәер-садака өләшү. Димәк, Мәүлиднең асыл максаты — Рәсүлебезнең дөньяга килү мөнәсәбәте илә сөенүдер.

Йомгак ясап әйткәндә, Пәйгамбәребезнең туган көнен белдерә торган махсус терминга әверелгән «мәүлид» борынгыдан ук рәсми мәрасим булып калыплашкан. Ул ислам традицияләренә туры килгән эчтәлеге һәм шактый төгәл кысалары булган иҗтимагый чара рәвешендә, чорлар аша узып, безнең көннәргә килеп җиткән. Ошбу мәрасимнәр, үз чиратында, гыйльми һәм әдәби процесслар башлануга да этәргеч биргән.

***Ренат Миңнегалиев** әзерләде.*

МИШӘРСТАНДА МӘҮЛИД

«АКСАКАЛ»

Җәй көне, утау өсте иде. Аталар, әниләр, гадәттәгедән киресенчә, утаудан көн уртасында ук кайттылар. Апалар өйләребезне җыештыру, савыт-саба, чынаякларны юу, самаварлар агарту белән, әни «бәйрәм госеле» кирәкярагы хәзерләү белән мәшгуль иде.

Әти каладан кайтты. Без, кечкенә балалар, әти арбасының артына ябышып булса да арбада йөрүдән ләззәт алу, әтидән кала бүләге өмет итүләр шикелле өметләр, үзебез аңламый торган каршы алу шатлыклары белән шатланып, йөгерешеп каршы чыктык.

Арбаның артына гына түгел, аның өстенә менеп утырып килү дә насыйп булды.

Капкага килеп җитүгә, һәммәбез «мин элек тә, мин элек», ди-ди, капка ачарга йөгердек. Ат керде, арба туктады. Атны туарырга юнәлгән әтигә безнең юл өстендә казынуыбыз тәэсир иттеме, эчен пошырдымы, әллә безнең кәефебезне малкайның рәхәтеннән алда тотасы килдеме — атны үз иркенә куеп килеп, йөкне бәйләгән арканны чиште, җәймәне ачты, эчтән ике капчыкка тутырылган әйберләр биреп, өйгә кертергә кушты. Без капчыкларны күз ачып йомганчы өйгә кертеп тә өлгердек, авызларын чишеп, эчендәге чәй, шикәр, келиндер, коры йөзем шикелле зур бәйрәмнәрдә генә эләгә торган «төче-мөче»ләрне күздән үткәрдек. Алып капкаларга да кызыгып-кызыгып куя идек.

Әни килде, ансыннан-монсыннан берәр кисәк бирде. Без дөньяга сыешмаслык зур шатлык белән ишегалдына да чыгып җиттек. Әти атны туарып бетергән иде инде. Безне ат сакларга җибәрде. Бер атка икәүләп атланып, күңелебез җиденче кат күккә ашкандай булып чыгып киттек.

Кич булды. Безнең янга әти килеп, атны төнгә богаулап калдырып, үзебезне өйгә алып кайтты. Өйгә кергәндә, әниләр, апалар бәйрәм киемнәрен кигәннәр, әллә ни көтәләр; самавыр куелган иде.

Әти безне мунчага алып китте, «бәйрәм госеле» коендырып киләчәген әйтте. Мунчадан «бәйрәм госеле» белән пакьләнеп, яңа күлмәкләр киенеп килгәндә, самавыр инде өстәлдә иде. Өстәл янына тезелеп утырдык, чынаяк асты тәлинкәләрендә генә булса да, безнең өчен бик зур, бик кадерле кара җимеш, коры йөзем, инҗир, өрек шикелле «тәмле»ләр, келиндер кебек каладан гына китерелә торган ашамлыклар куелган иде. Чәй ясалды...

Менә ишектән бездән аз гына зуррак дүрт бала керде. Әллә нинди, дога сыман нәрсә укып көйли башладылар. Көйләренең актыгы «Мәүлид ае килде янә», дип туктый иде. Укып-укып тордылар, туктадылар. Әни аларга капчыктан җимешләр алып бирде. Әти ничәшәрдер тиен акча бирде. Һәммәбез дога кылдык. Балалар чыгып китте, чәй эчү дәвам итте. Тагын берничә төркем бала кереп, шундый ук көйләр көйләп, укып чыгып киттеләр.

«Болар мөнәҗәт укыйлар, мәктәптә укысаңыз, сез дә шулай укырсыз», — диеп, әни безне мөнәҗәт укуга кызыктырып куйды. Минем шәкерт буласым килде. Ләкин беркемгә дә әйтмәдем.

— Мөнәҗәт башланды! — дигән тавышка апалар, кулларындагы һәммә эшләрен, әйберләрен ташлап, мәчеткә караган тәрәзәгә барып тыгылдылар. Без дә, өстәлне ташлап, тәрәзә янына бардык. Ләкин анда урын юк иде. Без урамга чыгып киттек. Күрше Хәлимә абыстайлар янында хатыннар, кызлар, безнең иптәш балалар җыелган, мәчет манарасына карап торалар иде.

Мәчет манарасы төрле төстәге фо-

нарьлар белән яп-якты яктыртылган, азан әйтә торган җирендә әллә ничә кеше кычкырып, бик күңелле итеп мөнәҗәт әйтә. Апалар да чыкты: төн уртасына кадәр тыңлап тордык.

Безне бик иртә уяттылар. Кояш чыкканда уяу булырга кирәклеген аңлаттылар, юындырдылар. Без торганда, әти инде намазга барырга хәзерләнгән, башына чалмасын кигән, «Ясин» укып утыра иде. Әти дога кыла башлады, без «амин» тотарга тиеш булдык. Һәммәмез «амин» тоттык, әти намазга китте.

Мичтән күмәчләр чыгарылды. Өстәлгә ашъяулык җәелде. Ике зур, бер кечерәк күмәч өстәлгә куелды, муллаларны көтү башланды.

— Гарәфә йөри башладылар! — дигән сүз артыннан ук капкадан өйгә керә торган юл вак-төяктән тәмам арчылды.

Безгә гарәфә укыганны тыңлау күңелле күк күренгән булырга кирәк. Муллалар кергәндә, без чаршау артына апалардан алда тезелешеп өлгердек.

Муллалар керде. Өстәл янына утырдылар. Карт хәзрәт Коръән укый башлады. Әти муллалар ягында, әни чаршау артында тезләнеп, бик түбәнчелек һәм ихлас белән тыңлап тордылар. Муллалар «амин» тотты. Әтиләр, әниләр һәм апалар — һәммәсе «амин» тотканны күргәч, берсе дә сорауларыбызга җавап кайтармагач, эндәшмәгәч, без дә аларча итеп кулларыбызны күтәреп «амин» тоттык.

Өстәлдәге ике зур күмәчне ике мулла, кечкенәрәген мөәзин алды. Әти ике муллага зуррак, мөәзингә аз гына кечерәгрәк бакыр акча да бирде.

Муллалар дога кылып чыгып китте. Мин эчемнән генә мулла булырга кызыгып калдым.

Безне әби-бабаларыбыз белән күрешергә бабайларга җибәрделәр. Әбиләр һәм андагы апа-җиңгиләр сыйлап, төрле бүләкләр биреп кайтарды. Бу көндә безгә киң иркенчелек бирелгән иде. Теләгән һәммә җиребезгә бара, теләгән эшләребезне үзебезчә эшли алдык. Бу көн үткәч тә, Мәүлид бәйрәме тагын тизме булыр икән, дип көтә торган булдык.

ӨСТӘМӘ

Мишәрләр арасында Корбан гаете алдындагы чын гарәфә көненнән башка, Рамазан гаете алдындагы көн һәм һәммә дини бәйрәм көннәре «гарәфә көн» диеп йөртелә. Шушы көндә мулла белән мөәзин яки ике муллалы мәхәлләләрдә муллалар белән мөәзин, үз мәхәлләләрендәге өйләрнең, ярлысын, баен аермыйча, садака бирәчәге вә бирмәячәгенә игътибар итмичә, һәрберсенә кереп, Коръән укып йөри, савабын шул өй халкыннан вафат булганнар рухына багышлый, терекләренең тормышларына бәрәкәт, үзләренә бәхет вә сәгадәт теләп дога кыла. Болай йөрү «гарәфә йөрү» диеп тәгъбир кылына. Һәркем хәленә карап ашамлык әйбере һәм акчалата садака хәзерләп куя. Мескен гаиләләргә муллалар үзләре садака сыйфатында алдан җибәреп куялар. Яхуд Коръән укып дога кылганнан соң, үзләре ашамлык әйбер һәм акчалата садака биреп чыгалар.

Мәүлид кичәсендә манараларда укыла торган мөнәҗәтләр гарәпчә мәүлид касыйдәләре һәм берничә татарча касыйдәләрдән гыйбарәттер ки, боларның басмалары да бар.

(«Кояш» газетасы, 1914 ел, 24 гыйнвар)

ДӨНЬЯДА СҮЗЕМ КАЛЫР

Бер сүз эзлим сиңа әйтер өчен,
Беркем әйтмәгәнне, якынны;
Тормыш кебек тирән булсын ул сүз,
Мәхәббәттәй булсын ялкынлы.

Фәнис Яруллин

ИЛЕ БАРНЫҢ ТЕЛЕ БАР

ГҮЗӘЛ НӘБИУЛЛИНА, ЛИЛИЯ ГЫЙЛӘҖЕВА,

филология фәннәре кандидатлары

Туган телең — үзе
Олы бер фән ул.

Клара Булатова

Туксан тугыз мәгънәсез сүзгә каршы
Бердәнбер мәгънәле сүз табып кара!

Әхмәт Рәшит

Туган тел ул — бездән соң да
Яшәр өчен туган тел.
Бүгенгедән киләчәккә
Дәшәр өчен туган тел.

Зиннур Насыйбуллин

Кешеләрнең авызына төнлек тыгып булмый.

***

Ут белән сүз арасында охшашлык бар:
Икесе дә яндыра һәм көйдерә ала.

***

Дусны дошман ясар өчен,
Бер ялгыш сүз дә җитә.

***

Күңел байлыгы җанга телебез аша туплана.

Фәнис Яруллин

Сүзеңне үлчәп әйт: әйтелгән сүз — атылган ук. Ук бәгырьгә кадалгач, үкенүләр соң була, җәрәхәт мәңгегә кала.

***

Язган сүз — аткан ук. Үзеңә килә дә кадала.

Рабит Батулла

Шатлыкларны, кайгыларны
башка телгә
итеп буламы тәрҗемә?

Рәдиф Гаташ

Җиңелмә сүздә, җиңелсәң,
Җиреңне дә дауларлар.
Юкка гынамыни җирдә
Чичән булган бабаңнар?!

***

Исәнләшик.
Мин — халкыңның теле,
Кылыч телгәләгән хәтере.
Сиңа мине «үлде» дигәннәрдер,
Мин исән-сау, мин бар, мин тере!

***

И туган тел!
Сине Әнкә итеп
Йөрәгендә саклый бу халык.
Таралган ул...
Әгәр Син булмасаң —
Бетәр иде күптән югалып.

Рәшит Әхмәтҗанов

Башка телләр белән чагыштырып карамасаң, үз телеңнең байлыгын, үзенчәлеген, әчке хосусиятен беркайчан да бөтен тулылыгы белән аңлап һәм ачып бетереп булмый.

Суфиян Поварисов

Сүзнең иң кадерлесе —
Әйтелми калганы.

Әхәт Гаффар

Сүзләр телнең күрке булса,
Мәкаль — телнең тоткасы!

Илдус Гыйләҗев

Җылы сүздән күңелдәге
Суыклар шартлап сына.
Матур хыял шытып чыга
Җылы сүз җылысыннан.

***

Кычкырган каргыштан көчле
Пышылдап әйткән рәхмәт.

Ренат Харис

Булмый телне калыплап,
күңелне авызлыклап!

***

Күп телләрне белү — яхшы шөгыль,
туган телең үги калмаса;
Җаның салып әйткән әткәң сүзен
синең аша балаң аңласа.

***

Тик шунысы хак: фәкать туган телдә
Иман иңә кеше җанына!

***

Әй, килә соң тапкыр сүзләр
бәхәс тынгач!..

Равил Фәйзуллин

Телләр үлми! Үлә бары
Телен җуйган халыклар!

Рәфикъ Юныс

Озын тел авызга гына түгел, дөньяга сыймый.

***

Сүз документ түгел, эш кәгазенә теркәп булмый

Җәүдәт Дәрзаман

Халкым теле — хак телем син,
Йөрәк телем.
Киләчәгем өчен мәңге
Кирәк телем!

Лена Шагыйрьҗан

Туры әйтелгән сүз — гаделлекнең аяусыз көндәше.

***

Сүздән такыялар үрелә, сүздән кылыч йөзе канлана, сүздән гөл илләр көл ителә, сүздән чәч толымы еланга әверелә.

***

Мендәргә сөйләгәнең мамыкка китәр, мөнбәрдән сөйләгәнең халыкка җитәр.

***

Кылычка кылыч килешсә, корыч ныклыгы җиңә. Сүзгә сүз килешсә, иман аклыгы җиңә.

***

Сүзнең эресен сайлый белсәң, фикерең өрелер булыр.

***

Ир-ат... Ат-ир... Безнең телебезгә генә хас нинди бөек мәгънә. Рухи һәм җисми бергәлек.

***

Тел ул — халыкның рухи дәвасы. Өлкән буын телне салмак олыгайтып яшәтсә, яшь буын телне санлап яшәртә.

***

Тел байлыгы — буыннан-буынга күчә барган ганимәтле мирас, халык бәгыренә язылган тере сүзләр йолдызлыгы.

***

Мәһабәт тел тирәге — милләтнең яшәү терәге.

***

Тел ул — халыкның рухи дәвасы.

***

Халкымның тәкъдир-язмышы — төрле дәверләрдә баш июе дә, баш чөюе дә, әрнүле ярасы да, бәхетле күз карасы да, чая матурлыгы да, аяусыз батырлыгы да — ана телебездә чагыла!

***

Халыкның холык-табигате, тарихы, гореф-гадәте, омтылышы, уй-гаме сүзләргә сыйган. Ана карыныннан

ук без телнең моң-яңгырашын тәнвөҗүдебезгә сеңдереп үсәбез. Туган телнең көй тирбәнешенә, нәкъ менә шул телнең табигатенә хас тәңгәл моң туа. Тел тәмен җуйган — моңын да җуя. Кешенең тәнен, җанын туган тел сугарып килә, ул аның холкын билгели, аң-зиһененә чиксез үсеш мөмкинлеге бирә, шул телнең эчке хасиятеннән яралган җыр-моң исә кешенең халәтрухиясенә дәва, омтылыш дәрте өсти.

Марсель Галиев

Тел беттеме — хәтер югала.

***

Хәбәрләрнең яхшысы да, яманы да тиз тарала.

Нур Әхмәдиев

Бәхетсезгә әйләнгәнен күрдек
Туган телен үги иткәннәр.

Харрас Әюп

Изсәләр дә, кылыч чапсалар да,
Юлыкса да юлда мең үткел,
Шигырьле тел фанилыкка бәйсез,
Үлемгә баш бирми андый тел.

***

Тел ачылгач әйтә алсаң:
«Әни!» — дип,
Тел ачылгач әйтә алсаң:
«Әти!» — дип,
Күзләреңә яшьләр тыгылмас,
Туган телең әле бу булмас.
Соң минутта әйтә алсаң:
«Әни!» — дип,
Соң минутта әйтә алсаң:
«Әти!» — дип,
Күзләреңә яшьләр тыгылыр,
Туган телең әнә шул булыр.

Зөлфәт

Эзсез узмый кеше сүзләре дә,
Кылдан нечкә күңелгә тиеп.

Флёра Тарханова

Туган телем бабамнардан —
Иң бай мирас, васыять.

Әмир Мәхмүдов

Хикмәтле сүзне үтә җентекләп эшкәртелгән кыйссага тиңлиләр икән, мәкальләрне күздә тотып әйткәндә, безнең халык бихисап кыйсса иҗат итүче булып чыга.

***

Тирән мәгънәле чын хак сүзләр артык уйлап тормыйча әйтелә.

***

Бала төшендә нинди телдә саташа, аңарга шушы тел якынрак була.

Зиннур Мансуров

Кешенең күңелен җылыту, яшәү дәрте белән канатландыру өчен, нибары бер сүз яисә бер елмаю җитә. Елмаю теләсә нинди сугышлардан, ызгыш-талашлардан өстен.

Рашат Низамиев

Татармын мин, димә, газиз балаң
Бөек Тукай телен онытса.

Шәмсия Җиһангирова

Иң батыр яклаучы —
Галиҗәнап Сүз.

***

Тел байлыгы — көзге. Аңа карап, халыкның үзен күреп була.

Бикә Рәхимова

Сүзсез калу — җавап көтү,
Рәнҗүле күз — сүзсез хөкем.

Акъегет

Ана телен җуйган — башка күп телләр белүенә карамастан милләтсез...

***

Алтын бәһасенә торырлык сүзләр дә бар. Шуңар аларны иң кирәк булганчыга кадәр дәшми саклап торуың алтынга тиң.

***

Сүзләргә колак сал: күзең — ачык, авызың ябык булсын.

***

Ишарәне кул белән дә, күз белән дә, ым белән дә «күрсәтеп» була... Фикер әйтү өчен — сүз, сүз әйтү өчен, тел кирәк!

***

Мәгънәле сүз мәгънәсез гамәлдән чигендерә ала, әмма мәгънәсезлектән котылу өчен, сүз генә җитми...

***

Сүздән ботка пешереп була — ашап булмый.

***

Телсез ризык тәмен белә, сүз тәмен белми.

***

Әйткәнеңнең мәгънәсе — кайтарып әйтелгән сүз дәрәҗәсендә... Дәшмәсәләр, ишетмәгәннәр һәм кабул итмәгәннәр булыр.

***

Әйтергә онытылган сүз — хәтерсезлек кенә түгел, сүзнең зәгыйфьлеге дә.

***

Кыек утырып, туры сөйләргә маташучыны бөкресе фаш итәр...

***

Нахак сүз — арттан атылган агулы ук.

***

Сүзендә торган — нәрсәдер корган.

***

Сүз белән сөзеп була.

***

Сүз әйтеп терелтеп була, үтереп була. Тудырып булмый.

Мөхәммәт Мирза

Исемен югалтып кына, халык үлми әле. Телен оныткан халыкның тамыры корый.

Мөдәррис Вәлиев

Вакытында әйтелгән сүз генә асыл.
Алда әйтелсә — көлке,
Соңга калса — төссез.

***

Мәңгелекнең тынычлыгын җуйган
Әйтелмәгән сүзләр.

***

Туган телне җеназасыз
Күмеп куйды, таптый-таптый.
Заманалар үзгәрде.
Күмгән урынын эзли —
Тапмый гына бит, тапмый.

***

Туган телгә җан өрәсе иде...

Факил Сафин

***

Сүз, кош кебек, бер авыздан очса — тоттырмый. Әгәр бик күп сөйләнеп йөрсәң, аягыңа да урала.

Нәбирә Гыйматдинова

Сүз — могҗиза ул! Сүзгә ияреп, уй чыга, димәк, акыл, хәтер суырылып чыга... Сүз сихердән өстен, ырымнан алда йөри. Сөйләшкән кешене, сүз белгән кешене юлдан яздыру кыен.

Галимҗан Гыйльманов

Телең өчен тезләнергә була.

***

Киләчәгенә
телсез, лөгатьсез
бармый ул халык.

Газинур Морат

Сүзнең иясе юк, чәчеп ташлагандай, бик тиз тарала бит ул дөнья йөзләренә.

Ркаил Зәйдулла ■

*Сәхифә «Дөньяда сүзем калыр» (Татарстан китап нәшрияты, 2012 ел) китабы нигезендә даими алып барыла.

ЯХИН А.
СИСТЕМА ТАТАРСКОГО ФОЛЬКЛОРА. —
Набережные Челны: НИСПТР, 2012. — 285 с.

Нәкъ вакытында, инде җәмәгатьчелек аңы фикерне кабул итәргә өлгереп беткәч, язылган китаплар була. Кайбер китаплар исә заманнан алда, кешеләрнең карашын үзгәртер өчен дөньяга киләләр. Хөрмәтле остазыбыз Альберт Гатуф улы Яхинның 2012 елда беренче тапкыр тулысынча дөнья күргән әлеге зур фундаменталь хезмәте дә шундыйлардан. Китап 1980 еллар башына язылып бетә һәм шушы елларда өлешләп, 3 китап эчендә укучы игътибарына тәкъдим ителә. Автор аны тулысы белән фәнни әйләнешкә кертә алмый: яңалыкның авыр юл ярган еллары була ул.

Инде 1960 елларда Тарту (Эстония) һәм Мәскәү галимнәре СССРда бердәнбер дөрес саналган марксистик-ленинчыл әдәбият белеме методологиясе белән тәңгәл килмәгән тикшеренүләр башлый. Соңрак төркем «Тарту-Мәскәү семиотика мәктәбе» исемен ала. Бу тикшеренүләр «тимер пәрдә артындагы» чит ил галимнәренең структурализм юнәлешендәге эзләнүләре белән аваздаш була. Лингвистик методларны яңадан-яңа объектларга карата кулланып, Ю.М.Лотман, Б.А.Успенский, Вяч.Вс.Иванов кебек абруйлы галимнәр, аларның укучылары сәнгать белеменә, этнографиягә, тарихка, мифологиягә мөрәҗәгать итә. 1970 елларда структур анализ принципларын һәм алымнарын кулланган фундаменталь фәнни хезмәтләр дөньяга чыга. Шушы методология үзе мөстәкыйль фәнни юнәлешләргә нигез була. Татарстан фәнни җәмәгатьчелеге Казан университетының мөхтәрәм профессоры Й.Г.Нигъмәтуллина җитәкчелегендәге Казан база группасының «структурализм нигезендә комплекслы метод» дип аталган метод тәкъдим итүе белән горурлана ала. Альберт Гатуф улы Яхин исә әдәби әсәрне системалы-комплекслы анализлау методикасын татар халык авыз иҗатын өйрәнүдә куллана. Әлеге хезмәт — галимнең шушы эзләнүләре нәтиҗәсе.

Хезмәтнең беренче өлешендә татар фольклорын өйрәнүнең яңа системасы тәкъдим ителә. Структуралистлар кебек үк, А.Г.Яхин татар халык авыз иҗатын бербөтен итеп карый һәм аны берләштерә торган «вертикаль» һәм «горизонталь» тирәкләрне барлый. Әйтик, автор фикеренчә, халык авыз иҗаты ул — иҗтимагый-психологик мөнәсәбәтләрнең чагылышы. Шуңа күрә дә, күпвариантлы сәнгатьтән аермалы буларак, биредә төп бер структура — «Без» — «Алар» структурасы өстенлек ала. Галим бу структураның ачык (ягъни дәвам ителә ала торган) 5 төркемен аерып күрсәтә: 1. Безнең халык, милләт — Аларның халкы, милләте; 2. Безнең сыйныф, хезмәт ияләре — Аларның сыйныфы, хезмәт ияләре; 3. Безнең нәсел, гаилә — Аларның нәселе, гаиләсе; 4. Субъект (ирешергә теләгән халәттә) — Субъект — ничек бар шулай; 5. Халык, сыйныф, нәсел, гаилә — Табигать күренешләре һ.б. (26 бит). Бер яктан, хезмәт «социализмга барган» елларда язылган, сыйнфыйлык парының мөһим урын алуы — мәҗбүри күренеш. Икенче яктан, галимнең, сыйнфыйлыктан бигрәк, милли, нәсел һәм гаилә, шәхси мөнәсәбәтләрнең халык авыз иҗатында әһәмиятле урын биләвен күрсәтүе игътибарга лаек. Структураның ачык булуы исә башка заманда яшәүче

галимнәргә аны үзгәртү мөмкинлеге бирә.

Горизонталь дәрәҗәдә исә танып белү һәм эстетик (эстетик идеал тәкъдим ителеше) яктан фольклорның сыйфатларын барлау шулай ук төпле һәм актуальлеген җуймаслык итеп эшләнгән. Шушы ике дәрәҗәне хасил итә торган билге һәм вазифаларның төрлелеге фольклорда жанр хасиятләрен китереп чыгара, дигән нәтиҗә ясала. Татар халык авыз иҗатының автор ачыклаган әлеге катлаулы төзелеше хезмәтнең методологик асылын тәшкил итә.

Хезмәтнең өченче, дүртенче бүлекләрендә бу методология аерым жанрларны — әйтемнәрне, мәкальләрне, табышмакларны, җырларны, мәзәкләрне — анализлау өчен нигез булып тора. Системалы-комплекслы анализлау методы авторга татар халык авыз иҗаты жанрларының милли үзенчәлекләрен билгеләргә ярдәм иткән. Алай гына да түгел, методология хәтта аерым жанрлар арасында чикләрне дөрес билгеләргә юл ача. Мәсәлән, автор, әйтемнәр һәм мәкальләр арасындагы чикне күрсәтеп, теге яки бу текстның нинди жанрга каравын төгәлләштерү критерийларын ачыклый (86-87 битләр). Шушы урында, гомумән, хезмәтнең бер сыйфатын телгә алу урынлы булыр — автор һәрдаим төгәллеккә омтыла. Һәр жанрның төп сыйфатларын төгәл билгеләп, санап-күрсәтеп баруму ул, методны куллану этапларын ачыклаумы — фәнни хезмәтләрдә иң әһәмиятле булган бу үзенчәлек фикернең төгәлләнеп, йомгакланып баруы хакында сөйли.

Хезмәтнең тагын бер ягы игътибарга лаек. Ул халык авыз иҗатын өйрәнү тарихына бераз күз ташлауны таләп итә. Ислам диненең көчле агым булып үтеп керүе татар мәдәниятендә исламга кадәрге авыз иҗатын, аның жанрларын «оныттыра». Без бүген төрки чыгышлы Алтай, Кавказ халыкларындагы бездә бөтенләй булмаган фольклор жанрларын күзәткәндә, аларның менталитетыбызга бик тә якын икәнлеген тоябыз, татар әдәбиятында «эзләре» барлыгы да күзгә ташланып тора. Ләкин жанрлар югалган. Әлеге күренеш татар халык авыз иҗатының системалы төстә чагыштырмача соң өйрәнелә башлавы, бу вакытта рус галимнәре хезмәтләренең тәэсире зур булу белән дә аңлатыла. Шуңа күрә кайбер жанрларыбыз теориясендә рус фольклорындагы жанрларны өйрәнү тәҗрибәсенең турыдан-туры чагылуы да сер түгел. А.Г.Яхинның татар халык авыз иҗатын система итеп өйрәнүгә багышланган фәнни хезмәте исә шушы якны исәпкә ала, автор татар фольклоры жанрларының милли үзенчәлекләрен билгеләүгә зур урын бирә.

Хезмәт ике кушымта белән баетылган. Беренчесе — «Татар әдәбияты системасында татар фольклоры структурасы», икенчесе «Әдәби әсәр структурасында мәзәкләр структурасы» дип атала һәм алар А.Г.Яхинның өр-яңа бер фундаменталь хезмәт язарга әзерләнгәне, шул хезмәтнең концепциясен аңында «төзеп куйганлыгы» турында сөйли. Бу өлешләрдә, татар әдәбиятын структурализм юнәлешендә тикшергәндә, нинди милли нигезләргә таянырга кирәклеге күрсәтелгән, урта гасырлар татар әдәбиятында халык авыз иҗатыннан килгән нинди структур калыплар яшәгәнлеге ачыкланган. Кушымталарда тәкъдим ителгән аерым бер методик фикерләр Альберт Гатуф улының мәктәпләр өчен эшләнгән программаларында, дәреслекләрендә файдаланылган. Ләкин биредә алар махсус фәнни хезмәтнең, монографиянең планы, башлангычы кебек тәэсир калдыра. Бу өлешләр татар әдәбиятын өйрәнүче галимнәр өчен аерата файдалы булыр дип уйлыйм.

Китап татар фольклорын структурализм концепциясенә таянып өйрәнүнең перспективалы, кызыклы булуын тагын бер кат ассызыклый. Бәлки, ул иртәрәк киң фәнни әйләнешкә кергән булса, татар фольклористикасы нарратология, семиотика сукмакларын тирәнрәк үзләштергән булыр иде. Ләкин аның басылып чыгуы, яшь галимнәр, фәндә беренче адымнарын атлаучылар кулына барып җитүе мөһим. Дәвамчылар, фикерләрне үстерүчеләр булганда, гыйльми тәгълиматлар да югалмый.

Дания Заһидуллина,
филология фәннәре докторы,
Татарстан Фәннәр академиясе академигы

ТАРИХ СӘХИФӘЛӘРЕННӘН

ӘХМӘТ МАЗҺАРОВКА 70 ЯШЬ

11 гыйнварда Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең актлар залында Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе президенты, техник фәннәр докторы, профессор Әхмәт Мазһаровка 70 яшь тулу уңаеннан тантаналы чара үтте. Әхмәт Мазһаров — нефть һәм газны күкерт кушылмаларыннан арындыру белән шөгыльләнгән һәм бу өлкәдә шактый зур ачышлар ясаган галим, 165 гыйльми хезмәт, 130 патент иясе. Ул эшләгән технологияләр дөньяның төрле илләрендә кулланыла. Гомумән, ул —Татарстанны һәм Татарстан Фәннәр академиясен дөнья күләмендә таныткан шәхес. Казан Кремлендә Татарстан Республикасы Президенты Рөстәм Миңнеханов Әхмәт Мазһаровка «Татарстан Республикасы алдындагы казанышлары өчен» орденын тапшырды. Галимне котларга килгән Россия Фәннәр академиясенең Океанология институты директоры, РФА һәм ТФА академигы Роберт Нигъмәтуллин, ТР Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин, РФА академигы, РФ Дәүләт Думасы депутаты, география фәннәре докторы Михаил Залиханов, Башкортстан Фәннәр академиясе президенты Рамил Бәхтизин, Россия Фәннәр академиясенең Казан фәнни үзәге рәисе Олег Синяшин кебек шәхесләр тарафыннан галимнең фәнни-оештыру эшчәнлегенә югары бәя бирелде. Чарада шулай ук язучылар, журналистлар һәм җәмәгать эшлеклеләре катнашты.

РОАЛЬД СӘГЪДИЕВКӘ 80 ЯШЬ

21 гыйнварда Россия Фәннәр академиясе һәм Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе академигы, физика-математика фәннәре докторы, Мэриленд университеты профессоры, «Көнчыгыш-Көнбатыш», АКШ фәнни тикшеренүләр үзәге җитәкчесе Роальд Сәгъдиев 80 яшен билгеләп үтте. Роальд Сәгъдиев — атом-төш энергиясе, плазма физикасы һәм астрофизика мәсьәләләрен өйрәнүгә саллы гына өлеш керткән белгеч. Казан Кремлендә галимне ТР Президенты Рөстәм Миңнеханов котлады һәм «Татарстан Республикасы алдындагы казанышлары өчен» ордены белән бүләкләде. Ә Фәннәр академиясендә узган чарада Роальд Сәгъдиевкә ТФА президенты Әхмәт Мазһаров академиянең яңа гына булдырылган алтын медален тапшырды. Роальд Сәгъдиевне котларга галимнәр, язучылар, сәясәтчеләр һәм иң сөендергәне — әнисе туып үскән Буа районы, әтисенең туган ягы Кама Тамагы районыннан да якташлары, Казан каласының 19 нчы гимназиясе вәкилләре дә килгән иде. Буалылар Р.Сәгъдиевкә «Буа шәһәренең шәрәфле гражданины» исемен бирде, ә галим, үз чиратында, Буа шәһәренең Р.Сәгъдиев исемендәге мәктәбендә физика фәнен иң яхшы үзләштерүче укучыларга ноутбук бүләк итте.

ТАТАРСТАН КОМПОЗИТОРЛАРЫНЫҢ МУЗЫКА АНТОЛОГИЯСЕ

23 гыйнварда Казан шәһәренең Салих Сәйдәшев исемендәге Зур концерт залында Sony Music һәм RCA Red Seal Records ширкәтләре ярдәмендә дөнья күргән «Татарстан композиторларының музыка антологиясе» тәкъдим ителде. Диск-антологиядә Нәҗип Җиһанов, Салих Сәйдәшев, Фасил Әхмәтов, Алмаз Монасыйпов, Фәрит Яруллин, Рәшид Кәлимуллин, Шамил Тимербулатов, Анатолий Луппов, Ренат Еникеев, Мәсгудә Шәмсетдинова, Алёна Анисимова, Резедә Ахиярова, Зөлфия Рәүпова, Александр Миргородский кебек танылган композиторларның әсәрләре урын алган. Бу җыентыктагы әсәрләрне Александр Сладковский җитәкчелегендәге Татарстан дәүләт симфоник оркестры башкарды. Диск-антологияне тәкъдим итү тантанасында «B-Sharp» Берлин студиясенең продюссеры Филипп Нидель һәм Sony Music Russia мөдире Йэн Һендерсон катнашты. ■

«УНИВЕРСИАДА!» ДИП ТИБӘ ЙӨРӘКЛӘР

ӘЛЕ КАЙЧАН ГЫНА КАЗАНДА ҮТӘЧӘК УНИВЕРСИАДАГА ИКЕ ЕЛ, БЕР ЕЛ КАЛДЫ ДИП СӨЙЛӘНДЕК. БАКСАҢ, БҮГЕН АНЫҢ БАШЛАНУЫНА БИШ АЙ ВАКЫТ КАЛЫП БАРА ИКӘН. БУ ВАКЫТНЫ ИНДЕ АЙЛАП ТҮГЕЛ, Ә КӨНЛӘП САНЫЙЛАР. УНИВЕРСИАДА ТУРЫНДА БЕЗ НӘРСӘЛӘР БЕЛӘБЕЗ СОҢ? АНДА КЕМНӘР КАТНАША, НИНДИ СПОРТ ТӨРЛӘРЕ БУЕНЧА КӨЧ СЫНАШАЛАР? ӘЙДӘГЕЗ, ӘЛЕГЕ СОРАУЛАРГА ҖАВАП БИРГӘНЧЕ, БУ ЧАРАНЫҢ ТАРИХЫНА КҮЗ САЛЫП АЛЫЙК.

ТАРИХ СӨЙЛИ...

Катнашучылар саны, программага кертелгән спорт төрләренең күплеге ягыннан Универсиада Олимпиададан кала икенче урында тора. Һәм иң кызыгы шунда: хәзерге заман Олимпиадаларын уйлап тапкан кебек, аны да французлар гамәлгә кертеп җибәргәннәр. Әгәр Олимпиадаларны яңадан торгызуга Пьер де Кубертен зур өлеш кертсә, Универсиадаларның «атасы» дип Жан Петижанны санарга мөмкин. Ул I Бөтендөнья сугышы барган чорда ук Җир шарындагы сәяси хәлләрнең күбесен сугыш юлы белән түгел, ә спорт мәйданнарында да хәл итеп булачагын, җәмгыятьтә нәкъ менә студентларның зур көч икәнлеген аңлаган. Әмма моны башка илләрнең җитәкчеләренә төшендерү җиңел генә бармаган. Студентларның халыкара конференциясен 1919 елда ук төзүгә ирешелсә дә, берничә ил вәкилләре катнашкан Халыкара спорт конгрессы 1923 елда гына җыела. Ә беренче Универсиада 1924 елда Варшавада үткәрелә. Аның программасына җиңел атлетика гына кертелә. Ә инде 1927 елда Римда үткән икенче Универсиада программасы футбол, теннис, йөзү һәм фехтование белән байый. Анда тәүге кабат океан арты спортчылары — АКШ һәм Гаити яшьләре дә катнаша. Тагын шунысы да бар: беренче һәм икенче Универсиадаларда фәкать ир-егетләр генә көч сынаша. 1928 елдан башлап дөнья студентлары өчен кышкы Универсиадалар да үткәрелә башлый, ә җәйгеләрендә хатын-кызларга да катнашу рөхсәт ителә.

Әлбәттә, Универсиадалар үткәрү шома гына бармаган. Моңа II Бөтендөнья сугышы, күп кенә илләр арасындагы каршылыклар аяк чалган. Ниһаять, 1949 елның 1 маенда Халыкара студентлар спорты федерациясе (FISU) төзелү сугыш вакытында тукталып торган спорт бәйрәмнәрен яңадан дәвам итүгә зур этәргеч ясаган һәм алар ике ел саен даими рәвештә үтә.

Безнең илдә (СССРда) җәйге Универсиада 1973 елны үткәрелде. Анда 71 илдән дүрт меңнән артык спортчы катнашты. Шулай итеп, Казан Универсиадасы Мәскәүдәгесеннән соң нәкъ 40 ел үткәч уза һәм ул катнашучылар саны ягыннан да, уйнатылачак медальләр күләме буенча да әлегә иң зурысы булачак.

КАЗАН — ВУЗЛАР ШӘҺӘРЕ

Казаныбызга 2013 елдагы Универсиаданы үткәрү хокукын тапшырганда, FISU аның, чын мәгънәсендә, студентлар шәһәре икәнлеген дә искә алгандыр, студент спортчыларыбызның Универсиадаларда гына түгел, ә дөнья чемпионатларында, Олимпия уеннарындагы уңышлы чыгышларын да күз алдында тоткандыр дип уйларга кирәк.

Республикабыздагы студентлар спорты тарихы «Буревестник» ирекле спорт

җәмгыяте тарихы белән аерылгысыз. Бөек Ватан сугышыннан соң оештырылган әлеге җәмгыять бик күп талантларга спортта һәм тормышта үз урыннарын табарга булышты. Ни кызганыч, Советлар Союзы таркалган 90 нчы елларда күп кенә урыннарда әлеге җәмгыятьне дә бетереп ташладылар. Тик республикабызда ул яңадан торгызылды һәм бүген үз эченә 40тан артык югары уку йортын, 64 көллиятне берләштерә. Әлеге җәмгыять оештыра торган ярышларга 200 меңнән артык катнашучы килүен исәпкә алсак, аның, чыннан да, зур көч икәнлеген күрербез.

Универсиада медален республикабызга беренче булып Зәй егете чаңгычы Фёдор Симашев алып кайта. Ул, 70 нче елларда ике кышкы Универсиадада катнашып, биш дистанциядә алтын медальләр яулады.

1973 елда Мәскәүдә үткән Универсиадада рапира осталары Наилә Гыйләҗева, Валентина Никонова һәм Ольга Князева команда беренчелегендә көмеш медальләр яулады, ә Валентина Никонова шәхси беренчелектә дә мактау пьедесталының икенче баскычына менде.

1983 елгы Универсиададан Чаллы кызы, велосипедта узышучы Надежда Кибардина ике алтын һәм ике бронза медаль алып кайтты.

Аннан соңгы Универсиадаларда медаль алучылар арасында Татарстаннан җиңел атлетлар Ольга Сальникова, Елена Мигунова, фехтование осталары Екатерина Шурупина, Илья Мокрецов, Камилла Гафурҗанова, штанга күтәрүче Андрей Деманов, дистәдән артык хоккейчыларыбыз бар.

БЕЗНЕҢ ӨМЕТЛӘР

Универсиада узачак 6-17 июль көннәрендә бөтен дөньяның игътибары Казанга юнәләчәк. Безгә 170тән артык илдән 12 меңләп спортчы килүе көтелә. Аларның тренерлары, табиблар, рәсми вәкилләр, волонтёрлар, туристлар белән бергә килүчеләр саны 100 мең кешедән дә артып китәчәк.

Студентлар һәм аспирантлар спортның 27 төреннән 351 комплект медаль өчен көрәшәчәк. 13 спорт төре (җиңел атлетика, йөзү, нәфис гимнастика, өстәл теннисы, баскетбол, вышкадан суга сикерү, фехтование, футбол, дзюдо, спорт гимнастикасы, волейбол, теннис, ватерпол) барлык Универсиадалар өчен дә мәҗбүри санала.

Россия, шундый зур спорт форумын үткәрүче ил буларак, программага тагын 14 төрне (бокс, ату, синхрон йөзү, академик ишү, байдаркаларда һәм каноэ көймәләрендә йөзү, самбо, билбау көрәше, шахмат, авыр атлетика, регби-7, чирәм хоккее, бадминтон, пляж волейболы) өстәде. Спорт белгечләре Татарстан спортчыларының аеруча авыр атлетика, билбау көрәше, фехтование, нәфис гимнастика төрләрендә зур уңышка ирешәчәген фаразлый.

Чыннан да, штанга күтәрү буенча Россия җыелма командасының төп нигезен Андрей Деманов, Геннадий Муратов, Дмитрий Хомяков, Артём Окулов кебек безнең егетләр тәшкил итә. Билбау көрәше буенча да безнекеләр, тиздән Воронеж шәһәрендә үтәчәк сайлап алу турнирларында үзләрен күрсәтеп, Универсиадада катнашу хокукын яуларлар дип өметләник. Без шулай ук Лондон Олимпиадасыннан көмеш медаль яулап кайткан фехтование остасы Камилла Гафурҗанова белән бронза медаль иясе, тхэквондо остасы Алексей Денисенкога да зур өметләр баглыйбыз.

«Өйдә диварлар да булыша», диләр бит. Шулай булса да, алдан әллә ни юрамыйк, ә зур спорт форумының үзен көтик. Ничек кенә булмасын, Универсиада Казаныбызның абруен илдә генә түгел, ә бөтен дөньяда тагын берничә башка югарырак күтәрәчәк бит. Хәерле сәгатьтә!

***Атлас Гафиятов** әзерләде.*

Универсиада – 2013 символлары

Индекс 54132